# ШУРА

№ 45

2024



ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4

Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

Гашурә көне. Нәфел уразаларның файдасы . . . . . . . . 14

Әрвахларыбызга ничек ярдәм итә алабыз?. . . . . . . . . 20

Никахның әһәмияте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27

Биләл радыяллаһу ганһенең тормышыннан дәресләр . . . . . . 40

Коръән хафизларның дәрәҗәсе . . . . . . . . . . . . . . . 47

Җәмәгатьнең мөһимлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56

Кеше җаны – әманәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63

Белем алганда ниятләребез дөрес булсын . . . . . . . . 68

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам – иң гадел җитәкче . . . . . . . 74

Мәүлид ән-Нәби . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79

Динебезгә чакырабызмы?. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85

Өлкәннәрне хөрмәтләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

Гыйлемне остазлардан алуның әһәмияте . . . . . . . . . 99

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . 105

МАРТ-ИЮНЬ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106

**«ШУРА» дини альманах, № 45** **12+**

июль–сентябрь 2024
мөхәррам–рабигыль-ахыр 1446

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38нче йорт

Бушлай таратыла.
2013 елның июленнән чыга.
Басма кварталга бер тапкыр чыга.

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Рәмзилә Маннанова

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ильяс Гарифуллин

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Тышлыкның 1нче битендә Болгар шәһәрендәге «Ак мәчет» сурәтләнгән, соңгы битендә гарәпчә «әл-Мәүлид ән-Нәби әш-Шәриф» дип язылган.
Рәсемнең авторы: Хамматов Ленар, Tasnim Ahmad / shutterstock.com/ru/image-vector/vector-mawlid-al-nabi-translation-arabic-742392532

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ № ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Карти» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420095, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Восстания урамы, 100 йорт, 209 корпус, 22 бина.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 17.06.2024
Чыгу көне: 8.07.2024

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

________________________________________ ۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

________________________________________ ۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسْلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلٰوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةِ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәә-нә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә эн һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә эн йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү эн ләә иләәһә илләллаһү. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыйинәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ____________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләзиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати з̣әвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гус̣мәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфирииинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ____________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгеләә.

**Иң соңыннан, «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

> **«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*12 нче июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Гашурә көне. Нәфел уразаларның файдасы

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хаҗ кылу гамәлләрен һәм Корбан гаетен үз эченә алган зөлхиҗҗә ае тәмамлану белән, мөселман календаре буенча яңа 1446 ел башланып китте. Ислам календаре буенча елның беренче ае булып мөхәррам ае килә. Үз вакытында һиҗри календарьне гамәлгә керткән Гомәр әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе нәкъ менә мөхәррам аен беренче ай итеп билгеләгән. Моның үз хикмәте дә бардыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сахих хәдистә болай дип әйткән: «Кеше начар сүзләр сөйләмичә, бозыклыклар кылмыйча, бу Йортка (ягъни Кәгъбәгә) хаҗ кылса, өенә анадан туган сабый кебек (пакь, гөнаһларсыз) кайтыр».[1] Димәк, фазыйләтле зөлхиҗҗә аенда мөселманнар хаҗ гамәлләрен үтәп, корбаннар чалып, гөнаһларыннан пакьләнәләр. Һәм шундый зур гыйбадәтләр кылып, иман байлыкларын арттырып, киләсе елга яңа өметләр, максатлар белән аяк басалар.

Мөхәррам атамасының асылында «харам» («тыю») сүзе ята. Аллаһы Тәгалә «Әт-Тәүбә» сүрәсенең 36 нчы аятендә болай ди:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ

---

[1] Әл-Бохари, 1819.

> **«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге** [катгый карарын белдергән] **язуында** [Ләүхелмәхфүздә] **– унике. Шуларның дүртесе – харам** [айлар]**. Бу –** [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйльдән галәйһимәссәлам калган] **хак дин.** [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] **Боларда** [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] **үз-үзегезгә золым итмәгез...»**
>
> «Әт-Тәүбә», 9:36

Аңлашылганча, аять дүрт изге ай булганын белдерә. Бу җәһәттән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Раббыбыз Аллаһы күкләрне вә җирне яраткан көннән бирле, тормыш илаһи низам, илаһи тәртипкә корылган рәвештә дәвам итәдер. Ел – унике айдыр, шуларның дүртесе – харам айлар. Аларның өчесе бер-бер артлы киләдер: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррамдыр. Дүртенчесе – раҗәб ае».[1] Бу айларга хөрмәт вә дәрәҗә сакланырга тиеш, бигрәк тә зөлхиҗҗә белән мөхәррамның беренче ун көннәрендә гөнаһлардан сакланыгыз.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бу көннәрдә без тулы бер тәкъвалык халәтендә яшәп, намазга, уразага, садака бирүгә, матур, гүзәл изге эшләргә аерым бер игътибар бирергә вә зуррак тырышлык күрсәтергә тиешбез.

Мөхәррам ае һиҗри елның башланганын белдерү җәһәтеннән генә түгел, ә үзендәге Гашура көне белән дә бик кыйммәтледер. «Гашурә» сүзе гарәп телендә ун санын аңлата, ягъни мөхәррамның унынчы көнен белдерә. Риваятьләрдә килгәнчә, бу көнне җир йөзендә күп шатлыклы вакыйгалар булып узган. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдис-шәрифендә: «Рамазаннан соң иң саваплы ураза – мөхәррамда тотылганыдыр», – дип әйтә. Һәм Пәйгамбәребез безгә бу айның унынчы көнендә ураза тотуны аерым киңәш иткән. Иң элек мөселманнар нәкъ Гашурә көнендә

[1] Әл-Бохари, Мөслим.

ураза тоткан. Ә инде соңрак, Аллаһының әмере белән Рамазанда ураза тоту фарыз ителгән.

Гайшә радыяллаһу ганһәдән: «Җаһилият чорында корәешлеләр Гашурә көнендә ураза тоттылар. Рамазан ае уразасы мәҗбүр булганчыга кадәр, Пәйгамбәребез бу көндә ураза тотарга кушты. (Рамазан уразасы мәҗбүр булгач), Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кем тели, шул тотсын, ә кем тели – калдырсын», – дип әйтте», – дигән хәдис тапшырыла.[1] Димәк, Гашурә уразасы теләгән кешегә генә гыйбадәт булып калды. Әҗер-савап аласы килсә – тотсын, тотарга мөмкинлеге булмаса – гөнаһы юк.

Бу уразаның әҗере хакында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Гашурә көнендә ураза тотсагыз, узган елдагы гөнаһларыгызны Аллаһы Тәгалә гафу итәр, истигъфар кылыр». Аллаһының Илчесе уразаны Гашурә көнгә бер көн өстәп, йә 9 нчы һәм 10 нчы мөхәррамда, йә 10 нчы һәм 11 нче көннәрендә тотарга кушкан. Бу калган дин әһелләреннән аерылып тору өчен шулай кертелгән. Быел Гашурә көне сишәмбе, 16 нчы июль көненә туры килә. Димәк, аңа өстәп дүшәмбе уразасын да тота алсак, ике сөннәтне үтәп, тагын да зуррак әҗер-савапларга ирешербез, иншәАллаһ.

Әйе, бу фарыз түгел, ә өстәмә, сөннәт ураза гына, диючеләр бардыр, бәлки. Ә без уразаларыбызны нәрсә өчен тотабыз соң? Әлбәттә, гөнаһлардан сакланыр өчен. Хөрмәтле дин кардәшләрем, ураза ул – бөек гыйбадәтләрдәндер. Ураза ул безне Раббыбыз белән бәйли торган яшерен, серле бер силсилә булып тора. Адәм баласы уразадан кала кылган һәр гамәлен (намаз уку, ашарга пешерү, эшкә бару, балалар тәрбияләү һ. б.) үзе өчен эшли. Гомумән, ураза ул адәм баласының рухи ягын тәрбияләр өчен бер көчле корал булып тора. Исламның биш нигезе дә шул тәрбиягә юнәлтелгән. Хәдисләрдән билгеле булганча, нәфесне тәрбияләүнең иң яхшы ысулы – ураза тоту. Бер хәдистә болай дип әйтелә: «Аллаһы Тәгалә нәфескә «Син кем дә, Мин Кем?» дигән. Нәфес: «Син – мин ул, мин – Син ул», – дип җавап биргән. Раббыбыз

[1] Әл-Бохари: 1893.

аны утка ташлап җәзалый. Шуннан Аллаһы аннан тагын сорый: «Син кем дә, Мин Кем?» Нәфес кабат: «Син – мин ул, мин – Син ул», – дип җавап кайтара. Нәфес янә ачлык белән җәза ала. Шуннан соң гына, тагын бер кат сорагач, хәлсезләнгән нәфес Бөек Затка: «Син – минем Раббым, Син мине яклыйсың һәм минем гөнаһларымны гафу итәсең. Мин – Синең ярдәмеңә мохтаҗ мескен колың», – дип әйтә». Бу елга бер булган фарыз уразага гына карамый, ел дәвамында да үзебезне ураза белән тәрбияләп, гөнаһлардан саклап торыйк.

Кайвакыт: «Ни өчен һаман гөнаһлар турында сүз йөртәбез?» – диючеләр була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйтә: «Адәм баласының кылган гөнаһлары, эшләгән хата-кимчелекләре аркасында аларның җилкәсенә бәла-казалар, хәерчелек килә». Димәк, гөнаһтан ерак булу – бу тормышта да, ахирәт тормышында да бәхеткә ирешү ысулы ул.

Ә ураза тоту ул ашамый тору гына түгел. Гадәттә, уразасын бозарга куркып, кеше башка вакытта кылырга мөмкин булган гөнаһларыннан, кимчелекләрдән ныграк саклана. Мәсәлән, алдау, гайбәт сөйләү кебек тел гөнаһларыннан ныграк саклана. Адәм баласы һәр әгъзасы белән ничек дөрес, саваплы гамәлләр кыла алса, нәкъ шулай ук аларга хас гөнаһларны кыла ала. Шуңа күрә гөнаһларны без: тел гөнаһы, кул гөнаһы, колак гөнаһы, күз гөнаһы дип аерып атыйбыз да. Менә күз гөнаһын алыйк. Үзебезне шушы күз гөнаһларыннан гына булса да саклый алсак, инде нинди зур җиңү булыр иде. Ә күз гөнаһына нәрсә керә соң? Әлбәттә, тыелган, сиңа харам булган әйберләргә карау. Чит-ят хатын-кызның гаурәтенә карау сиңа рөхсәт ителгәнме? Юк, кагылырга да, карарга да рөхсәт түгел. Хатын-кызларга шулай ук чит ир-атның гаурәтенә карау тыелган. Җәй җиттеме, бездә хатын-кыз киемен киметә, бөтен әгъзаларын күрсәтерлек киемнәр кия башлый. Инде ир-атлар да калышмый, кайберләре кыска шортылар киеп йөри. Соң нишләргә, хәзер урамга чыкмаскамы, дияр кемдер. Галимнәребез күзләрне нәфесебезнең тәрәзәсе дип атады. Шуңа күрә, нәфесеңне тыярга телисең икән, күзләреңне дә акылыңа буйсындыр, карашыңны төшер, гаурәтләре ачылган кешене күрдең

икән, аңа сокланып, кат-кат карама. Шайтан безне бик җиңел алдый, башта ул бер караш кына була, аннан соң кеше моннан ләззәт таба башлый, ахырда нинди хаталарга китерә алуын барыбыз да аңлый. Бүгенге көндә телевизор, телефоннарны кулланганда да бик сак булырга кирәк. Синең телефонда нәрсәләр караганыңны беркем күрми димә, Аллаһы Тәгалә барысын да күрә!

Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُل لِّلْمُؤْمِنِينَ يَغُضُّوا مِنْ أَبْصَارِهِمْ وَيَحْفَظُوا فُرُوجَهُمْ ۚ ذَٰلِكَ أَزْكَىٰ لَهُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا يَصْنَعُونَ ﴿٣٠﴾ وَقُل لِّلْمُؤْمِنَاتِ يَغْضُضْنَ مِنْ أَبْصَارِهِنَّ وَيَحْفَظْنَ فُرُوجَهُنَّ

«[Расүлем!] **Иманлы ирләргә әйт,** [харамнарга караудан] **күзләрен яшерсеннәр** [дә, хәләлләргә генә карасыннар] **һәм җенес әгъзаларын** [зина һәм ливата кебек харамнардан] **сакласыннар. Бу алар өчен хәерлерәк** [бер гамәл]**. Һичшиксез, Аллаһы – аларның** [кемгә караганнарыннан һәм] **ни кылганнарыннан хәбәрдар.**

**Иманлы хатыннарга әйт, күзләрен** [ирләрнең һәм хатыннарның гаурәт урыннарына караудан] **яшерсеннәр һәм җенес әгъзаларын** [зинадан] **сакласыннар...»**

«Ән-Нур», 24:30

Менә бу – Раббыбызның ачыктан-ачык әмере. Ә аны үтәү авыр булса, нишләргә? Аллаһы Тәгалә моның чишелешен күрсәткән – ураза тотарга. Ураза ул – ашамау гына түгел, ул әдәп-әхлагыңны күркәм якка төзәтү. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Ий яшьләр! Өйләнә алганнарыгыз өйләнсен, чөнки бу барыннан да ныграк карашларны һәм җенес әгъзаларын сакларга ярдәм итә. Ә өйләнә алмаганнарыгыз – ураза тотсын...»[1]

---

1 Әл-Бохари, 1905; Мөслим, 1400.

Димәк, бер ысул ул – ураза тоту. Шулай ук Коръән, аның тәфсирен, хәдисләр уку – болар күз белән кылына торган гыйбадәт, саваплы гамәлләр. Шуңа күрә, гөнаһлы гамәлдән тыеласың килсә, аңа капма-каршы булган хәләл, саваплы гамәлләрне арттырырга кирәк. Бу бар гөнаһлар белән шулай эшли.

Аллаһы Тәгалә адәм баласына, дөрес юл сайласын өчен, шушындый ысуллар тәкъдим итә һәм үтәргә өнди. Ә өстәмә гыйбадәтләр, Гашурә көне, Мигъраҗ кичәсе, Бәраәт көне, Кадер кичәсе кебек фазыйләтле вә мөбарәк көннәр кешене фикерләргә, динне аңларга, үзенең якыннарын дөрес юлга өндәргә өйрәтә.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Раббыбызның ярдәме белән хәерле уңышларга ирешергә, мәгъфирәткә, бәхет-сәгадәткә ирешергә язсын! Аллаһы Тәгалә безне бозык, дөрес булмаган адашу юлларыннан саклап, дөрес юлга, мәгъфирәт юлына ирештерсен. Аллаһы Тәгалә барчабыздан да разый булсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Мирхәт хәзрәт Җамалиев,*
*Апас районының имам-мөхтәсибе*

*19 нчы июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Әрвахларыбызга ничек ярдәм итә алабыз?

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы бөек Раббыбызга барча мактауларыбыз, Аның хак Расүле, соңгы Пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафага салаватларыбыз булсын!

Мөхтәрәм кардәшләр, Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Гыйбадәт ул – Аллаһыга ышанган хәлдә Аның юлында хезмәт итү. Беренчедән, иман китерү, ягъни Исламның биш нигезен үтәү. Алга таба: һәр эшне «бисмилләһ» белән башлау, ярдәмчел булу, нинди хезмәт башкарсаң да, Аллаһы ризалыгын алырга тырышу, садака бирү. Һәрберебез, һәр мөселман, бу гамәлләр турында белеп, аларны үтәргә тырышып яшәргә тиеш. Шундый изге-хәерле гамәлләр, гыйбадәтләр арасында бу дөньядан бакыйлыкка күчкән әти-әниләребез, әби-бабаларыбыз, туганнарыбыз өчен изге эшләр кылу аерым урын алып тора. Бу нинди эшләр соң? Мәсәлән, каберләрне зиярәт кылу, әрвахларыбыз өчен дога кылып, Аллаһыдан ярлыкау сорау. Бүген шулар турында сөйләшербез.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйткән: «(Әүвәл) Мин сезгә каберләрне зиярәт кылуны тыйган идем, әмма хәзер рөхсәт итәм, чөнки каберләрне зиярәт итү үлемне, соңгы Ахирәт көнен искә төшерә».[1]

Татар телендә каберлекләрне «зират», «зыярат» кебек сүзләр белән атыйбыз. Бу сүзнең мәгънәсенә карасак, ул бит «зиярәт яки зыярат итү» сүзеннән килеп чыккан. Зиярәт кылу – барып күрү дигәнне аңлата, шуңа күрә без «авыруларны, туганнарны зиярәт итү» дип әйтәбез. Димәк, әби-бабаларыбыз каберлекләрне еш зиярәт кылганнан, шулай атый башлагандыр да.

Каберлек ул – җирнең бер тыныч урыны, анда үзең генә калып уйланасың, үлем турында фикер йөртәсең, тормыш юлыңның кимчелекләрен анализлыйсың. Янә бакыйлыкка күчкән якыннарыбызның үткән-кичергән тормышларын искә төшереп, гыйбрәт аласың. Каберләрне зиярәт кылу – үлемнең хак икәнен искә төшереп тору ул. Һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә килгәнчә, бу мөселманның каберстанга баруының төп максаты булырга тиеш.

Кеше һәрдаим ике халәттә яши: яшәргә теләве һәм үлемнең хак икәнен белү. Әгәр кеше дөньяны вә бу тормышны мәңгелек дип белеп, үлемнең хак икәнен танымаса, ул ни өчен яшәгәнен дә белмәс иде, ахирәт тормышы турында уйланмас иде.

Мөэмин-мөселманнар өчен үлем ул – Аллаһының бүләге, ул борчу-мәшәкатьле бу тормыштан тыныч бакыйлыкка китү шатлыгы, ул бер халәттән икенче хәлгә күчү ләззәте. Ә кяферләр, имансызлар яки гөнаһлылар өчен ул – бетмәс газап.

Безнең борынгы бабаларыбыз каберлекләрне шәһәр яки авылга бик якын итеп, тирәп ясаганнар, янында мәчетен дә салдырганнар. Мәчеткә, гыйбадәт кылырга кергәндә, каберстан керү юлында даими торган киңәшчең

---

1 Әт-Тирмизи, Мөслим.

булсын өчен. Шулай ук каберләрне ешрак зиярәт кылу мөмкинлеге булсын өчен.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бәлки кыш айларында берникадәр кыенлыклар буладыр, әмма елның карсыз айларында без дә каберлекләрне ешрак зиярәт итсәк иде. Шушы күркәм гадәтне кайтарыйк. Каберләрне зиярәт кылу ул – безнең өчен гыйбрәтле дәрес, ә үлгәннәр өчен – җибәрелгән рәхмәт вә шәфкать, чөнки үлүчеләр, сазлыкка баткан кеше кебек, ярдәм көтә.

Каберләрне зиярәт итүдә без билгеле бер әдәпләрне үтәп, динебезгә хас булмаган, әмма халкыбызда киң таралган хаталы гамәлләрне кылмаска тиешбез.

Беренчедән, зиратларыбызга тәһарәтле килеш кереп, үзеңне тыныч тоту тиешле. Анда сабырлык белән әрвахларыбыз рухына дога кылу, Коръән аятьләрен укып багышлау хәерле гамәлләрдән булыр.

Әрвахларга багышлап Коръән укысак, аларга Аллаһының мәрхәмәте ирешер, бигрәк тә «Йәсин» сүрәсен укысак, иншәАллаһ. Бу хакта пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисендә болай дигән: «Йәсин» сүрәсе – Коръәннең йөрәге. Аны Аллаһының ризалыгын өмет итеп укучы һичшиксез котылыр. Аны әрвахларыгызга атап укыгыз».[1]

Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук болай дип әйткән: «Кемгә дә булса үлеме килсә, аны тизрәк кабергә төшерү хәерлерәк булыр. Күмгәннән соң баш очында «Фатиха» сүрәсен укыгыз, ә аяк очында «Әл-Бәкара» сүрәсеннән «әмәнәр-расүлү»не (ягъни сүрәнең ахыргы аятьләрен) укыгыз. [2]

Габдрахман бине Галә бине Ләҗҗәҗ болай дип әйткән: «Минем әтием, Галә бине Ләҗҗәҗ, үлгәндә шуны васыять итеп калдырды: «Мине кабергә куйганнан соң, «бисмилләһи вә галә сүннәти Расүлуллаһи» – дип әйтегез, соңыннан кабер туфрагын салыгыз. Һәм шуннан соң баш очымда «Әл-Бәкара»

---

1 Әхмәд.

2 Әт-Табарани.

сүрәсенең башын вә ахырын укыгыз. Дөреслектә, мин Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһенең шулай киңәш итүен ишеткән идем».[1]

Моннан күренгәнчә, каберләрне зиярәт кылу, мәетләргә хәерлелек, тынычлык теләп дога кылу, алар рухы шат булсын дип, садака бирү, Коръән укып дога багышлаулар – бу Аллаһының бер рәхмәте булып тора. Әмма әрвахларыбыз өчен дога кылу, Коръән багышлау өчен һәрвакыт каберстанга бару кирәк, дигән сүз түгел. Без бакыйлыкка күчкән әби-бабаларыбыз, галимнәребез, гомумән бөтен мөселманнар өчен көн саен дога кылып торсак хәерле. Һәр намаздан соң алар рухына дога кылыйк. Еш кына: «Ә нинди дога кылырга, шул гарәпчә доганы безгә татар хәрефләре белән язып бирегез әле», – диләр бездә. Хөрмәтле дин кардәшләрем, иң ихлас дога ул – үз сүзләрең белән, үзең аңлап кыла торган дога. Әгәр гарәпчә укый белмисез икән, үз сүзләрегез белән: «Раббым, мөселман булып бакыйлыкка күчкән барча әби-бабаларым, туганнарымның хата-кимчелекләрен ярлыка, рухларын шат кыл, кабер газапларыннан коткар, Үз рәхмәтең илә аларны җәннәтеңә керт», – дип сорагыз. Ә Коръән укып багышлаганда: «Аллаһым, шушы укылган аять-сүрәләрнең савабын әрвахларымның рухларына да ирештер», – дип әйтергә була. Моны мөмкин кадәр ешрак, хәтта һәр намаздан соң да бер кечкенә сүрә укып куеп, шулай багышларга мөмкин. Раббыбызның рәхмәте, кодрәте киң, әҗер-саваплары үзебезгә дә, багышлаган барча әрвахларыбызга да ирешер. Коръән укый белмәүчеләр исә кемнәндер сорап та, мәчетләргә килеп тә укыта ала. Моның да савабы булыр, иншәАллаһ.

Шулай ук Раббыбыз Аллаһы Тәгалә безгә Коръәни Кәримнең «Әл-Хәшр» сүрәсенең 10 нчы аятендә мондый дога тәкъдим итә:

رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَلِإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالْإِيمَانِ وَلَا تَجْعَلْ فِي قُلُوبِنَا غِلًّا لِّلَّذِينَ آمَنُوا رَبَّنَا إِنَّكَ رَءُوفٌ رَّحِيمٌ ﴿١٠﴾

1 Әл-Бәйһакый «Әл-Сөннәт әл-кубра» 4, 56.

**«Ий Раббыбыз! Безне дә, бездән алда иман китерүчеләрне дә ярлыка һәм иман китергән кешеләргә карата күңелләребезгә ачу салма. Ий Раббыбыз! Һичшиксез, Син – Аяучан, Рәхимлесең».**

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:10

Хөрмәтле дин кардәшләрем, без шуңа бик игътибар итәргә тиешбез: бүген кайбер кешеләр кабер өсләрендә шәм яндыралар, ниндидер сурәтләр бәйләп куялар һәм башка бик күп кирәкмәгән ырымнар уйлап чыгаралар. Менә бу гамәлләрне динебез катгый тыя. Алар фәкать безнең наданлыгыбыздан гына тарала.

Гомумән каберлекләрне зиярәт кылу тәртибе, әдәпләре бар. Зиратларның эче дә, тыштан әйләнә-тирәсе дә чиста булырга тиеш. Чистарткannan соң барлыкка килгән чүп-чарны зират янында урнаштырылган чүп контейнерларына яки читкә чыгарып түгәргә кирәк. Моны аерым кеше дә башкара ала, әмма өмә белән җыештыру тагын да хәерлерәк булыр. Чардуганнарны даими рәвештә буяп торсак хәерле, алай алар озаграк сакланыр, ямьсез булып тормас. Кайбер якларда зиратка алып барган әйберләрне кире алып кайтырга ярамый, имеш бу өйгә үлем чакыра, дигән ышанулар яши. Һәм кешеләр бөтен перчаткасын, пумала, башка җиһазларын, чүп арттырып, зират контейнерларына ыргытып кайта. Бу зур ялгышлык, һәркайсыбызның үлем сәгате инде язылган, мондый надан кешеләрнең ышануларына иярмәгез. Сораулар туса, шикләнсәгез, муллалардан сорарга кирәк.

Каберләргә ясалма чәчәкләр, веноклар, ниндидер сыннар кую, кабер ташында рәсемнәр урнаштыру тыела. Гомумән, мөселманның кабер ташы артык зур, купшы булырга тиеш түгел. Аны кую максатыбыз – шушы кабердә кайсы дин кардәшебез ятуын билгеләү генә, шуңа күрә исемнәре, яшәгән еллары язылган кабер ташы җитә, артыгы кирәкми. Корыган чәчәкләрне җыеп алып, алар урынына яңаларын утырту – бик саваплы гамәл. Элек-электән бабаларыбыз зиратларда озын гомерле агачлар утыртканнар, мәетләргә савап барып торсын дип. Бүген кайбер җирлектә агачлар утыртмауны сорыйлар,

чөнки алар картаеп, авып, кабер ташларын боза, мәшәкать тудыра. Шуңа күрә, агачны тәрбияләп тора алмыйсыз икән, кыска куаклар яки үлән, чәчәкләр утырту хәерле булыр.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе хәбәр иткәнчә, бер көнне Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм ике кабер янынnan үткәндә, болай ди: «Болар бик җәзаланалар, юк, олы гөнаһлары өчен түгел, берсе – гайбәт сөйләгәне өчен, икенчесе – бәвелдән пакьләнмәгәне өчен». Соңыннан ул бер пальма ботагын алган да, аны урталай сындырып, шул каберләргә кадап куйган һәм: «Бу ботаклар кипкәнче, аларның җәзалары җиңеләйтелеп торыр, дип өметләнәм», – дип әйткән. Димәк, нинди генә үсемлек утыртсак та, без аны матурлык өчен утыртмыйбыз, ә әрвахларыбызга җиңеллек булсын, дигән ният кылабыз.

Безгә хак юлны күрсәтүче Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Кеше үлгәннән соң аның гамәл дәфтәре ябыла. Өч нәрсәдән гайре: садака җәрия, тапшырылган гыйлем һәм балалары тарафыннан әти-әнисе өчен кылынган дога». [1]

Садака җәрия ул – дәвамлы садака, әҗер-савабы килеп тора торган садака. Мәсәлән: юллар, күперләр салдыруда катнашу, кое-чишмәләр казыту, агачлар утырту, мәчет-мәдрәсәләр төзетү һ. б. хәерле гамәлләр. Болар башка кешеләргә күпме вакыт файда китереп торса, шуның кадәр кешегә, хәтта үлемнән соң да, әҗер-савабы ирешеп торачак. Шуңа күрә һәрберебез үзе, гаилә әһелләре исеменнән дә шушындый изге эшләрдә күбрәк катнашырга тырышсын.

Бу хәдис, беренчедән, кешене изгелеккә өндәсә, икенчедән, ул якыннарын бакыйлыкка озатканнарның өметләрен арттыра. Чөнки дөньяда яшәп калган туганнары, якыннары дога кылып, багышлап яхшылык эшләгән саен, мәеткә савап барып торыр. Бу эш дәвамлы булса, гамәл дәфтәре ябылмый тора, саваплар килеп тора.

[1] Мөслим.

Димәк, әрвахларыбыз рухы шат булсын, дип садакалар бирү бик хәерле гамәл булыр. Еш кына мәчеткә килеп: «Хәзрәт, үлгән туганымны төштә күрдем, садака өмет итәдер», – дип, мәчеткә садака салып китәләр. Ниндидер төшләр кергәнен көтеп утырырга кирәкми, ай саен, атна саен садака бир. Мәчеткә генә түгел, авыру балаларга, йорт-җирсез калучыларга, мохтаҗ күршеләреңә булдыра алганча ярдәм ит. Шулай ук мөһим сорау ул – әрвахларыбызның бурычлары калса, аларны һичшиксез кайтарырга кирәк. Әгәр инде әҗәткә бирүче бурычны кичерсә, бу аңа бик саваплы булыр һәм туганнарыннан бурычны кайтару йөге дә төшәр.

Ий Раббыбыз, кылган гамәлләребездән разый булуыңны сорыйбыз. Бакыйлыкка күчкән барча мөселман кардәшләребезнең рухларын тыныч вә шат кыл, аларны кабер газапларыннан, җәһәннәм утыннан саклап, җәннәтләреңә керт! Безне дөнья борчуларыннан сакла, сабырлыклар бир. Ий Аллаһым, тормышыбызны, үлемебезне һәм ахирәт тормышыбызны хәерле, матур кыл. Зур ышану белән буйсыну, ярату, курку белән мөрәҗәгать итү мөмкинлеген бир. Тәүбә күз яшьләребезне кабул кыл. Синең хозурыңа хәерле кол булып кайтырга ярдәмең насыйп ит!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Мирхәт хәзрәт Җамалиев,*
*Апас районының имам-мөхтәсибе*

*26 нчы июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Никахның әһәмияте

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрне, күкләрне, җирләрне, җирдәге барча мәхлукатларны юктан бар кылып, безләрне Үзенең санап бетереп булмый торган сый-хөрмәтләрендә, нигъмәтләрендә яшәтүче, ризыкландыручы, тәрбияләп торучы, гыйбадәткә лаек булган бердәнбер хак Илаһыбыз Аллаһы Сөбеханә вә Тәгаләгә хәмед-сәналәр, чиксез шөкерләребез булсын!

Җиргә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен алып килүче, Аллаһының Илчесе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһының сәламе һәм йөрәк түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булсын. Йә Раббым, безгә Кыямәт көнендә аның шәфәгатен насыйп әйлә. Җир йөзенә килеп киткән барча пәйгамбәрләргә, аларга хаклыкта иярүчеләргә, изге иман әһелләренә догаларыбызны ирештереп, Үзеңнең рәхмәтеңне һәм ярдәмеңне бир.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, Аның ризалыгын өмет итеп, мәчетебезгә җомга намазына җыелдык. Йә Раббым, укыган намазларыбызны кабуллардан кылсаң иде. Шушында сөйләгән вәгазьләр белән вәгазьләнеп, сөйләүчегә дә, тыңлаучыларга да хәерле гамәлләр кылырга һәм Үзеңнең ризалыгыңа ирешергә насыйп итсәң иде!

Ислам дине һәркайсыбызны тәртипкә чакыра, мәрхәмәтле булырга өнди. Аллаһы Тәгалә ир-егет һәм хатын-кызларыбызга хәләл гаилә корып, тәртипле рәвештә яшәргә куша. Ир белән хатыннарның никахлы булып

яшәүләре – Раббыбыз тарафыннан безгә бирелгән бер нигъмәт. Әгәр дә кешеләр никахлашып яшәмәсә, җирдә бозыклык, гөнаһ таралыр иде. Никахлашмыйча гына яшәгәннәр арасында булган бозык гамәлләрне үз күзләребез белән күреп, колакларыбыз белән ишетеп торабыз. Ятим балалар, яман чирләр белән авырган кешеләр – бу никахсыз яшәүнең нәтиҗәләре.

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُم مِّن نَّفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً ۚ

**«Ий кешеләр! Сезне бер җаннан** [Адәмнән] **яраткан, аның бер кисәгеннән** [булган сул кабыргасының иң астыннан Хава исемле] **ишен яраткан һәм аларның икесеннән бик күп ирләр белән хатыннарны халык кылып** [җиһанга] **тараткан Раббыгыздан куркыгыз...»**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:1

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дә гаилә коруы мөселманнарга үрнәк булып тора. Ул өйләнмичә яшәүне яратмады. Бер егеттән: «Мин беркайчан өйләнмәм, Аллаһыга гына табынып торырмын», – дигән сүзләрне ишеткәч, болай дип әйтте: «Мин никахлашам, хатыннарга өйләнәм, кем дә булса, хәленнән килеп тә, өйләнүдән баш тартса, ул бездән булмас». Бу хәдис безгә никахлашуның сөннәт гамәл икәнлеген аңлата.

Өйләнмичә, зина кылып йөрүчеләр гаиләләр арасында бозыклык тарата, шунлыктан алар ике дөньяда да Раббыбызның хәсрәтендә булыр. Зина кылу ул – җиде олы гөнаһларның берсе. Әмма бу начар гамәл бүген киң таралыш алган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә болай дип әйткән: «Адәм баласын бу дөньяда да, киләчәк ахирәттә дә һәлак итә торган җиде төрле гөнаһтан куркыгыз!» Сәхабәләр Аллаһының Илчесеннән:

«Ий Расүлуллаһ, син безгә ул гөнаһларны әйтеп үтмәссеңме?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгаләгә ширек кылу, гаепсез кешене үтерү, зина кылу, сихер белән мавыгу, ятимнәрнең ризыгын ашау, гаепсез хатын-кызларны төрле гөнаһлы гамәлләрдә гаепләү, сугыш кырыннан качып китү», – дип җавап биргән.

Кайбер яшьләребез, кызганыч, аңлапмы, аңламыйчамы, әти-әни фатихасын да алып тормыйча, качып кына өйләнешеп куялар. Яки бөтенләй никахлашмыйча, ЗАГСка да бармыйча, бергә яши башлыйлар. Менә бу инде зина кылуның бер төре. Хайваннар кебек никахсыз да яшәп була, әлбәттә. Никахсыз гаиләдә үскән балалар картайган көнебездә безгә кадер-хөрмәт күрсәтерме? Никах ул – Аллаһы Тәгалә каршында, шаһитлар алдында бер-береңнең һәм әти-әниеңнең ризалыгы белән яши башлау. Ә хәзерге вакытта кайсылары әти-әни ризалыгын сорап та тормыйлар. Әти-әни киңәшләренә борылып та карамыйлар. Гомер буе яшәр өчен яр сайлыйлар, ә аның нинди нәселдән булуына да, динлеме, нинди милләттән икәненә исләре дә китми. Чәче озын, буе зифа, биле нәзек булса, шул җиткән, дип фикерлиләр. Матурлык бит бер көнлек, ә алда – озын тормыш юлы. Шул юлларны узар өчен, акыллы, тәкъва, югары әхлаклы тормыш иптәшең булса, күпкә җиңелрәк.

Авылда яшәгән кеше бер-берсен күрә, аралаша, бер-берсенең нәселен яхшы белә. Яшьләрне: «Бу нәселнең янына бара күрмә, бу егет кеше белән аралашма», – дип кисәтәләр икән, әти-әнинең әйтүләре дә авыл балаларының колагына керә әле. Шуңа да балаларыбызга никахның җитдилеген аңлатып торырга, үз никахыбызга да хилафлык китермичә, аларга яхшы үрнәк булып яшәргә тиешбез.

Белгәнебезчә, 2024 ел Россия Федерациясендә Гаилә елы дип игълан ителде. Ник дигәндә, бүген ил күләмендәге мәсьәләләрнең берсе булып гаилә ныклыгы тора. Гаилә төзү, аны саклау, ныклы итү проблемалары бар. Гаиләләр нык булса, дәүләтебез дә нык булачак. Ныклы, тигез гаиләдән без

мәхәббәт, үз эшеңә җаваплы карау, бүтән кешеләрне хөрмәтләү дәресләрен алабыз. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١﴾

**«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яратуы һәм арагызда сөю** [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] **белән бер шәфкать** [чарасы булган бала] **бирүе дә – Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен** [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] **билгеләр бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:21

Аллаһы Тәгалә җир йөзендәге бар мәхлукатны да парлы-парлы кылды. Адәм балаларын да парлы итте. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрнәрсә парлы, Аллаһы бер Үзе генә ялгыз», – диде. Шуңа күрә дә, һәр йөрәк үзенең парын табарга, матур гаилә корырга омтылырга бурычлы.

Барча кешелек дөньясына үрнәк булган, Аллаһының иң сөекле коллары – пәйгамбәрләр дә – никахлаштылар. Аллаһы алар турында Коръәндә әйтә:

وَلَقَدْ أَرْسَلْنَا رُسُلًا مِّن قَبْلِكَ وَجَعَلْنَا لَهُمْ أَزْوَاجًا وَذُرِّيَّةً ۚ

«[Расүлем!] **Синнән алда да Без расүлләр җибәргән идек, аларга да хатыннар һәм балалар биргән идек».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:38

Коръән буенча, тигез гаилә ул – җан тынычлыгы алу юлы:

هُنَّ لِبَاسٌ لَّكُمْ وَأَنتُمْ لِبَاسٌ لَّهُنَّ

**«Алар – сезгә кием һәм сез – аларга кием».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:187

Әгәр кеше никахлашмый икән, аның күңеле, тән шәһвәтен басар өчен, ул зина юлын сайларга мөмкин. Ә зина – Аллаһы Тәгалә тарафыннан катгый рәвештә тыелган зур гөнаһ. Аллаһы Тәгалә безне: «Зинага якын да бармагыз, ул – бозыклык һәм кабахәт юлдыр», – дип кисәтә. Никах һәм никахлы тормыш безне зина, фахешләрдән саклый торган калкан кебек. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кайсыларыгыз гаилә мәшәкатьләрен күтәрә ала, шулар никахлашсын, чөнки никах карашны (тыелган әйберләргә караудан) төшерә һәм җенси әгъзаларны саклый».

Зина кылу сәбәпле, күпме гаиләләр җимерелә, ятим балаларның саны арта. Юл кырыенда, урманнарда, чүп савытларыннан үле бала гәүдәләре табылып тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Чиста булыгыз, хатыннарыгыз да (зинадан) пакь булырлар», – дип әйткән. Бервакыт Пәйгамбәребез янына бер яшь егет килеп: «Йә Аллаһының Илчесе, миңа зина кылырга рөхсәт бир», – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан: «Син, әниең зина кылса, риза булыр идеңме?» – дип сорый. Егет: «Җанымны бирәм, юк!» – ди. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янә: «Апаң кылса, риза булыр идеңме?» – дип сорый. Егет янә: «Җанымны бирәм, юк!» – ди. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әниеңнең бертуган сеңлесе кылса?» – дип сорагач, егетнең җавабы шул ук була. Шунда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Син зина кыласы хатын – кемнеңдер газиз анасы, кемнеңдер кадерле апасы яки сеңлесе», – дип әйтә. Яшь егет: «Аллаһы белән ант итәм, зинага якын да бармаячакмын», – дип китеп бара. Без дә бу хакта бераз уйланыйк. Зина кебек пычрак гамәлне үз анабызга, сеңлебезгә, үз кызыбызга кайсыбыз теләр икән?

Әмма, ни кызганыч, бүген зина гадәти күренешкә әверелеп бара. Зина кылучы халык үзен Аллаһының газабына дучар итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кайсы гына җирлектә зина белән риба ачык рәвештә кылынса, ул җирлеккә Аллаһының газабы хәләл булды», – дип әйткән. Лут пәйгамбәрнең халкы никахтан баш тартып, бозыклыкта яшәүне

өстенрәк күрә иде. Аллаһының фәрештәсе ул җирләрне тамыры белән һавага күтәреп, өстен аска әйләндереп җиргә каплап куйды. Бу хакта Аллаһы Тәгалә хәбәр итә:

فَلَمَّا جَاءَ أَمْرُنَا جَعَلْنَا عَالِيَهَا سَافِلَهَا وَأَمْطَرْنَا عَلَيْهَا حِجَارَةً مِّن سِجِّيلٍ مَّنضُودٍ ﴿٨٢﴾

> «**Безнең** [Лут (галәйһиссәлам) кавеменең һәлак ителүе хакындагы газап] **әмеребез килгәч,** [алар яшәгән җиде шәһәрне Җәбраилнең канаты белән астын өскә китереп] **өстен аска әйләндердек һәм аларга бер-бер артлы каткан балчыктан ташлар яудырдык».**

«Һуд», 11:82

Аллаһының рәхмәте, элекке вакытта никах укытуларны качып-посып кына үткәрделәр. Ә хәзер бернинди тыюлар юк, теләгән һәркем, өенә кунак җыепмы, Аллаһы йорты мәчеткә барыпмы, никахлаша ала. Тик шунысы бар: яшьләребез өчен «никах» сүзе «дустым укытты, мин дә укытам»га гына калмасын иде. Ни кызганыч, әмма андый очраклар да була шул. Аллаһы Тәгаләдән, аның кушканыннан куркып түгел, мәчеттә матур фотога төшәр өчен килүчеләр очрый. Никахның асылына төшенеп бетә алмыйлар. Монда инде әти-әниләрне генә гаепләп булмый. Ата-аналар, балалары өчен Аллаһы каршында җаваплы булсалар да, тәрбия дәресләрен мәктәптә, кечерәк сыйныфлардан ук алып барырга кирәк. Әмма, мәктәп җитәкчелеге мәчет әһелләре килеп, әхлак дәресләре үткәрүдән нигәдер курка. Мәктәптән чыгып киткәч, балалар тәрбияне «урамнан» ала башлый шул. Шуңа да күп очракта егетләр ата-анадан кызларын балага узгач кына килеп сорыйлар.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр кеше зина кылса, аның иманы аннан чыгар һәм башы өстендә күләгә сыман булыр, ә шушы гамәлен, ягъни зинаны, тәмамлагач, иманы кире кайтыр». Әгәр дә кеше зина вакытында үлеп китсә, имансыз булып дөньядан

китәчәк түгелме? Ә имансызның урыны – җәһәннәм. Тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: «Кем дә кем ике ирене һәм ике аягы арасындагы әгъзаларын харамнан тыйса, мин ул кешегә җәннәтне вәгъдә итәм». Моннан аңлашылганча, шушы ике әгъзасына хуҗа була алмаган кеше – бу дөньяда хурлыкка, түбәнлеккә төшеп, ахирәттә исә зур газапларга дучар булучыдыр.

Шулай итеп, Ислам дине зинаны катгый рәвештә тыя һәм зинага илтә торган бөтен юлларга киртә куя. Билгеле ки, нык иманлы мөэмин-мөселманнар моны яхшы аңлыйлар, һәм бу мәсьәләдә бер дә икеләнмичә, Аллаһы кушканына итагать кылалар. Ләкин иманнары зәгыйфь булганнар әлеге яман гамәлнең дөньяви зарарын аңламыйлар. Кияүгә чыкканчы зина кылган кыз, картайганчы ире тарафыннан хурлыклы шелтәләргә дучар булып яшәргә мөмкин. Өйләнгәнче зина юлында йөргән егет исә, гаилә коргач та, элеккегечә зина кыла, никахына хыянәт итеп, хәләл җефетен алдауга керешә.

Имам әш-Шәфигый болай дип әйткән: «Зина ул – әҗәт. Әгәр шул әҗәтне өстеңә алсаң, үз гаилә әһеле белән түлисең була...» Шулай итеп, әгәр кеше зина кыла икән, көннәрдән бер көнне ул шушы зинаның «әҗәтен» йә хатыны, йә кызы, йә башка гаилә әһеле белән түләячәк, ягъни зиначының якын кешесе зина юлына басар. Аллаһы сакласын. Шуңа күрә дә элек: «Нәселегезгә зиначыны кертә күрмәгез», – дип, яшьләрне кабат-кабат кисәткәннәр. Коръәндә дә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

الزَّانِي لَا يَنكِحُ إِلَّا زَانِيَةً أَوْ مُشْرِكَةً وَالزَّانِيَةُ لَا يَنكِحُهَا إِلَّا زَانٍ أَوْ مُشْرِكٌ ۚ وَحُرِّمَ ذَٰلِكَ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ ﴿٣﴾

**«Зина кылган ир зина кылган бер хатыннан яки ширек кушкан бер хатыннан башкага өйләнми. Зина кылган хатынны исә, аны зина кылган бер ир яки ширек кушкан бер ир генә хатынлыкка ала.**

**Бу** [зиначыларга өйләнергә яки кияүгә чыгарга] **иман китерүчеләргә харам кылынды».**

«Ән-Нур», 24:3

Ягъни азгын ирләр азгын хатыннарга булсын, һәм азгын, пычрак хатыннар шундый ук ирләргә булсын, ди. Олы яшьтә булган зиначылар белән Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә бөтенләй сөйләшеп тә тормас, аларны берсүзсез җәһәннәмгә билгеләр.

Бер көнне бер сәхабә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән болай дип сораган: «Әй Расүлуллаһ! Аллаһы алдында иң зур гөнаһ нинди?» Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм җавап итеп: «Аллаһыга тиңдәш кату. Үзеңә ашарга ризык җитмәс, дип, балаңны үтерү. Күршенең хатыны белән зина кылу», – дигән.[1]

Янә башка хәдисләрдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ди: «Әгәр зина өчен бирелә торган газапларның яманлыгын минем кебек белгән булсагыз, әз көлеп, күп елар идегез».[2] «Төшемдә бәдрәфтәге нәҗәсәт кебек начар ис аңкып торган кешеләрне күрдем. Аннан соң боларның зина кылучылар икәнен белдем».

Инде барыбыз да белгәнчә, Пәйгамбәребезнең салләллаһу галәйһи вә сәлләм төшләре изге булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук болай дигән: «Әй кешеләр! Зинадан сакланыгыз! Чөнки зинаның алты төрле нәтиҗәсе бар. Аларның өчесе бу дөньяда күренер, өчесе – ахирәттә. Бу дөньяда зиначы кешенең йөзе үз гүзәллеген һәм нурын югалтыр, бөлгенлеккә төшүе һәм гомеренең кыскаруы бар. Ахирәттә исә: Аллаһы Тәгалә зиначыга ачуланыр, хисап алуы бик авыр булыр, (зинаны хәләл гамәл дип санаган булса,) мәңгелеккә җәһәннәмдә калыр».[3]

1 Әл-Бохари.

2 Әл-Бохари.

3 Әл-Куртуби.

Бу дөньяда яшәгәндә кеше гөнаһсыз булмый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм «мин гөнаһсыз» диючене, елга аша чыккач, «киемем коры» дип алдаучы кеше белән чагыштырган. Кешенең киеме керләнгән кебек, белеп һәм белми кылган гөнаһлардан күңеле дә карала. Шуңа да Аллаһы Тәгалә ирләргә дә, хатын-кызларга да карарга ярамый торган әйберләргә күзне йомарга, гаурәтләребезне яшерергә кушкан. Хәтта уйларыбызга да игътибарлы булырга кирәк. Кешенең башында нинди генә фикерләр йөрми бит. Пычрак уйлардан арынырга кирәк. Яшьләргә һәм балаларга зинаның зур гөнаһ булуын аңлатырга, аларны ялгыш юллардан сакларга кирәк. Динне өйрәнсеннәр, намаз укысыннар.

Корьәндә:

وَأَقِمِ الصَّلَاةَ ۖ إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ ۗ

**«...** [фарыз] **намазны укы, чөнки** [тышындагы һәм эчендәге бөтен шарт һәм әдәпләренә туры китереп, камил дәрәҗәдә укылган] **намаз** [зина кебек] **әшәкелекләрдән дә,** [шәригатьтә дә, акыл белән дә] **гаеп саналганнардан да саклый»**, – диелгән.

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:45

Без дөрес яшәп, ялгышлардан ерак булсын өчен, Аллаһы Тәгалә безгә Ислам динен бирде. Безнең әти-әниләр буларак зур бурычыбыз – үзебездән соң динле, тәрбияле, югары әхлаклы бала үстереп калдыру. «Аллаһы Тәгаләнең дөрес яшәмәгән кешеләргә беренче җәзасы – юлдан язган бала», – диде Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе. Без бүген байлык җыябыз, йорт салабыз, машина алыштырабыз, әмма балаларыбызга рухи тәрбия бирергә вакыт тапмыйбыз. Гаилә, бала тәрбияләү беренче урында булырга тиеш икәнлеген онытып җибәрәбез.

Егетләребез арасында кызларның тышкы матурлыгына гына караучылар да юк түгел. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм андыйларга бер хәдисендә болай дип әйтә: «Хатын-кызга дүрт билге буенча

өйләнәләр: аның байлыгына карап, дәрәҗәсенә күрә, матурлыгы аркасында һәм диндарлыгына карап. Диндарлыгын исәпкә алып үзеңә тормыш иптәшен сайла, һәм сиңа уңыш килер».[1]

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләреннән шуны аңларга була: үзең өчен тәкъва хатын сайласаң, бу, әлбәттә, хәерлерәк. Әмма бу матур хатын сайларга ярамый, дигәнне аңлатмый. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм никахлашыр алдыннан хатын-кызга карарга кушты, алдагы көндә ир белән хатын арасында мәхәббәт сүрелмәсен өчен. Кияү белән кәләш бер-берсенә ошамаса, алдагы көндә бу гаиләдә аңлашылмаучанлыклар килеп чыгуга китерә. Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына ансарлардан булган бер кеше килә һәм бер хатын-кызга ярәшергә теләвен әйтә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан: «Син ул хатын-кызны күрдеңме?» – дип сорый. Ул: «Юк», – дип җавап кайтара. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм барып күрергә куша.[2]

Мөселман кеше үзенең хатыныннан һәрьяктан да канәгать булырга тиеш. Аның матурлыгыннан да, иман дәрәҗәсеннән дә. Хатын-кыз да үзенең иреннән канәгатьлек күрсәтергә тиеш. Күп хатын-кызлар ирләре тапкан малдан канәгать булмыйлар, ирләрен төрлечә түбәнсетергә тырышалар: «Мин синең белән гомерем буе игелек күрмим, хәерчелектә яшибез», – ише сүзләр әйтеп, ирләрен рәнҗетәләр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Кайсы хатын иң хәерле хатыннардан санала?» – дип сораганнар. Ул: «Ире аңа караса, ирен сөендерүче; ире берәр нәрсә кушса яки берәр ошамаган ягы булса, аңа буйсынучы һәм иренең малына каршы килмәүче», – дип җавап биргән.[3]

1 Әл-Бохари, Мөслим.

2 Ән-Нәсаи, Ибне Мәҗә.

3 Әхмәд.

Яшь мөселман гаиләләре Аллаһының Китабын, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен үзләренең яшәү рәвешләрендә кулланырга тиеш. Башка бер генә диндә дә хатын-кызларга Ислам динендәге кебек ихтирам юк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Хатыннарыгыз белән һәрвакытта да яхшы мөгамәләдә булыгыз, чынлыкта, хатын-кыз кабыргадан яратылган, бигрәк тә ул кәкрелек аның өске өлешендә аерылып тора, әгәр син аны турайтырга тырышсаң, син аны сындырачаксың, әгәр син аңа тимәсәң, ул кәкре килеш калачак, шуңа күрә хатыннарыгыз белән яхшы мөгамәләдә булыгыз!»[1]

Бу сүзләрдән шуны аңлыйбыз: хатын-кызның табигатенә генә хас булган кимчелекле яклары да булачак. Шуңа күрә күпчелек вакытта хатын-кыз ире теләгәнчә генә булып бетә алмый. Аллаһы Тәгалә аларны ничек итеп яратканлыгын онытмыйк. Хатынның зәгыйфь җенес икәнен исәпкә алсак, гаиләдә тынычлык һәм бәхет хөкем сөрер, тавыш, ызгыш-гауга булмас.

Ир кеше – гаиләне алып баручы, саклаучы, ризык алып кайтучы. Ул – үзенең гаиләсе өчен Аллаһы Тәгалә каршысында җавап тотучы. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Сезнең һәрберегез – көтүче, һәм һәрберегез үзенең көтүе өчен җавап бирәчәк».[2] Ир кешегә Аллаһы Тәгалә болай боерды:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ عَلَيْهَا مَلَائِكَةٌ غِلَاظٌ شِدَادٌ لَّا يَعْصُونَ اللَّهَ مَا أَمَرَهُمْ وَيَفْعَلُونَ مَا يُؤْمَرُونَ

**«Ий иман китерүчеләр!** [Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып] **Үзүзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз,** [башка утларның

---

[1] Әл-Бохари, Мөслим.

[2] Әл-Бохари, Мөслим.

> ягулыгы утын булса] **аның ягулыгы** [кяфер] **кешеләр һәм** [бик тиз кабынып, бик күп яндыра торган күкерт] **ташлар».**
>
> «Әт-Тәхрим / Тыю», 66:6

Гаилә башлыгы буларак, мөселман ир кеше гаиләсендә булган серләрне саклый, беркайчан да тышка чыгармый. Хатынын башкалар янында беркайчан да авыр хәлдә калдырмый, әгәр хатынының берәр җитешсез ягы булса, башкалар янында әйтми, моның өчен кирәкле вакытны һәм кирәкле урынны сайлый. Ир-ат хатынының туганнары хакында, ата-анасы хакында начар сүзләр әйтергә тиеш түгел, чөнки бу аны кимсетергә мөмкин. Хатынының туганнарына, ата-анасына хөрмәт белән карарга тиеш. Шулай ук үз ата-анасын да ихтирам итәргә тиеш.

Раббыбыз ирләрне көчле зат итеп яратты, алар гаиләләре өчен тулаем җаваплы, ә хатын-кыз йорт өчен җаваплы, балалар тәрбияләү дә – нигездә хатын-кыз өстендә. Ир белән хатын арасында һәрвакыт яхшы мөгамәлә булырга тиеш. Шулай ук хатын-кыз иренең сүзеннән чыкмый, аннан рөхсәт алмыйча, киңәш сорамыйча, бер эшне дә эшләми. Хатын-кыз иренә шәригать кушкан гамәлләрдә буйсынырга тиеш, чөнки ир кешенең хатынына күрә хакы бик зур. Моңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләре дәлил булып тора: «Әгәр дә миңа берәр кешегә сәҗдә кылырга кушарга туры килсә, мин хатын-кызларга ирләренә сәҗдә кылдырыр идем».[1]

Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, ирен риза итеп яшәгән хатын, җәннәтнең сигез капкасының кайсыннан теләсә, шунсыннан керәчәк.[2] Әгәр берәр хатын-кыз, ире аннан разый булмаган хәлдә вафат булса, ул җәһәннәмдә җәзаланачак, Аллаһы сакласын.

Мөселман дөньясында таныштырып, димләп өйләндерү, кияүгә бирү гадәте бар. Андый очракта, яучы җибәрер алдыннан, соратылачак кызның нәсел-нәсәбе һәм холык-фигыле, әхлагы хакында да белешү кирәк. Холык-

1 Әт-Тирмизи.

2 Ибне Мәҗә, әл-Хәким.

фигыле яман булып, кызны бары тик чибәр булган өчен генә сайлау бик үк дөрес булмас. Өйләнергә теләгән мөселман егете холкы тыйнаграк булган кызны алырга тырышсын. Кияүгә чыгарга ниятләгән кыз исә үзеннән бик күпкә олы булмаган, саран булмаган, киң күңелле, тәрбияле, әдәпле-әхлаклы мөселман ир-егетенә барырга тырышсын. Кызның әти-әнисенә кияүгә чыгу яшенә җиткән кызны үз вакытында кияүгә бирергә кирәк.

Бер-береңә юл куеп яшәү сабырлыкка нигезләнгән. Гаилә тормышында сабырлык зур әһәмияткә ия. Сабырлык җитмәгәндә никахны саклап калу бик авыр. Никах нык булсын дисәк, ике як та сабыр булып, бер-берсен гафу итә белергә тиеш.

Ир белән хатын бәхетле гаилә корып яшәсен өчен, дини белемле булып, тормышта шул белемнәрне куллана белергә тиеш. Әгәр дә барыбыз да Ислам кушканча яши алсак, бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешербез, иншәАллаһ.

Раббым Аллаһы, барыбызны да никахның әһәмиятен аңлап, имин гаиләләрдә сау-сәламәт итеп яшәтсәң иде. Кушканнарыңны үтәп, тыйганнарыңнан тыелып, Үзеңнең ризалыгыңа ирешергә, вәгъдә кылган җәннәтләреңә керергә һәрбарчабызга да насыйп итсәң иде. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Зөфәр хәзрәт Галиев,*
*Әтнә районының Ташчишмә авылы имам-хатыйбы*

*2 нче август вәгазе,*

*мөхәррам аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Биләл радыяллаһу ганһенең тормышыннан дәресләр

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактауларыбыз безне юктан бар кылган Раббыбыз Аллаһыга булса иде. Аның хак Расүле, безгә динебезне өйрәтер өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Бүген, Аллаһы насыйп итсә, Биләл радыяллаһу ганһе турында сөйләшербез. Аллаһы тел ачкычлары биреп, хәерле вәгазьләр сөйләргә насыйп кылса иде. Сөйләгән кешегә дә, тыңлаган кешегә дә шушы вәгазьләр белән вәгазьләнеп, күбрәк гыйлем алырга язсын иде.

Биләл радыяллаһу ганһе Мәккәдә туган. Чыгышы белән ул Хәбәштаннан булган, без хәзер ул илне Эфиопия дип атыйбыз. Һәм күпчелек тарихи риваятьләр буенча, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм туганнан соң өч ел узгач туган. Аның тулы исеме – Әбү Габдулла Биләл бине Әби Рабах. Димәк, аның әтисенең исеме Рабах булган, ә әнисен «Хәмама» дип йөрткәннәр. Аның әнисе кол итеп алынган, ә ул үзе Үмәйя бине Халәф исемле кешегә сатылган. Ә Үмәйя бине Халәф Исламның көчле дошманнарының берсе булган. Дус-иптәшләре сурәтләгән буенча, Биләлнең тән төсе кара, буе озын, гәүдәсе арык булган.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең пәйгамбәрлеге турында игълан иткәч һәм Исламга чакырып вәгазьли башлагач, Биләл радыяллаһу ганһе

потларга табынудан баш тарта. Ул иң беренчеләрдән булып Ислам динен кабул итә. Берникадәр вакыттан соң Үмәйя бине Халәф Биләл радыяллаһу ганһенең Исламга килүе турында белеп ала һәм аны газаплый башлый. Үмәйя бине Халәф аны чүлдә кызган комга ташлый һәм аның күкрәгенә авыр таш куйдыра, бу таш астында Биләл хәтта селкенә дә, тора да алмый. Шуннан соң Үмәйя аңа: «Исламнан баш тартмасаң, шулай үләчәксең дә!» – ди. Ләкин Биләл радыяллаһу ганһе фәкать: «Әхәд» (Аллаһы бер), «Әхәд» (Аллаһы бер) – дип кабатлый. Янә аны төн буе камчы белән камчылаганнар, ә көндез, Исламнан баш тартсын яки алган яраларыннан озак һәм газаплы үлем белән үлсен өчен, яраланып беткән килеш кызган комга ташлаганнар. Аны җәфалаучылары – Әбү Җәһел, Үмәйя һәм башка мөшрикләр – аны җәфалап шулкадәр арый торган була, хәтта аны чиратлап җәфалыйлар, һәм аңа авырту-газап китерүдә бер-берсе белән ярышалар. Ләкин Биләл радыяллаһу ганһе бирешми, ул сынауларны уңышлы үтә. Биләл радыяллаһу ганһе мөшрикләрдән шундый газаплар күреп, сынмый калган бердәнбер кеше булган. Биләлне газаплаулары турындагы хәбәр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кайбер дусларына барып ирешә, һәм алар бу хәбәрне аңа җиткерәләр. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Биләлне азат итү турында сөйләшүләр алып барырга Әбү Бәкерне җибәрә, ул аны сатып алырга яки мөселман булмаган колга алыштыру турында сөйләшергә куша.

Аллаһының рәхмәте белән, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе Биләлне сатып ала. Үмәйя бине Халәф аны 10 алтынга сата. Үмәйя көлеп: «Әгәр син сатулашсаң, мин аны 1 алтын тәңкәгә дә биргән булыр идем», – ди Әбү Бәкергә. Ә ул: «Әгәр син 100 алтын сорасаң да, мин аны барыбер сатып алыр идем», – дип әйтә. Сатып алгач та, Әбү Бәкер аны коллыктан азат итә. Аллаһы Раббыбызның кодрәте киң, рәхим-шәфкате иксез-чиксез.

Аллаһының Расүле Мәдинәгә һиҗрәт кылгач, ул мөселманнарны җәмәгать намазына җыя, алар бергә җыелып, намаз вакыты җиткәнен көтә торган булалар. Ул вакытта аларны беркем дә намазга азан белән чакырмаган. Биләл – намазга чакыручы беренче кеше һәм Пәйгамбәребез салләллаһу

галәйһи вә сәлләмнең мөәзине булган. Сөекле Пәйгамбәребез тарафыннан аңа ике дәрәҗә бирелгән. Беренчесе – «әл-Хазим» (сакчы), икенчесе – «әл-Мүәззин» (мөәзин).

Шулай ук бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Һәр пәйгамбәрнең җиде ярдәмчесе һәм яклаучысы булган, миңа исә күбрәк бүләк ителгән. Бу: Гали, Хәсән һәм Хөсәен, Хәмзә, Әбү Бәкер, Гомәр, Мосгаб бине Гомәййр, Биләл, Салман, Гаммәр бине Ясир, Габдулла бине Мәсгуд, Әбү Зәрр һәм әл-Микъдәд».

Азанның тарихына килгәндә, бу хакта озын ышанычлы хәдис билгеле. Бервакыт мөселманнар намаз вакытының җитүен җәмәгатькә ничек хәбәр итәргә кирәклеге турында фикер алыша башлаганнар. Кайберәүләр, христианнар кебек, чаң (кыңгырау) кагарга тәкъдим иткән. Башкалар исә, яһүдиләр кебек, быргы кычкыртырга киңәш иткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бу алымнар ошамый. Икенче көнне иртән Габдулла бине Зәйд әл-Әнсари Аллаһының Илчесе янына килә һәм бу төндә күргән искиткеч төшен сөйли:

«Төшемдә мин яшел киемле ирне күрдем. Ул кулына кыңгырау тотты һәм мин аңа мөрәҗәгать иттем: «Ий Аллаһының колы! Син бу кыңгырауны сатмыйсыңмы?» Ул: «Ә син аның белән нәрсә эшләячәксең?» – дип сорады. Мин: «Без аның ярдәмендә кешеләрне намазга чакырачакбыз», – дип җавап бирдем. Ул миңа: «Сиңа моннан яхшыракны хәбәр итәргәме?» – дип сорады. Мин: «Ә нәрсә яхшырак?» – дип сорадым. Ул болай дип әйтте: «Аллаһы олуг. Аллаһы олуг. Аллаһы олуг. Аллаһы олуг. Шәһадәт китерәмен: Аллаһыдан башка илаһ юк! Шәһадәт китерәмен: Аллаһыдан башка илаһ юк! Мөхәммәд – Аллаһының Расүле, дип шәһадәт китерәмен. Мөхәммәд – Аллаһының Расүле, дип шәһадәт китерәмен. Намазга ашыгыгыз! Намазга ашыгыгыз! Уңышка ашыгыгыз! Уңышка ашыгыгыз! Аллаһы олуг. Аллаһы олуг. Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаек иләһ юк».

Габдулла бине Зәйд дәвам итә: «Мин бу төшне Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сөйләгәч, ул: «Дөреслектә, төшең хак,

иншәАллаһ», – диде һәм миңа Биләл радыяллаһу ганһе янына барырга һәм аңа төшем турында сөйләргә кушты. Шуннан соң Биләл кешеләрне намазга чакыра башлады. Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе азанны үз өендә булганда ишеткән. Ул, ашыгып, чапанын кия-кия чыгып, Аллаһының Илчесенә: «Сине хаклык белән Җибәрүче белән ант итәм, йә Расүлуллаһ! Мин шундый ук төш күрдем», – дип әйтте. Һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Лилләһил-хәмд – барча мактаулар Аллаһыга», – дип әйтте».[1]

Биләлнең тавышы бик матур булган, шуңа Пәйгамбәребез нәкъ аны мөәзин итеп сайлаган. Ләкин моның хикмәте дә бар: кайчандыр кол хәлендә чүлдә зур таш белән бастырылып яткан Биләлнең тавышын беркем ишетмәсә, хәзер аның азаны бар Мәдинәгә таралган. Икенче хикмәт: кайчандыр Биләл курыкмыйча шәһадәт кәлимәсен әйтеп, аны моның өчен үтерергә тырышсалар, хәзер ул шул ук тавышы белән көненә биш мәртәбә мөселманнарны намазга чакырган.

Хәзрәти Сәгъд радыяллаһу ганһе тапшыра: «Бервакыт без Габдулла бине Мәсгуд һәм Биләл радыяллаһу ганһүмә белән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында идек. Аның янына берничә бай Мәккә мөшриге килеп: «Башта бу кешеләр чыгып китсеннәр, аннары без сөйләшербез», – диделәр (ягъни бу бай, дәрәҗәле мөшрикләр фәкыйрь-мохтаҗ булган сәхабәләр янәшәсендә хәтта утырырга, сөйләшергә дә теләмәделәр). Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр аларны чыгарсам, мөшрикләрнең йөрәкләрен яулый алырмынмы, алар Исламга күбрәк тартылырлармы?» – дип уйга кала. Шул чак түбәндәге аять иңдерелә:

وَلَا تَطْرُدِ الَّذِينَ يَدْعُونَ رَبَّهُم بِالْغَدَاةِ وَالْعَشِيِّ يُرِيدُونَ وَجْهَهُ ۖ مَا عَلَيْكَ مِنْ حِسَابِهِم مِّن شَيْءٍ وَمَا مِنْ حِسَابِكَ عَلَيْهِم مِّن شَيْءٍ فَتَطْرُدَهُمْ فَتَكُونَ مِنَ الظَّالِمِينَ ﴿٥٢﴾

---

[1] Әхмәд, Әбү Давыд, әт-Тирмизи.

«[Расүлем!] **Иртә-кич** [дәвамлы рәвештә] **Раббыларына гыйбадәт кылган һәм Аның Затына омтылган кешеләрне кума.** [Мөшрикләр аларның иманнарында ихласлы булмаганнарын, синең янында яшәүтуклану өчен калганнарын әйтсәләр дә] **Аларның** [кылган гамәлләр] **хисабыннан бернәрсә дә** [җаваплылык] **синдә юк, синең** [кылган гамәлләр] **хисабыңнан бернәрсә дә** [җаваплылык] **аларда юк. Аларны кусаң, залимнәрдән булырсың».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:52

Сәгъд радыяллаһу ганһе горурлык белән: «Бу аять безнең өчен иңдерелгән иде», – дип әйтә. Аллаһы Тәгалә Үзе мактаган кешеләр белән кем тиңләшә ала соң?! Аллаһыга хезмәт итүнең бөтен мәгънәсе – Аның ризалыгына ирешү. Бу кешеләр исән чакта ук Аллаһының алардан риза-канәгать булуы турында яхшы хәбәр алган.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән хәбәр ителә: «Бервакыт иртәнге намаз вакытында Аллаһының илчесе Биләл радыяллаһу ганһедән болай дип сорады: «Ий Биләл, Исламда кылган эшләреңнең кайсысы сиңа файда китерә? Мин синең аяк тавышларыңны җәннәттә ишеттем», – ди. Биләл радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Мин эшләгән эшләрнең берсе дә миндә шулкадәр өмет уятмый, илләмәгәр мин төнен дә, көндез дә тиешенчә тәһарәтләнәм дә, тәһарәттән соң һәрвакыт ике рәкәгать намаз укыйм». Ягъни һәр тәһарәт алганнан соң ике рәкәгать өстәмә намаз укып кую – ул сөннәт, бик әҗер-саваплы гамәл. Әмма ул намаз кылырга мәкруһ булган вакытка (ягъни кояш чыккан һәм баткан вакыт һәм кояш зәвәлдә булган вакытка) туры килмәскә тиеш. Һәм бу хәдистән Биләлнең әлеге сөннәтне калдырмавын күрәбез. Хөрмәтле дин кардәшләрем, без дә бөек сәхабәләребезнең, галимнәребезнең тормышын, аларның холкын, гадәтләрен үзебезгә дәрес алыр өчен, гыйбрәт алыр өчен өйрәнәбез. Аларга хас булган күркәм сыйфатларны үзебездә дә булдырырга тырышыйк.

Мәккә шәһәре мөселманнар кулына күчкәч, Кәгъбәтуллаһ потлардан азат ителгәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Кәгъбәгә беренче кеше итеп Биләл радыяллаһу ганһене кертә. Ул: «Биләл, тор, Кәгъбә түбәсенә менеп, азан әйт», – ди. Сөекле Пәйгамбәребез Әбү Бәкерне, яки Гомәрне, яки Габдрахман бине Гауфны, яки бүтән көчлерәк, бай гарәп кабиләсеннән булган, чибәррәк күренгән бер сәхабәсен сайлый алыр иде. Ләкин ул кайчандыр кол булган Биләл радыяллаһу ганһене сайлаган. Чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм расизм мәсьәләсен 1400 ел элек чишкән. Аның өчен раса, тышкы кыяфәт, байлык-дәрәҗә буенча кешеләрне аеру булмаган, динебездә бу юк. Бервакыт шундый вакыйга була: Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе Биләл радыяллаһу ганһегә «кара хатынның улы» дип әйтә һәм үпкәләтә. Биләл бу хәлне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәбәр итә. Һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әбү Зәррны чакырып: «Ий Әбү Зәрр, мин – Мөхәммәд, һәм мин кара хатынның улына да бертигез карыйм, мин – ак хатынның улы», – дип әйтә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе кара хатынның күкрәгеннән тукланды. Шул рәвешле, эфиоп булган кара тәнле Биләл радыяллаһу ганһе – Мәдинәдә дә, Мәккәдә дә беренче булып азан әйткән кеше.

Биләл радыяллаһу ганһе гомере буе Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең янәшәсендә булган. Юлда да, өйдә дә ул аның мөәзине булган. Һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм авырып киткәч, риваятьләрдә Биләл радыяллаһу ганһенең еш азан әйткәнлеге хәбәр ителә. Ул шул дәрәҗәдә Пәйгамбәребезне яраткан ки, аның вафатыннан соң, ул намазга азан әйтә алмыйча, елый башлаган, Биләлгә кушылып бар мәчет җәмәгате дә, Мәдинә халкы да елаган. Пәйгамбәрсез Мәдинә шәһәрендә кала алмавын аңлап, Әбү Бәкердән рөхсәт алып, Биләл Мәдинәдән Шам җирләренә күченеп киткән.

Гомәр радыяллаһу ганһе Әл-Кудс (Иерусалим) шәһәрен алганда, Биләл аңа кушылган, дигән фикер бар. Һәм ул мөселманнар өчен өченче иң изге мәчет булган әл-Әкъса мәчетендә азан әйткән, диелә.

Йомгаклап, тагын бер кат әйтеп үтәм, Биләл радыяллаһу ганһе Мәккәдәге әл-Харам мәчетендә, Мәдинәдә Пәйгамбәр мәчетендә һәм шулай ук әл-Әкъса мәчетендә азан әйткән. Болар барысы да – өч изге урын.

Һиҗри исәп буенча 20 нче елда Биләл радыяллаһу ганһе Димәшкъ шәһәрендә вафат була. Шулай ук ул хәзерге Иордания җирлегендә җирләнгән, дигән фикер дә бар. Ул үзеннән соң балалар да, бернинди байлык та калдырмыйча киткән. Ләкин Биләл радыяллаһу ганһе калдырган азан дигән искиткеч мирасны мөселманнар буыннан-буынга тапшыралар. Дөньяда көненә миллионнан артык азан әйтелә. Тагын бер мөһим нәрсә: «азан» дигән сүзнең тамыры гарәп телендә «рөхсәт» дигән мәгънәне бирә. Аерым әйткәндә, азан – намазны укырга рөхсәт ителгән вакыт җитү турында хәбәр бирү. Азанның тагын бер хикмәте дә бар. Коръән һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең догалары белән беррәттән, авыруларны, күз тиюдән интегүчеләрне, бозымсихердән газапланучыларны өшкерү өчен азан әйтәләр.

Аллаһы Тәгалә барчабызны Кыямәт көнендә сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Биләл радыяллаһу ганһе һәм башка бөек сәхабәләр белән берләштереп, Фирдәвес җәннәтләрендә очраштырсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рәшит хәзрәт Шәрифҗанов,*
*Әтнә районы Яңа Өҗем авылы мәчетенең имам-хатыйбы*

*9 нчы август вәгазе,*

*сафәр аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Коръән хафизларның дәрәҗәсе

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Безләрне юктан бар кылып, туры юл күрсәтеп, чиксез нигъмәтләре белән яшәтеп торучы Раббыбыз Аллаһы Сөбханәһу вә Тәгаләгә чиксез рәхмәтләребез, Аның Сүзен – Изге Коръәни Кәримне – безгә җиткерүче, аңлатучы сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булсын!

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Аллаһының күркәм исемнәренең берсе – «Әл-Гадел» – Гадел. Раббыбыз барча кимчелекләрдән пакь, Аның гаделлеге камил вә бар мәхлукларына ирешә. Бу гаделлекнең бер чагылышы булып Коръәни Кәрим тора. Бу Изге Китапта Раббыбыз безгә Үзе турында мәгълүмат җиткерә; галәмнәрнең, җир, күкләр, табигатьнең серләрен ача; кешеләр, фәрештәләр, җеннәр дөньясын аңлата; мәңгелек ахирәт тормышы, Кыямәт көне булачагы турында хәбәр итә һәм Үзенең әмерләрен биреп, шуларны үтәүче вә үтәмәүчеләрнең нинди әҗер алачакларын да әйтә. Әгәр дә Изге Коръән булмаса, без җәннәт һәм җәһәннәмнең барлыгын ничек белә алыр идек? Әмма гаделлеге белән Раббыбыз адәм баласына бөтен кирәкле мәгълүматны биргән, туры юлны күрсәткән, җәза һәм әҗер-савап биреләчәген әйткән, инде безгә дөрес гамәлләр сайлыйсы гына кала. Ә аларны сайлый белер өчен, туры юлдан тайпылмас өчен, нәтиҗәдә җәннәткә ирешер өчен, безгә Аллаһының Китабына мөрәҗәгать итәргә, аны укырга, фикер йөртергә, ятларга кирәк.

Беренче мөселманнар һәм борынгырак чорларда яшәүче дин кардәшләребез Коръәни Кәримне яттан өйрәнеп, аны төрле-төрле халыкларга, киләчәк буыннарга җиткерә иде. Үзебезнең татар әби-бабаларыбызны гына искә алыйк. Әгәр гаиләдә Коръән китабы булса, ул иң кыйммәтле, иң кадерләп саклана торган әйбер булган. Алар кайдадыр күченергә мәҗбүр булсалар, иң беренче эш итеп үзләре белән Коръән мосхафларын алганнар; дин тыелган чорларда аны яшерә-яшерә саклаганнар, балаларына укыганнар, яттан өйрәнгәннәр. Без бүген Аллаһының Сүзен шулай кадерле беләбезме? Әлхәмдүлилләһ, безнең һәрберебезнең өендә, бүген инде хәтта телефоннарыбызда Коръән китаплары бар. Әмма ул күңелләребездә, калебләребездә нинди урын ала, без яттан ничә сүрә беләбез?..

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Коръәни Кәримне ятлау аны үзләштерүнең төп ысулы булып тора. Аллаһы Тәгалә Изге Китабында болай ди:

بَلْ هُوَ آيَاتٌ بَيِّنَاتٌ فِي صُدُورِ الَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ ۚ

«[Башка китаплардан аермалы буларак, бер өстенлеккә ия булган] **Ул** [Коръән] **– гыйлем бирелгән** [хафиз һәм галим] **кешеләрнең күкрәкләрендә булган ап-ачык аятьләр».**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:49

Раббыбыз тәкъва колларының күңелләрен Үзенең Изге Китабын саклый ала торган сәхифәләргә тиң итте. Һәм моның белән безне, мөселман өммәтен, олылады.

Кодси хәдисендә Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә болай ди: «Мин сине (кешеләргә) сине сынар өчен һәм синең белән (аларны) сынар өчен җибәрдем. Һәм Мин сиңа Китап иңдердем, аны су белән юып юкка чыгарып булмый, син аны төшеңдә дә, өнеңдә дә укыячаксың».[1]

[1] Мөслим, «Сахих» № 2865.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең бөек нигъмәтләренең берсе – Ул безгә, Үзенең зәгыйфь колларына, Коръәни Кәримне ятлауны җиңеләйтте. Бу хакта Ул болай ди:

وَلَقَدْ يَسَّرْنَا الْقُرْآنَ لِلذِّكْرِ فَهَلْ مِن مُّدَّكِرٍ ﴿١٧﴾

**«Без Коръәнне, үгет алынсын дип, бик җиңел иттек, ләкин үгет алучылар бармы?»**

«Әл-Камәр / Ай», 54:17

Галимнәребез, бу аятьне тәфсир кылып, Аллаһы Тәгалә Коръән китабын ятлаучылар (ягъни булачак хафизлар) өчен җиңел итте, ди. Тәфсир галиме имам әл-Хазин бу аять хакында болай дип язган: «Бу аять Коръәнне ятларга өнди, чөнки Аллаһы Тәгалә аны җиңел кылды. Шуңа күрә Аның һәр колы – балалар да, олылар да, гарәп тә һәм башка милләт вәкиле дә – Коръәнне ятлый ала».

Чыннан да, хөрмәтле дин кардәшләрем, без Коръәнне ятлауда җиңеллек бирелүен күпсанлы мисаллардан күрәбез. Мөселман өммәтендә һәр дәвердә төрле милләт вәкилләреннән булган Коръән хафизлар бик күп булды һәм булачак та. «Хафиз» сүзе гарәп телендә нәрсәнедер саклаучыны белдерә, шуңа күрә Коръәнне тулысынча ятлап, аны үзләренең калебләрендә, хәтерләрендә саклаучы кешеләрне дә шулай атыйлар. Хафизлар, гарәпләрдән яки башка милләттән булсынмы, Коръәни Кәримнең бер сүзен дә, бер хәрефен дә үзгәртми, хата җибәрми. Хәтта гарәп милләтеннән булмаган хафизлар арасында гарәп телен белмичә, Коръәнне җиде яки ун кыйраәт белән яттан укый алучылар бар. Имам Әбү Хәсән әл-Мәвәрди (Аллаһының рәхмәтендә булсын) моны Коръәни Кәримнең бер могҗизасы дип санаган. Ул болай дигән: «Коръәннең могҗизаларының берсе – аның бар телләр өчен җиңел булуы. Хәтта телсез булган чит ил кешесе дә аны ятлый ала, ә башка китаплар алай истә калмый. Һәм бу фәкать Аллаһы биргән үзенчәлекләрдән, аны башка китапларыннан өстен куюыннан». Әлхәмдүлилләһ, җәмәгать, бүген без үзебез

дә шушы сүзләргә дәлилләрне күреп торабыз. Үзебезнең илебездә, Республикабызда гына да күпме Коръән хафизлар бар. Алар, безнең кебек үк, гарәп телен белеп, гарәп милләтеннән тумады. Араларында күзләре күрмәгән, сукыр, телсез-чукрак булган кардәшләребез дә бар.

Әгәр без олы галимнәребезнең тормыш юлларына күз салсак, иң әүвәл аларның Коръәнне ятлавын һәм шуннан соң гына башка гыйлемнәрне өйрәнә башлавын күрәбез. Аларның күпләре бик кечкенә булганда ук хафиз булган, чөнки Коръән – бар нәрсәнең нигезе, һәр эштә терәк һәм бар гыйлем-фәннәрнең төпле чыганагы ул. Шулай ук элек күпчелек остазлар, галимнәр балаларга, әгәр алар Коръәнне яттан белмәсә, хәдисләр яки башка фәннәрне өйрәтүдән баш тарткан. Бүген үзебезнең балаларыбызга күз салыйк. Алар көненә ничә сәгатен кулына телефон тотып, ничәсен Коръән тотып үткәрә? Ә бит бала бар күргән, укыганын аңына, хәтеренә сеңдереп бара. Баланы күпсанлы түгәрәкләргә, репетиторларга йөртәбез. Бу бик яхшы, әмма онытмыйк, балага дин нигезләрен бирү, Коръән укырга өйрәтү – безнең бурычыбыз. Моңа вакыт табыйк. Гаилә – баланың беренче мәдрәсәсе. Аның кайчандыр үзе теләп мәчет курсларына яки мәдрәсәгә йөри башлаганын көтәргә кирәкми. Бала бик кечкенә булганда ук, әле укый-язарга өйрәнгәнче үк, аңа Коръән аятьләрен әйтеп кабатлатырга кирәк. Сезгә мисал китерәсем килә: Согуд Гарәбстанында Әр-Рияд шәһәренең хафизлар мәктәбендә өч яшьлек малай тулысынча Коръәнне ятлаган. Ул дөньядагы иң яшь хафиз булган. Бу Аллаһының бер могҗизасы бит. Әгәр кемдер әлегә үзе Коръән укырга өйрәнмәгән икән, баласын мәчетләребезгә алып килсен, остаз тапсын. Һәм, әлбәттә, үзе дә тизрәк хәрефләрне һәм тәҗвидне өйрәнсен. Безнең мәчет-мәдрәсәләребез, шулай ук онлайн «Татар мәдрәсәсе» дигән проект бар. Аны телефоннан да карап була. Алар да гарәп хәрефләрен өйрәтә. Теләкомтылышы булган кеше чарасын тапмый калмас.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Коръән ятлауны башка эшләрдән әһәмиятлерәк булуын күрсәткән. Сәхабәләре арасыннан

ул Коръәнне күбрәк ятлаган, яхшырак белгәнен өстен күргән. Әгәр ул кайдадыр гаскәр җибәрсә, гаскәр башлыгы итеп Коръәнне башкалардан күбрәк белүчене билгеләгән. Әгәр намазда имамны билгеләсә, Коръәнне башкалардан күбрәк укучыны сайлаган. Җеназа укыйсы булса, Коръәннән күбрәк гыйлем алучыны өстен күргән. Кайвакыт Расүлуллаһ хафиз булган сәхабәсенә берәр мөслимәне димли алган, аның бай яки мохтаҗ булуына, башка сыйфатларына карамаган.

Коръәнне өйрәнүчеләрнең, ятлаучыларның дәрәҗәсен Аллаһы Тәгалә бик югары кылган. Алар бу тормышта ничек югары булса, җәннәттә дә Коръән хафизлар башкалардан югарырак дәрәҗәләрдә булачак. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хакта болай дигән: «Коръән иясенә: «Укы һәм күтәрел, фани тормышыңда укыган кебек укы. Синең дәрәҗәң син укыячак соңгы аять белән билгеләнә», – дип әйтеләчәк».[1] Имам Ибне Хәҗәр әл-Һәйтәми бу хәдисне аңлатып, болай дигән: «Әлеге хәдис Коръәнне ятлаучыга гына карый, ә аны мосхафтан укучыларга түгел, чөнки язылганны укуда кешеләр аерылмый. Кешеләр нәкъ ятлаулары белән аерыла, шуңа күрә, ятлау дәрәҗәләренә карап, җәннәттә аларның дәрәҗәләре төрле булачак».

Әлбәттә, мондый югары дәрәҗәләргә ирешүнең мөһим шартлары бар. Беренчедән, ятлау Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен генә булырга тиеш. Ә дөнья дәрәҗәсе, байлык өчен түгел. Гомумән, без нинди генә гыйбадәт кылсак та, иң беренче ниятебезне төзәтергә тиешбез. Балаларыбызны укытканда да, үзебез һәм алар Аллаһы ризалыгынаирешсен, дигән ният булырга тиеш. Башкалар сокلансын, сине яки балаңны мактасын кебек уй-ниятләрдән пакьләнергә кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Минем өммәтемнең күпчелек монафикълары Коръән укучылар арасында булыр», – дигән.[2] Монафикъ – ул икейөзле кеше. Раббыбыз безне моннан Үзе сакласын.

---

[1] Әбү Давыд, «Сунан» № 1464.

[2] Әхмәд, «Мөснәд» № 6633.

Дин кардәшләрем, сезгә сәхабәләр чорында булган бик гыйбрәтле бер вакыйга турында сөйлисем килә. Аллаһы Тәгалә Коръән аша олуг дәрәҗәләргә ирештергән кешеләрнең берсе Габдрахман бине Әбзи әл-Хозагый радыяллаһу ганһе була. Ул Нәфигъ бине әл-Харис исемле сәхабәнең колы булып, соңрак азат ителә. Әлеге Нәфигъ бине әл-Харисны Гомәр әл-Хаттаб радыяллаһу ганһүмә Мәккәнең хәлифәсе итеп билгеләгән була. Бер көнне очрашкач, Гомәр аннан: «Син үзәнлек кешеләре өчен кемне хаким итеп билгеләдең?» – дип сорый. Нәфигъ: «Ибне Әбзине», – ди. Гомәр: «Ә кем ул Ибне Әбзи?» – дип сорый. «Безнең азат ителгән колларыбызның берсе», – дип җавап бирә Нәфигъ. Гомәр гаҗәпләнеп: «Син азат ителгән колыңны хаким итеп билгеләдеңме?» – дип сорый. Нәфигъ болай дип әйтә: «Ул – Аллаһы Китабының хафизы һәм мирас фикһын белүче». Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әллә безнең Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу Китап белән Аллаһы Тәгалә берәүләрне күтәрә, ә башкаларны кимсетә», – димәдеме», – дип әйткән.[1]

Күрәбез, кайчандыр түбән катламнан саналган, ягъни кол булган; мәшһүр нәселгә дә, байлыкка да, җәмгыятьтә югары дәрәҗәгә дә ия булмаган бу кеше – Коръән күзлегеннән бөтенләй башка дәрәҗә вә урынга ия. Нәкъ изге Коръән аны азат ителгән кол дәрәҗәсеннән хаким дәрәҗәсенә күтәрә. Коръәнне белүе Габдрахман бине Әбзигә башка кешеләрнең сорауларын хәл итәргә, хөкем чыгарырга мөмкинлек, җәмгыятьтә югары урын бирә.

Коръән хафизларга бирелгән тагын бер өстенлекне искә алып китик. Җәмәгать намазларында имам булырга иң лаеклы кеше ул – хафиз. Бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә хәбәр итә: «Кешеләр арасыннан Аллаһының Китабын иң яхшы укыганы имам булсын».[2] Бу да хафизның дәрәҗәсен күрсәтә торган бер хөкем: мәчеттә ул бар җәмәгатьтән алдарак басып, имам була. Әлхәмдүлилләһ, хәзер Рамазан аенда тәравих намазында Казанның күп мәчетләрендә, шулай ук районнарыбызда да Коръән

1 Мөслим, «Сахих» № 817.

2 Мөслим, «Сахих» № 673.

хәтем кылына. Моның өчен хафизларыбыз имам булып басалар, Аллаһының рәхмәтендә булсыннар. Киләчәктә тагын да күбрәк мәчетләребездә, һәр районыбызда хафизларыбыз артсын иде!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Әгәр Коръән (кешенең хәтерендә тупләнеп, аның) тиресе астына кертелсә, ә соңыннан (бу кешене гөнаһлары өчен) җәһәннәм утына ыргытсалар, (Коръәннең фазыйләте аркасында аның тиресе) янмаячак».[1] Бу хәдистән без шуны аңлыйбыз: Коръәнне белү җәһәннәмнән котылуны вәгъдә итми, әмма Аллаһы каршында шәфәгатьче, яклаучы була ала. Җәһәннәм утыннан котылу өчен, кеше Коръәнне белергә генә түгел, аның хөкемнәрен үтәргә дә тиеш.

Димәк, үзебез өчен Коръәнне үзләштерүдә без мондый баскычлар, адымнар билгели алабыз: ниятебезне дөресләү; гарәп хәрефләрен һәм тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнү; Коръәнне укый башлау; укуыбызны остаз яки яхшы укучы белән хаталардан төзәтү; тәфсир укып һәрдаим аятьләр турында фикер йөртү, аларны аңларга тырышу; тормышыбызны Коръән буенча дөресләү; аять вә сүрәләрне ятлау. Һәм нәтиҗәдә, Аллаһының рәхмәте белән, тулысынча Коръәнне дә ятлап чыгу.

Кемдер, мин инде олы яшьтә, яки минем хәтерем бик начар, яки минем бер буш вакытым юк, дип уйлап утырадыр хәзер. Әмма, хөрмәтле дин кардәшләрем, кемнәр инде гарәпчә укырга өйрәнде, үзегезне искә төшерегез: бу хәрефләр бигрәк буталчык, авыр, мин моны өйрәнеп чыга алмыйм, диючеләр күпме иде. Һәр икенче кеше бәлки шулай дип уйлагандыр. Ә хәзер бу безгә бик җиңел тоела. Һәм әгәр ниятебез дөрес булса, теләкмаксатыбыз булса, Аллаһы Тәгалә безгә барын җиңеләйтәчәк. Интернеттан, газета-журналлардан беләбез: хәтта 70 яшьтән соң да хафиз булучылар бар! Кардәшләрем, 2016 елда Төркиянең Бордур шәһәрендә Хәдичә исемле мөслимә кардәшебез хафизлык шәһадәтнамәсе алган. Беләсезме, бу вакытта аңа 67 яшь булган, алай гына да түгел, Хәдичә ханым кечкенә вакытта сукыр

[1] Әхмәд, «Мөснәд» № 17365.

калган була. Бу кардәшебез 13 ел дәвамында, сукыр вә олы яшьтә булуына карамастан, Аллаһы Тәгаләнең Китабын ятлаган. Раббыбыз аннан разый булсын. Димәк, хөрмәтле кардәшләрем, безгә Аллаһыдан җиңеллек сорап, ихлас күңел белән Коръәнне укый һәм ятлый башларга берни комачауламый. Ярдәмгә безнең Казаныбызда Коръән хафизларын әзерләү үзәге бар, алар районнар белән дә эшли, балаларыбыз өчен «Татар хафизы» дигән проект оештырдылар. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дә, кайбер мәчетләребездә дә хафизлык курслары бар.

Изге Коръәнгә карата битараф булмыйк. Мондый кешеләр турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Дөреслектә, йөрәгендә Коръәннән бер нәрсә дә булмаган кеше бушап калган өйгә тиң».[1] Бушап калган, беркем дә яшәмәгән өй тора-бара җимерелә. Аның диварлары ишелә, түбәсеннән су үтә, тәрәзәләре ватыла. Шулай ук рухи азыктан мәхрүм ителгән йөрәк тә әкренләп сүнә. Мондый йөрәктә Аллаһыга карата ярату-хөрмәткә дә, изге гамәлләргә дә, камилләшүгә омтылуга да урын юк. Ул гөнаһларга карата зәгыйфь була һәм күпмедер вакыттан соң мәрхәмәтлелеген югалта.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Коръәнне өйрәнү һәм аның аятьләре хакында фикер йөртү – һәр мөселман мохтаҗ булган гыйбадәт. Фәкать Раббыбызның Сүзе генә калебләребезне иман нуры белән яктыртырга, тәкъвалыгыбызны арттырырга һәм хакыйкатькә юл күрсәтергә мөмкин.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай ди:

وَفِي ذَلِكَ فَلْيَتَنَافَسْ الْمُتَنَافِسُونَ

**«Омтылучылар** [гыйбадәтләргә ашыгып] **моңа омтылсын».**

«Әл-Мутаффифин / Киметеп үлчәүчеләр», 83:26

Без дә Коръәнне өйрәнергә, гөнаһларыбызны төзәтергә, күбрәк яхшылыклар кылырга омтылучы ихлас мөселманнардан булсак иде! Хөрмәтле

[1] Әт-Тирмизи, «Сунан» № 2913.

дин кардәшләрем, Раббыбызның аятьләре хакында күбрәк фикер йөртик, аларны өйрәнергә һәм ятларга омтылыйк, бу эштә сабырлык вә тырышлык күрсәтик.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Руслан Әмерханов,*

*«Хозур» нәшрият бүлеге*

*16 нчы август вәгазе,*

*сафәр аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Җәмәгатьнең мөһимлеге

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, барчаларыбызга да Аллаһының сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын! Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә һәркайсыбызны да шушы дөньяда Үзенең рәхмәтенә һәм ризалыгына насыйп әйләп, Кыямәт көнендә дә Үзенең ризалыгы белән бүләкләсен иде.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә шөкер вә мактауларыбыз булсын. Ул янә барчаларыбызны изге җомга көнебездә Үзенең йортларында берләштерде, бердәм итте. Атна дәвамында төрле сәбәпләр белән таркау булып, йөргән юллар кайларга гына илтсә дә, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә җомга көнне бөтенебезне дә, әмерләрен үтәү өчен, бирегә җыйды.

Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Тагын бер кат кабатлыйм: җомга намазы – һәрберебез өчен дә фарыз гамәл. Аның үтәлешендә дә билгеле шартлары һәм тәртибе бар. Әгәр дә җәмәгать җыелмаса, ул гамәл үтәлмәс һәм дөрес булмас. Ислам динендә һәрберебез дә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең әмерен үтәүнең тиешлеген аңлыйбыз. Ә шул гамәл башкарылсын өчен, җәмәгать кирәк. Шушы урында Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә динебездә, тормышта җәмәгатьнең никадәр мөһим икәнлеген күрсәтә. Җомга намазының асылында الجُمُعَة сүзе ята. Ягъни «берләшү, бердәм, җәмәгатьле булу» дигәнне аңлата. Кешеләр бу көнне бер фикергә килеп, бер-берсенә хөрмәтле булып, Аллаһының әмерен үтәргә ниятләп берләшәләр. Хәер, Ислам динен үзен дә җәмәгатьсез күз алдына китереп тә булмый.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә «Әлү Гыймран» сүрәсенең 110 нчы аятендә болай ди:

كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ

**«Кешеләр** [мәнфәгатьләрен кайгыртыр] **өчен** [мәйданга] **чыгарылган өммәтләрнең иң яхшысы сез булдыгыз».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә мөселман җәмгыятен «өммәт» дигән күркәм сүз белән тасвирлый. Мөселман кешесе дөньяның кайсы гына почмагында, җирлегендә, нинди генә вәзгыятьтә яшәмәсен, асылда барлык мөселманнар да бердәм. Ул – «өммәт» дигән сүз белән аңлатыла.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләбез дәвам итеп болай дип әйтә:

تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ ۗ

**«Яхшы гамәлләрне әмер итәсез, начар гамәлләрдән тыясыз һәм Аллаһыга ышанасыз».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

Мөселман кешесе үз үрнәгендә башкаларга да мисал булып тора бит. «Начар гамәлләрдән тыясыз» дигәндә, телең, холкың, гамәлләрең белән начарлык кылмауда үрнәк булып тору күздә тотыла. Мөселман бәндәсе – Аллаһы Тәгаләгә ышанучы. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә әлеге аять аша безне бик күп дәресләргә өйрәтә. Беренчедән, без җәмәгать буларак бердәм булырга тиеш. Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең шәриф-хәдисләре аша да безне моңа өйрәтә: «Һәр мөселман – икенче бер мөселманга кардәш. Шуңа алар бер-берсенә җәбер-золым кылырга тиеш түгел. Ярдәмгә мохтаҗ кардәшенә ярдәм иткән кешегә Аллаһы Тәгалә аның мохтаҗлыгында Үзе ярдәм итәр.

Мөселманны яклаган һәр кешене Аллаһы Тәгалә Кыямәт көне авырлыкларыннан саклар»[1].

Адәм баласы бу тормышта шатлыкта да, кайгыда да, беренче чиратта, туганына барып сыена. Үзара нинди генә низаг чыкмасын, син үзеңнең күңелеңдә аңа карата ярату, хөрмәт тоясың. Син яшәүнең матурлыгын аннан башка күрмисең кебек. Һәм нинди генә мәшәкать булмасын, без үзебез дә ярдәм кулыбызны иң әүвәл туганыбызга сузабыз. Шулай булгач, бер мөселман икенче мөселманга карата да шундый булырга тиеш. Үз туганың өчен ничек борчыласың, кайгырасың, шатланасың икән, күңелеңдә һәр мөселман кардәшеңә карата да шундый хисләр яшәргә тиеш. Шулай ук Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Кардәшенә дә үзенә теләгәнне теләмичә, берегез дә иманлы (ягъни, иманы камил) булмаячак»[2].

Беләбез, бу җирдә кешеләрнең яшәү рәвеше, мөмкинлекләре төрле дәрәҗәдә. Кемдер тиз арада мәһабәт йорт салып, кыйммәтле машина алып, зур дәрәҗәләргә ирешергә мөмкин. Ни кызганыч, шундый чакта аның якын кардәшенең күңелендә хөсетлек (көнләшү) уяныргa мөмкин. Күрше күршедән көнләшкән; акча-байлык дип, туган белән туган аралашмыйча яшәгән очраклар хакында һәрдаим ишетеп торабыз. Шуны белергә тиешбез: әгәр хөсетле кеше урынында үзебез булсак – иманыбыз камил түгел. Башкаларга карата булган нәфрәтең яки шатлыгың турыдан-туры синең иманың белән бәйле. Киресенчә, без туганыбыз, күршебез, дустыбыз ирешкән үргә үзебез менгән кебек сөенә белергә тиешбез, чөнки Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Үзе кардәшлекне, җәмгыятьтәге бердәмлекне иман белән бәйләде, сөбхәналлаһ.

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһының сүзен, динен җиткерү әмер ителгәч, ул да җәмәгатьне берләштерде. Пәйгамбәребез яшәгән чорда барча иманлы булган кешеләр бердәм иделәр, бер-берсенә ка-

[1] Әл-Бохари 2442, Мөслим 2580.

[2] Әл-Бохари, Мөслим.

рата ихтирамлы иделәр. Тулаем алганда, мөселман җәмгыяте шул бердәмлеге белән матур да, кадерле дә. Ә моңа ирешү юлын безгә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең иң сөекле бәндәсе, расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз үрнәгендә күрсәтте. Бер мөселманның икенчесенә карата ихтирамлы булуы, кардәшлек җепләрен саклавы – шәригатебездә вәҗиб булып тора.

Берничә ел элек социаль челтәрләрдә бер видео таралды. Аның эчтәлеге болайрак: Рамазан аенда мәчеткә йөрүче мөселманнар арасында бәхәс куба. Ике кардәш тәравих намазын ничә рәкәгать укырга тиешлеге хакында уртак фикергә килә алмыйлар. Берсе, һичшиксез 20 рәкәгать укырга тиешле, дип белдерсә, икенчесе 8 рәкәгать дөресрәк, дип саный. Бер-берсе белән бәхәсләшеп киткән ике мөселман ахыр чиктә мәчет эчендә сугыша башлыйлар. Инде бу рәвешле дә җавап табылмагач, сорау белән имамга мөрәҗәгать итәләр. Имам хәлне аңлаганнан соң, мәчет ишекләрен ябарга, тәравих намазын өйдә укырга боера. Имамның әлеге әмеренә каршы: «Рамазан ае – изге ай. Тәравих намазы – җәмәгать белән кылына торган сөннәт намаз бит», – дип җавап кайтаралар. Шулвакыт имам һәрбарчабыз уйланырлык, бик мәгънәле сүз әйтә: «Кардәшләрем, сез асылны аңламадыгыз. Тәравих намазы – Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә боерган сөннәт гамәл. Ә кардәшләр арасындагы татулык, туганлык, дуслык, бердәмлек – вәҗиб», – дип белдерә.

Әйе, бер-берең арасында күркәм мөнәсәбәтне булдыру, аны саклау – сөннәт намазыннан кадерлерәк. Мөхтәрәм мөселман кардәшләребез! Җәмәгатебез бердәм булсын өчен, иң беренче эш итеп, үз өстебездә эшләргә, холкыбызны, фикерләү дәрәҗәбезне уңай якка үзгәртергә тиешбез. Үзеңдә булган бер генә йөрәк авыртуын бетерү, кечкенә генә кимчелегеңне юк итү дә – синең генә түгел, син яшәгән җәмгыятьнең көчен арттыра. Әгәр дә син ихлас күңелдән кардәшең өчен янып-көеп, аңа ярдәм итү өчен тырышсаң, бүген – аның хәле яхшырыр, иртәгә – синең тирәлек күпкә ямьләнер.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай ди:

لَّوْلَا إِذْ سَمِعْتُمُوهُ ظَنَّ الْمُؤْمِنُونَ وَالْمُؤْمِنَاتُ بِأَنفُسِهِمْ خَيْرًا وَقَالُوا هَٰذَا إِفْكٌ مُّبِينٌ ﴿١٢﴾

**«Ни өчен соң сез моны ишеткәч,** [бер җан кебек булган] **ир һәм хатын мөэминнәр, күңелләрегездән үзегезгә игелек теләп: «Бу бит – ап-ачык яла!» – дип уйламадыгыз?»**

«Ән-Нур», 24:12

Бу аять Гайшә анабызга нисбәтле иңдерелгән. Ислам диненә, Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә зыян китерү максатыннан, монафикълар (икейөзлеләр) Гайшә радыяллаһу ганһәне зинада гаепләп, аның турында куркыныч ялган сүзләр тарата! Аны аклап, Раббыбыз Коръән аятьләре иңдерә һәм мөселманнарны, ни өчен сез мөслимә кардәшегез хакында яхшы фикердә булмадыгыз, дип шелтәли. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә бер-беребез хакында яхшы фикердә булырга куша. Әлегә монда гамәлләр хакында сүз дә юк. Иң әүвәл, беребез турында икенчебез яхшы уйда булырга тиеш. Әгәр дә уйның начары килде икән, тиз арада аны юк итү өстендә эшләргә тырышырга кирәк. Алай итмәсәк, аның бик тиз безнең телгә, сүзгә, гамәлгә күчү ихтималы югары.

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер шәриф хәдисендә мөселман җәмәгатен стена, дивар белән чагыштыра. Дивардагы һәрбер таш ул – бер мөселман. Әгәр бер генә таш төшеп китсә, дивар ишелергә мөмкин. Моңа юл куймас өчен, безгә бер-беребезгә ныграк ябышырга, Пәйгамбәребезнең тормыш рәвешен яшәү үрнәге итеп алырга кирәк. Әйе, шундый хәдис тә бар: «Мөселман өммәте 70 төрле төркемгә таркалыр», – дигән. Әлеге хәдис аша без таркалу турында ишеткәч, хәвефләнергә түгел, тагын да ныграк берләшү турында уйланырга тиеш. Моңа ирешү юлындагы адымнарның берсе – безгә йөкләнелгән һәр фарыз намазыбызны мәчетләрдә җәмәгать белән бергә уку. Аның мөһимлеге хакында һәрберебез дә уйлансак иде.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә:

وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا ۚ

**«Барыгыз бергә Аллаһының арканына** [Китабына һәм диненә] **ныклап ябышыгыз һәм** [әһле китап кебек ихтилафка төшеп хакыйкатьтән һәм бер-берләрегездән] **аерылмагыз»**, – диде.

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103

Аллаһы Тәгалә ризалыгын өмет итеп мәчетләргә килгән кардәшләребез янәшәдәге иптәшенең хөрмәтенә дә ирешергә омтылсын иде. Бер-беребез арасында дуслыкны, бердәмлекне булдыру өчен тырышыйк. Төрле фиркаларга бүленү өчен сәбәпләр тудырмыйк. Киресенчә, күз алдыбызга Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәхәлләсен китереп карыйк. Алар бер-берсе өчен утка да, суга да керергә әзер торганнар. Алар өчен аерым кайгы да, аерым шатлык та булмаган. Бер кардәшнең иңнәренә төшкән сынауның авыр йөген бергәләп күтәреп җиңгәннәр. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә берсенең малын арттырса, иң беренче кардәшләре белән бүлешергә күнеккәннәр. Безнең өчен моннан да зуррак гыйбрәт була аламы?

«Начар хәбәр яшен тизлеге белән тарала», – ди халкыбыз. Бүген, интернет заманасында, бу бигрәк тә актуаль. Әгәр дә берәр кардәшебез хакында начар хәбәр килеп ирешсә, ышанмыйк! Мондый чакта Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең киң таралган, барчабызга мәгълүм хәдисенә таяныйк. Без дә, иптәшебезнең шул ялгыш гамәленә 70 аклау табыйк, аны якларга омтылыйк.

Бүгенге көндә Фәләстыйн җирендә мөселман кардәшләребез зур җәберзолымга дучар ителде. Үзен мөселман дип санаган һәркемнең йөрәген борчыган зур сынау бу. Үзеңә дога кылган чакта, кулларыңны күтәреп, алар өчен дә ялварырга авырсынмыйк! Хәзерге көндә мөселман өммәте тагын да ныграк берләшеп, бердәм булсын өчен, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләдән ярдәм сорыйк. Әгәр дә әлегәчә һаман да үзең хакында гына кайгырасың икән –

һичьюгы, үзең өчен камил иман сора! Аллаһы Тәгалә һәрбарчабызны Үзенең ярдәменнән, рәхмәтеннән ташламасын. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә мәчет-мәхәлләләребезгә, район, Республикабызга, мөселман өммәтенә Үзенең ярдәмнәрен насыйп әйләсен!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фәрит хәзрәт Шәрапов,*

*Биектауның «Ак мәчет» мәчете имам-хатыйбы*

*23 нче август вәгазе,*

*сафәр аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Кеше җаны – әманәт

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак Расүле, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Соңгы елларда илебездә булган коточкыч хәлләр барыбызны да тетрәндерде. Казан шәһәребезнең 125 нче гимназиясендә, Пермь университетында, Ижау шәһәре мәктәбендә, Мәскәүнең «Крокус» үзәгендәге кебек терактлар, ни кызганыч, җир шарының башка җирләрендә дә булып алды. Кызганыч, шуның аркасында күпме гаепсез җаннар һәлак булды, хаксызга кан түгелде. Чынлыкта, бу һәм моның ише теракт гамәлләре, кан коюлар, җинаятьләр хакыйкый гаделсезлек булып тора һәм бу безнең хак Ислам динебезгә һәм динебезнең максатларына, хикмәтләренә каршы килә.

Моның ише җинаятьләрнең ни дәрәҗәдә булуын аңлар өчен, без Аллаһының «Ән-Нәхл» сүрәсендәге сүзләренә игътибар итәргә тиеш:

إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَإِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَيَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ وَالْبَغْيِ ۚ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ﴿٩٠﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен иңдергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Әгәр шушы террористларга һәм алар тарафыннан кылынган җинаятьләргә, явызлыкларга карасак, боларда гаделлек, мәрхәмәтлелек һәм акыл бар, дип әйтеп буламы?! Әлбәттә, аларның кылган гамәлләрендә бернинди яхшылык, кешелеклелек юк, дөреслектә, аларның гамәлләре – бар чикләрне дә үтү һәм хокуксызлык!

Бернинди шик тә юк, моның ише гамәлләргә, бүренең Йосыф пәйгамбәр күлмәгендәге канга бернинди дә катнашы булмаган кебек, Ислам диненең дә тузан бөртеге кадәр дә катнашы юк.

Ислам дине ул – гаделлек дине, Ислам ул – мәхлукларга карата иминлек, тынычлык тудыру, Ислам ул – нык иманлы, ышанычлы булуыбыз, вәгъдәләрне үтәү һәм иминлек. Караклык, алдау, кешеләрне хурлау, чит кешеләр милкенә кул сузу, бигрәк тә шартлату һәм кешеләрне үтерү – боларга безнең динебезнең бернинди катнашы юк. Ниндидер ахмак кешеләр, мөселман киемнәрен киеп, гаепсез кешеләрнең канын агыза икән, алар Коръән аятьләренә каршы киләләр, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәм беренче буын мөселманнарының юлын өйрәнмиләр, өммәтебезнең бөек галимнәре сүзләренә колак та элмиләр. Шуңа күрә без аларның законсызлык һәм гаделсезлек кылуларына аз гына да шикләнмибез.

Әбү Зәрр әл-Гыйфари радыяллаһу ганһе хәбәр иткәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһының сүзләрен җиткереп, болай дигән: «Ий Минем колларым! Дөреслектә, Мин Үземә гаделсезлекне тыйдым һәм аны бер-берегез арасында тыйдым, шулай булгач, бер-берегезне җәберләмәгез».

Динебез Ислам билгеле кагыйдәләр, тәртипләр белән килгән һәм шулардан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Үзеңә дә, башкаларга да зыян китермә», – дигән сүзе бар.

Ислам динебез зыян салу өчен килмәде, ә киресенчә, бөтен кешелек дөньясына файда китерү өчен һәм мәрхәмәтлелек белән килде. Ләкин шул терактлар оештыручы явыз кешеләр, кан коючылар – кешелек өчен дә, динебез өчен дә бернинди файда китермиләр, киресенчә, Ислам һәм мөселманнарга карата зарар, хурлык, газаплар гына китерәләр, алар аркасында безнең динне күбрәк гаепли башлаучы кешеләр пәйда була.

Ислам динебез безне бөтен кешеләргә карата мәрхәмәт күрсәтергә этәрә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Аллаһы мәхлукларына мәрхәмәтлелек күрсәтә белмәгән кешегә мәрхәмәтлелек күрсәтелмәс».

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рәхимле булган Аллаһы Тәгалә мәхлукларга мәрхәмәт күрсәткәннәргә Үзенең рәхмәтен күрсәтер. Шулай булгач, җирдә мәрхәмәтлелек күрсәтегез һәм рәхмәте күкләрдән иңә торган Зат сезне рәхмәтеннән ташламас», – дип әйткән.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең максаты – кешеләргә карата шәфкатьлелек кылу, аларны коткарып калу, халыкны изгелеккә өйрәтү иде, ә кешеләрне юкка чыгару, һәлак итү һәм кан кою түгел иде.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Таиф шәһәре халкын Исламга өндәргә баргач, белгәнегезчә, алар аны кабул итмичә, ташлар атып, начар сүзләр белән озатып калалар. Канга баткан Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм, кәефсез килеш борчылып утырганда, аның

янына Җәбраил фәрештә килә, һәм үзе белән Тау фәрештәсе килгәнен хәбәр итә, Аллаһының аларга сәламе булсын! Тау фәрештәсе Пәйгамбәребезгә дәшеп: «Ий Мөхәммәд, ни телисең, шуны әмер ит! Телисең икән, мин аларның өсләренә ике тауны аударырмын!» – ди. Әмма Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кирәкмәс! Мин алар нәселеннән киләчәктә изге кешеләр чыгар, дип өметләнәмен», – дип җавап бирә.[1]

Динебез нәрсәгә өндәгәне хакында уйланырга һәм шушы җинаятьчеләрнең кылган гамәлләренә игътибар итәргә кирәк: мәхлукларга карата булган мәрхәмәтлелекләре кая соң аларның?! Дөреслектә, алар – авыру һәм адашкан бәндәләр.

Шулай ук без Аллаһының «Әл-Маидә» сүрәсендәге 32 нче аятенә игътибар итәргә тиеш:

مِنْ أَجْلِ ذَٰلِكَ كَتَبْنَا عَلَىٰ بَنِي إِسْرَائِيلَ أَنَّهُ مَن قَتَلَ نَفْسًا بِغَيْرِ نَفْسٍ أَوْ فَسَادٍ فِي الْأَرْضِ فَكَأَنَّمَا قَتَلَ النَّاسَ جَمِيعًا

**«Шул** [рәвешчә, Кабил Һабилне үтерүе] **сәбәпле, Без** [бу гөнаһны күп итеп кылган] **Исраил улларына** [бер хөкем буларак] **әмер иттек: кем дә кем бер җан өчен** [кыйсас ителү кебек хокуклы очрак булмыйча] **яки җирдә бозыклык** [һәм юлбасарлык кебек үтерелүне кирәк кылган сәбәп] **булмыйча,** [нахакка] **бер җанны үтерсә, гүя бөтен кешене дә үтергән кебек булыр».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:32

Динебез буенча, хаксызга бер кешенең канын кою – җир йөзендә булган бар кешене үтерүгә тиң. Дөреслектә, кешенең каны, милке, намусы кагылгысыз булып тора, Аллаһы Тәгаләә безгә боларны сакларга әмер итте.

Аллаһы безне туры юлга бастырсын, Аңа буйсынуда гомеребезне арттырсын, илебезгә иминлек, тынычлык насыйп итсен һәм шуның ише адаш-

[1] Әл-Бохари, Мөслим.

кан, яман кешеләрнең зыяныннан сакласын! Аллаһы Тәгалә безне изгелеккә чакыручы кешеләрдән кылып, үзебезнең дә күңелләребез изгелектә булуны һәм ике дөнья бәхетенә ирешүне насыйп итсен.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фәнзил хәзрәт Нәбиуллин,*

*Алабуга шәһәренең «Шатлык» мәчете имам-хатыйбы*

*30 нчы август вәгазе,*

*сафәр аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Белем алганда ниятләребез дөрес булсын

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрне, күкләрне, җирләрне юктан бар кылып, безне санап бетереп булмый торган нигъмәтләрендә яшәтүче, ризыкландыручы Аллаһы Сөбеханә вә Тәгаләгә хәмед-сәналәр, чиксез шөкерләребез булсын! Сөекле Пәйгамбәребезгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булсын.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, безнең янәшәбездә бик үзенчәлекле кешеләр яши – пәйгамбәрләрнең варислары! Шушы көнгә кадәр ул варислар үзләренең вазифаларын төгәл башкарып килергә тырышалар: пәйгамбәрләрнең мирасын тараталар, безне хак юлга дәшәләр, караңгылыктан чыгу юлларын күрсәтәләр. Сүз галимнәр турында бара.

Бүгенге көндә гыйлем үзе бер океанны хәтерләтә: үзенең күплеге һәм аны алу төрлелеге аркасында бу океанның ярлары да күренми кебек. Ярлары күренмәгәч, кеше арый башлый, шушы океанда бата, ник дигәндә, үзебез өчен төгәл сайлаган курс юк. Ошбу вәгазебездә гыйлем алуның фазыйләтләрен дә, аны дөрес итеп алу юлларын да карап китәргә тырышырбыз. Аллаһы Тәгалә безгә җиңеллек бирсә иде.

Чыннан да, тормышыбыз гаять күпкырлы. Бүгенге көндә 70 төрле һөнәр белү дә аз кебек: без әле берсенә, әле икенчесенә ябышабыз, төрле өлкәдә

үзебезне сынап карарга телибез. Кайчакта ярты гомер яшәп тә, үзебезне таба алмыйбыз. Бәлки бу тормышның үзенең дә бер океан кебек булуы белән бәйледер: ярлары күренми, шуңа кая барып бәрелергә белмибез. Моның сәбәпләренең берсе – бу тормышка артык ябышудыр: үлем турында, ахирәт турында уйланулар кимегән саен, телефонда, интернетта, социаль челтәрләрдә, сәүдә үзәкләрендә һәм башка шундый җирләрдә вакытны күбрәк сарыф иткән саен, безнең хакыйкать турында уйланырга вакытыбыз азрак кала. Аллаһыга шөкер, галимнәребез бар. Алар һәрвакыт безгә ярдәмгә килергә әзер. Нинди генә сорау туса да, гыйлемле кеше динебезгә муафыйк рәвештә җавап кайтарыр.

Галимнәребезне пәйгамбәрләр варисы, дип әйттек. Ә бу мираска нәрсә карый соң? Бервакыт Әбү Һөрайра радыяллау ганһе базар буйлап йөргәндә, кешеләрнең сәүдә эшләре белән мәшгуль булганын күреп: «Сез бик көчсез», – дип, Мәдинә халкына мөрәҗәгать итә. Кешеләр: «Безнең көчсезлек нидә?» – дип сорау бирәләр. Ул: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мирасын бүләләр, ник сез дә үзегезнең өлешегезне алмыйсыз?» – дип җавап кайтара. Кешеләргә бу мирасны мәчеттә бүлгәннәрен әйткәч, алар тиз арада шунда юнәлделәр. Әбү Һөрайра аларны базарда көтеп калды. Мирас алырга дип киткән кешеләр кире кайткач, Әбү Һөрайрага: «Без мәчеткә килдек, әмма анда берни дә таратмыйлар бит», – дип әйттеләр. Әбү Һөрайра алардан анда ни күргәннәрен сорагач, алар: «Анда кайберләре намаз укый, кайберләре Коръән укый, башкалары рөхсәт ителгән һәм тыелган әйберләр турында зикер итеп утыралар иде», – дип җавап кайтаралар. Әбү Һөрайра: «Үкенеч булсын сезгә, Пәйгамбәребезнең мирасы шул бит инде!» – дип җавап кайтара.

Чыннан да, гыйлем – иң зур мирас, ә иң зур гыйлем – Аллаһыны тану. Шуңа да Исламның беренче нигезе дә – шәһадәт китерүдер, ягъни иң зур гыйлем – дини гыйлем, Аллаһыны тану, динеңне өйрәнү. Аллаһыны таныган кеше Аның Китабына да игътибар бирә башлый. Раббыбыз Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә гыйлем турында 70тән артык урында искә ала. Шулай ук

беренче иңгән аятьләрдә дә Раббыбыз гыйлемне зикер итә. Шулай булгач, Раббыбыз күрсәткән юлларның берсе – гыйлем юлы. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

ٱلَّذِينَ يَذْكُرُونَ ٱللَّهَ قِيَٰمًا وَقُعُودًا وَعَلَىٰ جُنُوبِهِمْ وَيَتَفَكَّرُونَ فِى خَلْقِ ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَٱلْأَرْضِ رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَٰذَا بَٰطِلًا سُبْحَٰنَكَ فَقِنَا عَذَابَ ٱلنَّارِ ﴿١٩١﴾

> **«Алар** [акыл ияләре] **аякта торганда да, утырган килеш тә, янтыкларында килеш тә Аллаһыны зикер итәләр һәм күкләр белән җирнең яратылышы турында фикерлиләр: «Ий Раббыбыз! Син моны юкка яратмадың. Син** [юкка нәрсә дә булса яратудан һәм юкбар белән шөгыльләнүдән] **пакьсең! Безне Ут газабыннан сакла!»**
>
> «Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:191

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә үзенең бер хәдисендә: «Гыйлем алу һәрбер мөселман ир-атка һәм мөселман хатын-кызга тиештер», – дип әйтеп калдыра. Шулай ук ул гыйлем алуга ашкынуны күп кенә гыйбадәтләрдән дә өстенрәк икәнен әйтеп калдырган.

Хөрмәтле җәмәгать, гыйлем алуның кирәклеге, мөһимлеге һәм фазыйләтләре турында күп сөйләп була. Әмма без моны беләбез, бу кечкенә генә искә төшерү иде. Аллаһыга шөкер, Россия, Татарстан җирлекләрендә укулар башлана. Балаларыбыз мәктәпкә, техникум-университетларга укырга керделәр. Шулай ук шушы көннәрдә мәчет каршындагы курслар эшли башлый, мәдрәсәләребез үз ишекләрен ача. Гыйлем алырга шуның кадәр күп юллар булуы, төрле өлкәдә үзеңнең һөнәри квалификацияңне арттыра алу мөмкинлеге бик куандыра гына. Кайчандыр мондый көннәр хыял гына булып күренгән булса, бүген, әйткәнебезчә, гыйлем алу юллары да океанга тиң: уку йортлары, мәктәп-мәдрәсәләр, индивидуаль укытулар, интернетта онлайн мәктәпләр, телефонга программалар – һәр кеше үзенә җиңел юлны сайлап укый ала.

Әмма бүгенге көннең бер проблемасы шул: гыйлемнең күп булуына һәм аны алып булу юлларының да күп булуына карамастан, без әле дә җитәрлек күләмдә гыйлемле түгелбез. Моңа җавапны Пәйгамбәребез хәдисендә таба алабыз: «Ий кешеләр, гыйлемне аңа ашкынган чакта гына алып була». Шуңа күрә галимнәребез безгә яхшы, күркәм гыйлемнәр алуны тормышыбызның бер максаты итеп куярга тәкъдим итәләр дә. Безнең тормыш күпкырлы булса да, кеше барыбер ниндидер зур максатлар куеп яши: яхшы эш табарга, гаиләне яхшы итеп тәэмин итәргә. Менә шул максатларның берсе булып – гыйлем алу торырга тиеш тә инде. Шул вакытта гына без мәдрәсәләргә, мәчет каршындагы курсларга керергә тыгыз тормышыбызда бер вакыт табачакбыз. Бөтен әйбер кул астында, интернет бар, кибетләр тулы китап, дип, үз-үзебезне алдап йөрү бары тик төптән алынып гыйлем ала башлагач кына тәмамланачак. Өйдә утырып кына ниндидер хәерлелеккә ирешеп булмаска да мөмкин. Шуңа да без акча кирәк, дип – эшкә барабыз, гыйлем кирәк, дип – уку йортларына. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем дә кем гыйлем эстәү нияте белән өеннән чыкса, Аллаһы Тәгалә аңа җәннәткә юлны җиңеләйтер», – дип әйтә.

Шулай ук Пәйгамбәребез: «Аллаһыны зикер итү һәм шуның белән бәйле әйберләрдән, галим һәм гыйлем алучыдан кала, бу дөньяның һәм анда булган әйберләрнең берсендә дә хәерлелек юк», – дип әйтә. Игътибар итегез: галим һәм гыйлем алучы. Гыйлемне укытучыдан, галимнәрдән алу – менә бу динебезнең асылы булып тора. Бүгенге көнгә кадәр килеп ирешкән һәр гыйлемнең, без укый торган хәдисләрнең чылбыры бар. Без дә гыйлемне чылбыр аша, укытучыдан укучыга алырга тиешбез.

Интернет бар дип, интернет шәехләре бар, дип уйлаган һәр кардәшем: без файда китерә торган, күркәм гыйлем алу өчен үзебезгә күркәм укытучылар табарга тиешбез. Коръән мөтәвәтир юлы белән, хәдисләр мөтәвәтир юлы белән килеп иреште. Иснәдләре билгеле, һәм шуңа күрә курыкмыйча укый алабыз. Шуңа нинди генә гыйлем алырга керешсәк тә, ул укытучы–

укучы системасы аша булырга тиеш. Беренче чиратта: Коръән укырга өйрәнү, динебезнең нигезләрен, хәләл белән харам, дини даталар һәм бәйрәмнәр. Аллаһыга ышана башлаган һәр кеше Аңа ни рәвешле дөрес итеп ышануны өйрәнә, намаз укый башлаган кеше – намаз уку кагыйдәләрен, тәртипләрен, фарыз-вәҗибләрен, аны нәрсә боза, нинди шартлары бар икәнен өйрәнергә тиеш.

Шулай ук бу тормышны Раббыбыз Аллаһы безгә вакытлыча яшәү урыны итеп кылган икән (безне барлыкка китергәч тә, йә җәннәт, йә җәһәннәмгә урнаштырмады), димәк ки, без бу дөньяда яшәр өчен дә гыйлем алырга, һөнәр үзләштерергә тиешбез. Кемдер бина төзи, кемдер кешене дәвалый, башка берәү исәп-хисап кыла, икенчеләребез игенче була ала. Раббыбыз безне мондый шартларга куйган икән, монда да олы хикмәт бар. Дини гыйлем алганда да, дөньяви белем, һөнәр алганда да безнең ниятләребез мөһим. Һөнәре, кәсебе аша да адәм баласы башкаларга бик күп файда китерә ала: башкарган эше белән җәмгыятькә ярдәм итә, эшләп тапкан хәләл акчасы белән гаиләсенә, өммәтенә ярдәм китерә. Шуңа күрә, нинди генә рөхсәт ителгән гыйлем алсак та, ниятебез – аның аша да Аллаһының ризалыгына ирешү, ярдәм күрсәтү, мөселман өммәтен көчле, нык итү булсын.

Хөрмәтле җәмәгать, дин кардәшләрем. Ошбу җомга вәгазьләребез дә кыска гына бер нәсыйхәттер. Әлбәттә, гыйлем алу турында күп сөйләп була, әмма минем сезгә әйтәсе килгән олуг нәсыйхәтем: кемнәр әле бу юлга басмады, мәчет-мәдрәсәләребезгә, техникум-университетларга рәхим итегез. Бүгеннән үк гыйлем юлына басыгыз. Күпме кеше беренче курсның яртыеллыгын тәмамлагач та, «без монда килгәнче бернәрсә дә белмәгәнбез икән» кебек сүзләр әйтәләр. Бу чыннан да шулай.

Беренче класс баласы укуны әлифбадан башлый. Әлифба сүзе – гарәп теленең беренче ике хәрефләре: «әлиф» һәм «бә». Пәйгамбәребез таякның әлиф икәнен өйрәнгәч тә, калганнарга өйрәт, дип нәсыйхәт әйтеп калдыра. Шуңа күрә, үзебез дә укыйк, балаларыбызда да мәктәптән үк гыйлемгә

мәхәббәт уятырга тырышыйк. Мәктәптә үк уйларга, фикерләргә ияләштереп калдырыйк, ә Раббыбыз Коръәндә фикер ияләренә күп ризыклар, күп аятьләр бар, дип юкка гына әйтми.

Суга кермичә йөзәргә өйрәнеп булмаган кебек, мәдрәсәләргә кермичә, хак гыйлемнәргә дә ирешеп булмаячак. Фиркалар, бер-береңне аңламау да гыйлемсезлектән килергә мөмкин. Раббыбыз Аллаһы араларыбызга өлфәт мәхәббәт, күңелләребезгә гыйлем алуга карата сабырлыклар урнаштырса иде. Гыйлем – Пәйгамбәребезнең мирасы. Аллаһы үземне дә, сезне дә аның варисы итеп кылса иде, әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районының Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*6 нчы сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Пәйгамбәребез галәйһиссәлам – иң гадел җитәкче

Әгуүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактаулар һәм сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Һәм дә Аның хак Расүле, безгә туры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Хәдистә хәбәр ителгәнчә, Кыямәт көнне җиде төрле кеше Аллаһы Тәгаләнең Гарше күләгәсенә лаек булыр: гадел (намуслы) имам; яшьтән үк Аллаһыга гыйбадәт кылып үскән кеше; күңеле мәчет белән бәйле булган кеше; Аллаһы ризалыгы өчен бер-берсен сөйгән, шуның өчен генә күрешкән һәм аерылган ике кеше; дәрәҗәле, матур хатын зина кылырга чакырганда: «Мин Аллаһыдан куркам», – дип, бу эштән тыелган ир кеше; сул кулы уң кулының садака бирүен белмәү дәрәҗәсендә яшереп садака бирүче; беркем күрмәгәндә Аллаһыны зикер итеп, күзеннән яшьләре аккан кеше.[1]

Шул чыдамаслык кызуда бердәнбер күләгә булыр. Ул – Аллаһы Тәгаләнең Гаршенең күләгәсе. Хәдистәге сүзләр буенча, ул Аллаһы

[1] Әл-Бохари; Мөслим.

Тәгаләнең Үзенең күләгәсе була алмас, чөнки Аллаһы Тәгаләне җәннәт әһелләре генә күрә алырлар.

Шушы күләгәгә беренче эләгүче гадел имам булыр. Имам дигәч тә, күз алдына мулла, хәзрәт килеп басарга тиеш түгел. Гомумән, кешеләрне җитәкләгән һәр шәхескә: җитәкчеме, мөдирме, рәисме, башлыкмы, президент булсынмы ул – «имам» дип әйтелә. Күп кешеләрне хакимият нык боза, үзгәртә. Ә хәдистән аңлашылганча, дәрәҗәле урынга урнашуы кешенең гаделлегенә тәэсир итмәсә, ул бу күләгәгә лаек булачак, чөнки күпчелек кеше бу сынауны үтә алмый.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, безнең һәркайсыбыз, һәрбер кеше пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышын үзенә үрнәк итеп алырга тиеш. Аллаһы Раббыбыз да Коръәни Кәримендә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламне мактап болай дип әйтә:

وَإِنَّكَ لَعَلى خُلُقٍ عَظِيمٍ

**«Һәм син, һичшиксез, югары әхлак иясе».**

«Әл-Каләм», 68:4

Ул игелекле, итагатьле, шәфкатьле, миһербанлы, сабыр, киң күңелле, юмарт, ышанычлы, тыйнак була. Бу сыйфатлар Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә иң камил дәрәҗәдә хас. Һәм дә алар аның иң гадел җитәкче икәнлеген дә күрсәтә. Аллаһы Илчесе галәйһиссәламнең әхлак чыганагы Коръән булган. Шуңа күрә: «Расүлебезнең холкы нинди иде соң?» – дигән сорауга Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә: «Аның холкы Коръән иде», – дип җавап биргән.

Расүлуллаһ галәйһиссәлам югары дәрәҗәдә намуслы һәм ышанычлы, кешеләр белән йомшак һәм дустанә мөнәсәбәттә булган. Ул һәрвакыт әхлакый саф фикер йөрткән. Әгәр кемдер аннан берәр нәрсә сораса яки берәр нәрсә белән кызыксынса, һәрвакыт йомшак һәм төпле җавап биргән.

Ул беркайчан да әңгәмәдәшен ярты сүздән бүлдермәгән, җавапны яхшы уйлап, кыска, ләкин тирән мәгънәле итеп бирә торган булган.

Әнәс бине Мәлик исемле мәшһүр сәхабә радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Мин Аллаһының Расүле галәйһиссәламгә ун ел хезмәт иттем. Бер мәртәбә дә ямьсез сүз сөйләгәнен ишетмәдем. Беркайчан да: «Бу эшне ник болай эшләдең?» – дип ачуланганын күрмәдем».

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам күршеләрен хөрмәт иткән, күршеләрен вә кунакларын ихтирам белән кабул иткән. Аның Аллаһы өчен хезмәт итмәгән, яхшы гамәл кылмаган бер генә минуты да булмаган.

Аллаһының илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләрен бик яраткан, алар белән киңәшләшкән һәм алар турында кайгыртткан. Әгәр берәрсе авырып китсә, ул аларның хәлен белергә барган. Берәрсе вафат булса, аның хакына дога кылган.

Аллаһының илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бик тыйнак булган, кешеләр җыелган җиргә яки җыелышка килгәч, ул урын бар җиргә утырган һәм моның белән барысының да бертигез хокуклы икәнлеген ассызыклаган. Кысан җирдә һәрвакыт башкаларга күбрәк урын калдырган. Әңгәмәдәше белән утырганда беркайчан да аннан алда торып китмәгән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам ярлыларга фәкыйрьлекләре сәбәпле өстән карамаган, байлар алдында түбәнчелек күрсәтмәгән. Кешеләрне ул һәрвакыт беренче булып сәламләгән. Ул һәрвакыт дөресен генә сөйләгән.

Кием-салымда да, ризыкта да бернинди артыклык кабул итмәгән. Ашаганда, эчкәндә уң кулын файдаланган, чөнки Аллаһы аңа шулай кушкан.

Олуг пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләреннән кием белән дә, җыелышта утырган урыны белән дә аерылып тормаган. Шулардан чыгып, ул һәрбер мөэмин-мөселман өчен үрнәк булып тора.

Хакимнең үзен ничек тотуы аның астында халыкның ничек яшәвен билгели бит. Кызганыч, бүген Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә өйрәтеп калдырган гыйлемне искергән һәм хәзерге дөнья өчен яраксыз, дип саный торган кешеләр бар. Бу ялгыш караш. Коръәни Кәрим бөтен кешелек өчен иңгән кебек, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәте дә һәрвакыт ныклы һәм әһәмиятле булачак. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәте Кыямәт көненә кадәр калачак, һәм һәркем аңа иярергә тиеш.

Әбү Хәмид әл-Газали үзенең бер китабында болай дип яза: «Аллаһының ике төркем кешене сайлаганын белегез: пәйгамбәрләр һәм җитәкчеләр». Бу дөньяда бернәрсә дә болай гына булмый. Барысы да Аллаһының кодрәте белән була. Әгәр дә кемдер президент, рәис, начальник, җитәкче, имам булса – болар барысы да Аллаһы тарафыннан билгеләнгән. Шуңа күрә гадел мөселманнар үз хакимнәренә, җитәкчеләргә иярергә тиешләр.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَطِيعُوا اللَّهَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ وَأُولِي الْأَمْرِ مِنْكُمْ

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыга итагать итегез, Расүлгә һәм үзегездән булган хөкем ияләренә итагать итегез».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:59

Әйе, халыклар төрле җитәкчеләрне күрделәр: акыллы, гадел, аларның кайсылары үрнәк булып торды. Әлбәттә, иң камил үрнәкләр ул: Расүлуллаһ Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм башка пәйгамбәрләр, шулай ук тугры хәлифәләр Әбү Бәкер, Гомәр, Госман һәм Гали радыяллаһу ганһүм. Һәр мөселман алардан үз-үзен тотуда үрнәк ала. Һәм, һичшиксез, аеруча имамлык, хакимият мәсьәләсендә алар барлык хакимнәр, җитәкчеләр өчен иң яхшы үрнәк булып торалар.

Тарихыбызда шулай ук белемсез, гаделсез, начар, золым кылучы җитәкчеләр дә булды. Моның да үз хикмәте бар. Бу – Раббыбыздан бер сынау, аның асылын Ул Үзе генә белә.

Һичшиксез, җитәкчене халык яратсын өчен, аның сүзен кабул итсен, артыннан иярсен өчен, аңа бер бик яхшы сыйфат хас булырга тиеш. Ул да булса – акыл, гыйлем. Наданлык сәбәпле күпме кавемнәр авыр сынаулар үтте, йөзләгән, меңләгән кешеләр газапланды.

Һичшиксез, хаким үзенең халкын яратырга тиеш. Халык җитәкчесен ярата икән, димәк, халык аңа ышана. Җитәкчегә ышаныч бик мөһим. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакыт үз шәкертләрен фетнә таралуыннан сак булырга өндәде.

Күпмилләтле, күп динле илдә һәркемгә ошарга бик авыр. Уңышлы җитәкченең ачкычы – дәрәҗәгә, байлыкка, дингә, милләткә карамастан, һәркемгә карата зирәклек һәм гаделлек күрсәтү. Ә халыкның бурычы – Аллаһы тарафыннан билгеләнгән хакимгә иярү.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ранис хәзрәт Сөнгатуллин,*

*Алабуга шәһәренең җәмигъ мәчете имам-мөгаллиме*

*13 нче сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Мәүлид ән-Нәби

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне һәм безләрне дә юктан бар кылып, тәрбияләп торучы, Үзенең сансыз нигъмәтләре белән нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, олуглауларыбыз, рәхмәтләребез, шөкерләребез булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, сәхабәләренә йөрәк түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез, изге догаларыбыз, сәламнәребез барып ирешсә иде!

Мөхтәрәм җәмәгать, изге җомга көннәребез мөбарәк булсын. Ошбу җомга көнендә Аллаһыны зикер итеп, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар әйтеп, изге гамәлләр кылырга насыйп итсен. Бүгенге җомга вәгазе пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәүлиде турында булыр.

Рабигыль-әүвәл аеның 11еннән 12сенә булган кич – барлык мөселман өммәте өчен мөбарәк бәйрәм киче булып тора. Шушы мөбарәк кичтә безләрне караңгылыктан – нурга, наданлыктан гыйлемгә, тәүфыйк-һидәяткә алып чыккан сөекле Расүлебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган. Мөселманнар бу кичне «Мәүлид кичәсе» дип атап йөртәләр.

«Мәүлид» сүзе – туу, туган вакыт мәгънәсен аңлата. Мәүлид – сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искә алу, аның шушы дөньяга килүенә шатлык белдерү өчен үткәрелә торган мөселман бәйрәме.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

قُلْ بِفَضْلِ اللَّهِ وَبِرَحْمَتِهِ فَبِذَٰلِكَ فَلْيَفْرَحُوا هُوَ خَيْرٌ مِّمَّا يَجْمَعُونَ ﴿٥٨﴾

«[Расүлем!] **Әйт: «Аллаһының фазылы** [булган Коръәни Кәрим] **белән һәм Аның гына рәхмәте** [булган Пәйгамбәре, Ислам һәм сөннәт] **белән** [бәхетле булсыннар]**, шуңа гына шатлансыннар. Ул** [илаһи фазыл һәм рәхмәт] **алар туплаганнардан яхшырак».**

«Юныс», 10:58

Ягъни, Раббыбыз безгә бер рәхмәт җибәрә икән, без шатлык белдерергә тиешбез. Аллаһы Тәгалә Үзенең рәхмәте арасында иң зурысын «Әл-Әнбия» сүрәсенең 107 нче аятендә атый:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ

«[Расүлем!] **Без сине** [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] **бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Димәк ки, рәхмәтләрнең иң олысы – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килүе. Һәм без шул көнгә шатланып, мәүлид мәҗлесләре, кичәләре үткәрәбез. Сәхабәләр Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзен күреп, аның янәшәсендә булып, аның күркәм холкын һәм өстенлекләрен тоеп яшәгәннәр. Шуңа күрә алар өчен махсус мәҗлесләр үткәрү кирәк булмаган. Һиҗри исәп белән алтынчы гасырда зур табыннар, ашлар әзерләп, зур изгелекләр кылып, садакалар таратып, мохтаҗларга ярдәм итү гадәте кереп китә. Мәүлид мәҗлесләрендә без пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышын, эшчәнлеген өйрәнәбез, аңа салаватлар әйтәбез, садакалар таратабыз, Коръән аятьләре укып, догалар кылабыз. Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышын һәм пәйгамбәрлеккә бәйле могҗизалы вакыйгаларны сөйләү һәм тыңлау бик изге эш булып тора. Мәүлид мәҗлесләре, кичәләре

үткәрү – кешеләрне Аллаһыга, дингә өндәү, сираны өйрәнүгә зур бер форсат, бер ысул.

Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньядагы барлык пәйгамбәрләр, мәхлуклар арасындагы дәрәҗәсен югары куя. Аллаһы Тәгалә Үзенең мәгъфирәтенә ирешү өчен, безләргә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм артыннан иярергә куша. Аллаһы Тәгаләнең түбәндәге аяте моңа ачык дәлил:

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ اللَّهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ وَاللَّهُ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٣١﴾

«[Расүлем!] **Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһы –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Икенче төрле әйткәндә, дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булыр өчен, Аллаһының газабыннан котылу өчен, Мөхәммәд галәйһиссәламгә ияру кирәк. Аның гүзәл әхлагы, камил холкы, сабырлыгы, юмартлыгы, гыйлемлеге безгә үрнәк булып тора. Юкка гына ул ахыргы пәйгамбәр итеп, пәйгамбәрләрнең солтаны һәм бар галәмнәргә пәйгамбәр буларак иңдерелмәгән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

مَّا كَانَ مُحَمَّدٌ أَبَا أَحَدٍ مِّن رِّجَالِكُمْ وَلَٰكِن رَّسُولَ اللَّهِ وَخَاتَمَ النَّبِيِّينَ ۗ وَكَانَ اللَّهُ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمًا ﴿٤٠﴾

**«Мөхәммәд сезнең ирләрегезнең берсенең дә атасы түгел** [кайната белән бала арасында урнашкан хаклар һәм тыюлар аның белән башка берәү арасында хөкемдә йөри алмый]**, ләкин** [ул] **Аллаһының илчесе һәм пәйгамбәрләрнең соңгысы. Аллаһы һәрнәрсәне** [бик яхшы] **белүче».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:40

Аллаһы Тәгалә башка пәйгамбәрләрне аерым бер халык өчен, билгеле бер вакытка гына җибәрсә, Мөхәммәд пәйгамбәр исә барча галәмнәрдәге мәхлукат өчен, ягъни кешеләргә дә, җеннәргә дә пәйгамбәр булып тора. Бу хакта ул үзенең хәдисендә дә хәбәр итә: «Мин барлык мәхлукларга да пәйгамбәр итеп җибәрелдем»[1].

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا كَافَّةً لِّلنَّاسِ بَشِيرًا وَنَذِيرًا وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ ﴿٢٨﴾

«[Расүлем!] **Без сине** [гарәп-гаҗәм, ак-кара тәнле дип аерма ясамыйча] **бөтен кешеләргә** [иман китергәннәр өчен] **сөендерүче һәм** [инкяр иткәннәр өчен] **кисәтүче итеп җибәрдек. Ләкин кешеләрнең күбесе** [бу хакыйкатьне] **белми».**

«Сәбә», 34:28

Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне мөэминнәрне җәннәт белән шатландырыр өчен һәм ышанмаучыларны җәһәннәм газабы белән куркытыр өчен җибәрде. Ул көндез дә, төнлә дә якты нур булып, мөселманнарга юл күрсәтеп бара.

Башка пәйгамбәрләрдән Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өстенлеген карасак:

1. Башка пәйгамбәрләр шәригате үзләре үлгәннән соң туктый, ләкин Расүлуллаһның шәригате Кыямәт көненә чаклы бара.

2. Аллаһы Тәгалә һәрбер пәйгамбәргә исеме белән мөрәҗәгать итте. Үзенең сөеклесенә «Йә Расүлуллаһ!», «Йә Нәби!» дип эндәште.

3. Һәрбер пәйгамбәр үз кавеменең каршылыкларына үзе җавап бирде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә каршы чыкканнарга Аллаһы Тәгалә Үзе Коръән аятьләре белән җавап бирде.

4. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтен Аллаһы Тәгалә иң хәерле өммәтләрдән кылды, һәм Кыямәт көнендә Расүлуллаһ

[1] Мөслим.

өммәтенә шәфәгатьче булачак. Ягъни Кыямәт көнендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләдән гөнаһлы мөселманнар өчен ярлыкау сораячак.

Әбү Һөрайрадан мондый хәдис риваять ителә: Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйтте: «Миңа миннән элек булган пәйгамбәрләргә бирелмәгән биш нәрсә бирелде:

1. Мин тәннәре кызыл төсле халыкка да, тәннәре кара төсле халыкка да, ягъни барча кеше һәм җеннәргә пәйгамбәр итеп җибәрелдем.

2. Миңа бөтен җир йөзе (мәчет һәм су кулланырга гозер булса) пакьләнергә яраклы нәрсә ителде.

3. Бер айлык юл барганда, Аллаһының дошманнарын куркыту белән ярдәм бирелде.

4. Сугыштан килгән ганимәт малы миңа хәләл ителде.

5. Һәм миңа шәфәгать бирелде. Ул шәфәгатьне Кыямәт көнендә өммәтем өчен азык иттем»[1].

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Без дөньяда – соңгылар, ә Кыямәт көнендә – беренчеләр»[2].

Аллаһы Тәгалә болай ди:

وَكَذَٰلِكَ جَعَلْنَاكُمْ أُمَّةً وَسَطًا لِّتَكُونُوا شُهَدَاءَ عَلَى النَّاسِ وَيَكُونَ الرَّسُولُ عَلَيْكُمْ شَهِيدًا ۗ

«[Ий Мөхәммәд өммәтенә керү шәрәфенә ирешкән кеше!] **Сез кешеләргә шаһит булырсыз дип, расүл исә сезләргә шаһит булсын дип, сезне урта өммәт итеп кылдык».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:143

1 «Тәнбиһүл гафилин» китабыннан.

2 «Тәнбиһүл гафилин» китабыннан.

Шушы күркәм мәүлид кичәсендә шөкрана кылып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар әйтеп, бер-беребезгә иминлек, бәрәкәт сорап догалар кылыйк. Барчабызга да Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкате булсын! Өммәтебезгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтенә ияргән хәлдә яшәргә насыйп итсен!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Габделхәй хәзрәт Гайнетдинов,*

*Лаеш районының Кече Елга авылы мәчете имам-хатыйбы*

*20 нче сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Динебезгә чакырабызмы?

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә болай дип әйтә:

وَلْتَكُن مِّنكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ إِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ ۚ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ ﴿١٠٤﴾

**«Арагызда** [дини һәм дөньяви] **хәергә** [файдалы эшләргә] **чакыра, яхшы гамәлләрне** [кылуны] **әмер итә, начар гамәлләрдән тыя торган җәмәгать булсын. Менә шулар – уңышка ирешүчеләр».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:104

Шушы аятьтән без күрәбез: Аллаһы Тәгалә һәрбер җәмгыятьтә изгелеккә өндәүче, начарлыктан тыючы һәм дөрес юлны күрсәтүче вәгазьләүчеләр булырга тиеш, дигән. Алар галимнәр, имамнар һәм гади мөселманнар арасыннан да булырга мөмкин. Тиешле урында яхшы үрнәк булу, тиешле урында начарлыктан тыю, тиешле урында аңлатып һәм үгет-нәсыйхәт кылып җибәрү – динебездә һәрберебезнең изге бурычы булып тора.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм беренче мөселманнарның тормышына күз салсак, аларның һәркайсының, һәрбер сәхабәнең динебез таралуына һәм ныгуына үзенең зур өлешен кертүен күрәбез. Аларның һәрберсе үзләренең дусларын, гаилә әһелләрен, якыннарын дингә чакырды. Шул сәбәпле, Ислам диненә килүчеләрнең саны

көннән-көн арта иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйтә: «Тирән кое кебек булмагыз, ә җиңел болыт кебек булыгыз». Бу хәдисендә Пәйгамбәребез кешеләрнең үзләренең килеп сорау биргәнен көтеп утырмагыз, ә кешеләрне шифалы яңгыр кебек, алар хәтта көтмәгәндә дә, вәгазьләп китегез, диде.

Бүген әгәр дә картага карасак, төрле илләргә күз салсак, дөньяның һәр почмагында, һәр шәһәрендә диярлек мөселманнарның яшәгәннәрен күрәбез. Безнең болгар бабаларыбызга Ислам дине нинди ерак җирләрдән килеп ирешкән. Ул вакытларда бүгенге кебек интернет, социаль челтәр каналлары юк иде. Һәр сүзне ирештерү өчен, атка атланып, көннәр, айлар буе озын юллар үтәргә кирәк иде. Әмма ул чор мөселманнары, динебезне тарату һәм башкаларны Исламга чакыру өчен, бөтен булган малларын, вакытларын һәм гомерләрен дә кызганмадылар. Ул кардәшләребез, Аллаһы Тәгаләнең сүзен җиткерү өчен, хәтта безнең Болгар җирләренә кадәр килеп җиткәннәр.

Динебезгә чакыру бурычы бүгенге көндә безнең җилкәгә салынды, безгә кадәр яшәгән әби-бабаларыбыз ул бурычны намус һәм сабырлык белән үтәделәр. Нинди генә авыр һәм куркыныч чорларда яшәсәләр дә, динне безгә хәтле саклап, бу әманәтне безгә тапшырдылар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә болай диелә: «Дин тоту утлы күмер тоткан кебек чорлар да булачак. Аны ташласаң, дин югала, сакласаң, кулны пешерә». Бу чорлар бәлки безнең әби-бабаларыбыз чорына туры килде һәм алар сынатмады. Нинди авыр тоелган чорларда да, алар диннәрен һәм дәгъват кылу эшләрен ташламадылар. Бүген исә ул безнең изге бурычыбызга әйләнде.

Һәрбер чорның үз авырлыгы, үз сынавы булган кебек, безнең чорыбызның да үз сынавы һәм үз авырлыгы бар. Бүгенге көндә без җәмгыятебездә төрле бозыклык чирләре таралганын, җәмгыятебезнең таркалганлыгын күрәбез. Шуңа да динебезгә чакыру, дәгъват кылу, яманлыктан тыеп, изгелеккә чакыру бурычы барыбызның да өстебездә тора.

Тәндә барлыкка килгән авырулардан котылу өчен ярдәм күрсәтүче табиблар кирәк булган кебек, кешедә булган кайбер кимчелекләрдән котылу һәм яхшы сыйфатларны үзләштерү өчен дә юл күрсәтүче галимнәр, имамнар һәм матур үрнәк күрсәтүче гади мөселманнар кирәк.

Без үзебезгә ахирәт тормышыбызда ничек җәннәтле булуыбызны теләсәк, ул нигъмәтне үзебезнең гаиләбезгә, балаларыбызга, оныкларыбызга, якыннарыбызга, җәмгыятебезгә дә теләргә тиешле. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз чорында яшәгән һәрбер кешене уттан коткарырга теләде. Алар нинди генә усаллык кылсалар да, сабыр итте, аларга ачуланмады һәм аларга газап килүен сорап догалар кылмады. Киресенчә, Аллаһы Тәгаләдән аларның иманга килүләрен, һидаять юлына басуларын сорап догалар кылды.

Мәдрәсәдә укып йөргән чорларда безгә бер риваять сөйләгәннәр иде: «Бер көнне Аллаһы Тәгалә җир йөзендә бозыклык кылган кавемне газапка тарту өчен, фәрештәләрне җибәрә, әмма фәрештәләр кире кайтып, Аллаһы Тәгаләгә мондый хәбәр җиткерәләр: «Йә Аллаһы, ул кавемдә бит берәү Сиңа гыйбадәт кыла», – диләр. Аллаһы Тәгалә нәкъ шул кешедән башлагыз, ди, чөнки ул башкаларны хак юлга өндәми иде». Бу риваятьтән без күрәбез, үзе дөрес юлда булып та, җәмгыятьнең бозык юлда булуына риза булып яшәүчеләрдән Аллаһы Тәгалә риза түгел.

Аллаһы Тәгалә безнең бер-беребезгә үгет-нәсыйхәт кылып яшәвебезне тели. Һәм бу хакта Ул Үзенең китабында әйтә:

ادْعُ إِلَىٰ سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ ۖ وَجَادِلْهُم بِالَّتِي هِيَ
أَحْسَنُ ۚ إِنَّ رَبَّكَ هُوَ أَعْلَمُ بِمَن ضَلَّ عَن سَبِيلِهِ ۖ وَهُوَ أَعْلَمُ بِالْمُهْتَدِينَ
﴿١٢٥﴾

«[Расүлем!] **Хикмәт белән һәм күркәм үгет белән Раббыңның юлына дәгъват ит. Һәм алар белән иң яхшы булган юл белән бәхәсләш.**

**Һичшиксез, синең Раббың кем Аның юлыннан язганын яхшырак белә, һәм Ул һидаятькә ирешүчеләрне дә яхшырак белә».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:125

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә безне кешеләрне хикмәт һәм Коръәндәге дәлилләр белән, матур вә хикмәтле сүзләр белән дингә чакырырга өнди. Бу Раббыбызның безгә Исламга дәгъват кылырга турыдан-туры әмере. Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кем дә кем икенче берәүнең Исламга килүенә сәбәпче булса, бу аның өчен кызыл дөяләргә ия булудан да артыграк булыр». Кызыл дөяләргә килгәндә, элекке заманнарда чүлләрдә яшәүче кешеләрнең бердәнбер транспорт чаралары ул – дөя яки ат булган. Хәзерге чордагы байлар, үзләренең җәмгыятьтәге статусын күрсәтү өчен, бик зиннәтле машинарларга утырып йөргән кебек, дөядән башка транспорт булмаган чорда да байларның бүтәннәрдән аерылып торасы килгән. Шуңа да берәр кешедә бик сирәк була торган кызыл төстәге дөя туса, бай гарәпләр аны бик зур бәягә сатып алып, аңа утырып йөрүләре белән бүтәннәр арасында аерылып торганнар. Кешенең бай һәм дәрәҗәле икәнлегеерактан ук күренеп торган.

Шуңа да пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм берәүнең дингә килүенә сәбәпче булуны кызыл дөяләргә ия булудан да артыграк нигъмәт икәнлеген искәртеп узды. Димәк, без берәүне вәгазьләсәк, үгет-нәсыйхәт кылсак һәм аның Исламга килүенә сәбәпче булсак, ахирәттә бу безнең өчен нинди зур нигъмәт булып кайтачак. Безнең аша дингә килгән кешеләрнең әҗерләре безнең мизаннарыбызга да өстәлеп барачак, шул ук вакытта үзләренә киметелмичә биреләчәк. Бу нинди зур нигъмәт һәм Раббыбызның зур бүләге!

Әлбәттә, башкаларны дингә өндәгәнче, иң беренче динебезне үзебезгә яхшылап өйрәнү, үзебезне хата-кимчелекләрдән, ялгыш фикерләр таратудан саклау тиешле. Безнең сөйли торган сүзләребез Коръәнгә, пәйгамбәребез

Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә һәм галимнәребезнең фәтваларына таянган булырга тиешле.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кем дә кем ишеткән бер сүзен сөйләсә, шул аңа ялганчылардан булырга җитәр». Шуңа да безнең һәрбер сүзебез үлчәнгән һәм дәлилләнгән булырга тиеш.

Икенчедән, башкаларны дингә өндәүче үзе сөйләгән сүзләренә гамәле белән үзе дә туры килергә һәм ул хөкемнәрне үтәп яшәргә тиешле. Бу хакта Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

أَتَأْمُرُونَ النَّاسَ بِالْبِرِّ وَتَنسَوْنَ أَنفُسَكُمْ

**«Әллә сез кешеләргә игелек әмер ителә торып та, үз-үзләрегезне онытасызмы?»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:44

Күргәнебезчә, Аллаһы Тәгалә бу аятьтә бүтәннәрне үгет-нәсыйхәт кылучыларның да сөйләгән сүзләренә тәңгәл килүләрен таләп итә. Чөнки Аллаһы Тәгалә безнең барыбызның да изге юлда булып, җәннәтле булуыбызны һәм башкаларны да шушы юлга чакыруыбызны тели. Мисал өчен, кемдер икенче берәүне хәмер эчүдән туктарга чакырып, үзе хәмер эчүен дәвам итсә; кемдер гайбәт сөйләп, үзе бүтәннәрне гайбәт сөйләмәгез, дип вәгазьләсә, аның сүзен беркем дә әһәмияткә алмаячак. Киресенчә, син үзеңне бел, безгә акыл өйрәтмә, диячәкләр. Шуңа да вәгазьләү һәм үзебезнең сөйләгән сүзләребезгә туры килеп яшәү дәгъват кылуыбызның нәтиҗәле булуын тәэмин итә.

Бала чагыбызда бәлки күпләребезнең бер хикмәтле хикәяне укыганы булгандыр. Бу хикәядә өч кызның ерак сәфәрдә булып кайткан әниләрен каршы алулары тасвирлана. Ике кызы әниләре юкта аны ничек сагынулары һәм елаулары турында сөйләсәләр, бер кызы, бер сүз дә дәшмичә, ерак сәфәрдән арып кайткан әнисенә кул-аякларын юарга җылы су һәм сөлге

китереп бирә. Менә бу кызы әнисенә чын мәхәббәтен һәм итагатен күрсәтә. Без дә үзебезнең динебезне дөрес итеп тотып, бөтен кануннарын үтәп яшәсәк, хәләл юл белән генә мал кәсеп итсәк, матур гаилә корып, тәрбияле балалар үстерсәк, күрше-тирәләребез белән тату яшәсәк, танышларыбыз яки авылдашларыбызга мәрхәмәтле булсак, гадел булсак, безгә бирелгән әманәтләргә хыянәт кылмасак, кеше хакына кермәсәк – бу сүзсез вәгазь булачак һәм иртәме-соңмы үзенең җимешләрен бирәчәк. Һәм нәтиҗәдә күпләрнең Исламга килүенә сәбәп булачак иншәАллаһ. Бүгенге көндә кайбер мөселман кардәшләребезнең бүтәннәрне кимсетеп, яла ягып, гайбәт сөйләп, биргән вәгъдәләренә хыянәт кылып йөргәннәрен күреп чәчләр үрә тора! Мондый гамәлләр күпләрнең динебездән читләшүенә сәбәп булырга да мөмкин.

Әгәр дә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышына күз салсак, аның тормышында бер гаеп тә таба алмыйбыз, ул хәтта пәйгамбәрлеккә хәтле дә Мәккә шәһәрендә иң намуслы, иң ышанычлы һәм иң тәрбияле кеше иде. Хәтта аны «әмин» – «ышанычлы» – дип йөртәләр иде. Менә бу да безгә, дәгъват юлына басарга теләүчеләргә, зур үрнәк һәм кагыйдә булып тора.

Исламга дәгъватны кемнән башларга дигәндә, әлбәттә, үзебездән һәм үзебезнең гаиләбездән башлау иң дөресе була. Чөнки һәрбер изгелек үзебездән һәм гаиләбездән башланырга тиешле. Ә җир йөзендәге иң зур изгелек ул – хакыйкатьтә булу. Шулай ук бүгенге көндә без, әгәр дә тирә-юнебезгә карасак, үзен мөселман дип санап яшәүчеләр арасында яшәсәк тә, динебездән ерак һәм динебезне бөтенләй дә белмәүчеләрнең күп булуын күзәтәбез. Ә бит «мөселман» дигән сүз ул ниндидер милләтне яки халыкны түгел, ә шушы дөньяда Аллаһы Тәгаләгә буйсынып, Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен үтәп яшәүче кешене аңлата.

Дәгъват кылучыда булырга тиешле кайбер сыйфатлар:

1. Ихлас булу.

2. Тәкъва булу, харамнардан саклану, хәтта шөбһәле нәрсәләрдән дә качу.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Шөбһәле әйберләрне шикләнеп, эшләүдән тыелмыйча торып, бер кеше дә чын тәкъвалардан булып саналмас», – дип әйткән.

3. Дөрес сүзле булу, ялган сөйләмәү.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Ялганнан бик нык сакланыгыз. Чынлыкта, ялган гөнаһларга илтә. Ә инде гөнаһлар утка алып бара. Чынлыкта, кеше ялганлый, аның эче ялган белән тула һәм ул Аллаһы каршында ялганчылардан булып языла. Дөрес сүзле булыгыз, чынлыкта, дөреслек яхшылыкка илтә. Ә яхшылык исә җәннәткә илтә. Һәм дөрес сүздә булган кешенең эче дөреслек белән тула. Һәм ул Аллаһы каршында тугрылардан булып языла».

4. Башка диннәрне һәм аларның ияләрен сүкмәү һәм аларга тел тидермәү.

Аллаһы Тәгалә хәтта мөшрикләр, потларга табынучылар хакында болай дип әйтә: «Сез аларны, Аллаһыны калдырып, табынган нәрсәләрен сүкмәгез [башка юл белән игелеккә чакырыгыз], юкса алар да белмичә чиктән ашып, Аллаһыны сүгәчәкләр» («Әл-Әнгам / Терлек», 6:108).

5. Мәрхәмәтле булу, кешеләргә карата каты мөнәсәбәтле булудан тыелу.

Аллаһы Тәгалә Үзенең соңгы сөекле Пәйгамбәре салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында болай дип әйтә: «[Расүлем! Өммәтеңә карата сиңа] Аллаһыдан [бирелгән кызгану һәм] шәфкать белән син аларга [Өхед сугышында әмереңнән чыкканнарга] йомшак булдың. Әгәр дә дорфа, каты күңелле булсаң, алар синең яннан таралып киткән булырлар иде» («Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:159).

Димәк, шушы аятькә таянып, һичшиксез шуны әйтеп була: Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлында кешеләрне игелеккә чакырган вакытта, аларга карата йомшак мөнәсәбәтле булу кирәк.

6. Биргән вәгъдәне үтәү. Әманәтне саклау, хыянәт итмәү.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Дүрт төрле сыйфат бер кешегә хас булса, ул чын монафикъ булыр. Ә инде дүртесенең берсе булса, димәк, анда монафикъларның бер сыйфаты бар, дигән сүз, хәтта шул сыйфатын калдырганчыга кадәр. Беренчесе: әманәт алса – хыянәт итәр. Икенчесе: сөйләсә – ялган сөйләр. Өченчесе: вәгъдә бирсә – үтәмәс. Дүртенчесе: бәхәсләшсә – чиктән чыгып, гөнаһка керер».

7. Күршеләр белән яхшы мөнәсәбәттә яшәү. Туганнар белән яхшы мөнәсәбәттә булып, туганлык җепләрен өзмәү, авыруларның хәлен белү.

Раббыбыз барчаларыбызга да чын мөэмин-мөселманнардан булып, бер-беребезне вәгазьләп һәм үгет-нәсыйхәт кылып яшәргә насыйп әйләсә иде.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Дамир хәзрәт Гыйниятуллин,*
*Кайбыч районының имам-мөхтәсибе*

*27 нче сентябрь вәгазе,*

*рабигыль-әүвәл аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Өлкәннәрне хөрмәтләү

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмне юктан бар итүче, тәрбиядә тотучы Аллаһы Хак Сөбеханәһү вә Тәгаләгә хәмед-сәна, мактауларыбыз булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, күркәм сәхабәләренә салават-шәрифләребез, хәер-догаларыбыз барып ирешсә иде. Үзебезнең әрвах булып үткән әби-бабайларыбызга, әти-әниләребезгә, еракякын туганнарыбызга һәм барча мөселман кардәшләребезгә догаларыбыз барып җитсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا

«[Ий коллар!] **Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага, ... игелек кылыгыз».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:36

Аллаһы Тәгалә колларына Үзенә генә гыйбадәт кылырга боера һәм һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылудан тыйганнан соң, ата-аналарыбызга изгелек итәргә куша. Безнең бу фани дөньяга килүебезнең сәбәпчеләре, безне яратып, кайгыртып торучы кешеләребез – әти-әниләребез. Балага динне өйрәтү, әдәп-әхлагын тәрбияләү, матди яктан тәэмин итү; ул балигълыкка ирешкәч, аңа Аллаһы кушканнарны үтәп яшәргә боеру – болар барысы атаанага йөкләтелгән.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять кылына: «Бер-берләре белән бәйле булган өч аятьтә болай дип әйтелә:

1. «Аллаһыга итагать итегез, Расүлгә итагать итегез һәм [аларга каршы төшүдән] сакланыгыз» («Әл-Маидә / Табын», 5:92) – ягъни Аллаһыга һәм Аның Расүленә итагать итмәгән кешенең гыйбадәтләре кабул ителмәс.

2. «[Ий, мөэминнәр!] Намаз укыгыз, зәкят бирегез һәм Расүлгә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) итагать итегез...» («Ән-Нур», 24:56) – ягъни намазларын укып та, зәкятләрен түләмәгәннәрнең гыйбадәтләре кабул булмас.

3. «Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек» («Локман», 31:14) – ягъни Аллаһы Тәгаләгә итагатьле булып та, ата-анасын хөрмәт итмәүчеләрнең гамәлләре кабул булмас. Аллаһы ризалыгы – ата-ана ризалыгында, ата-ана риза булса, Аллаһы Тәгалә разый була».

Аллаһы Тәгалә әлеге «Локман» сүрәсендә болай дип әйтә:

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ حَمَلَتْهُ أُمُّهُ وَهْنًا عَلَىٰ وَهْنٍ

> **«Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән** [бу көчсезлек чоры авырга узуы белән башланып, нифасы беткәнче дәвам итә]**...»**
>
> «Локман», 31:14

Әниләребез безне үзләренең карыннарында тугыз ай күтәреп йөртте, без үскән саен авырайдык. Безне бу дөньяга тудырганда аның күз алдыннан бөтен тормышы узып киткәндер. Ниһаять, без бу дөньяга килгәч, шатлангандыр, дулкынлану хисләре кичергәндер. Көннәрен төннәренә ялгап, безне кулларында күтәреп үстергәндер. Төрле куркыныч хәлләрдән, хәвеф-хәтәрләрдән саклагандыр, үзе ач булса да, безне ашаткандыр, елаганда җылы кочагына алып тынычландыргандыр. Әтиләребез дә, гаиләсен, балаларын тәэмин итәр өчен, көчен-вакытын кызганмыйча, көннәр буе эшләгәннәрдер. Бала бәхетле, көчле булсын дип тырышканнардыр.

Безнең өчен иң якын кешеләребез – әти-әниләребез булуын һәрчак истә тотыйк, кардәшләребез! Ата-анасына итагатьле, ихтирамлы булган кеше бүтән кешегә дә кадер-хөрмәт күрсәтә. Без өлкәннәребезне дә онытмаска тиешбез, чөнки алар да кемнеңдер әти-әнисе бит. Һәрдаим ярдәм итеп, хәлләрен белеп, яннарына барып күңелләрен күреп торсак, нур өстенә нур булыр иде. Алар мәчеткә намазга килгәч, азан әйтсәләр, Коръән мәҗлесләрендә иң элек дога кылсалар, киңәшләре һәм белемнәре белән уртаклашсалар – ягъни без аларның җәмәгать өчен кирәк булуларын сиздерсәк, өстебездә булган хакның бер өлешен үтәгән булырбыз.

Хөрмәтле дин кардәшләребез! Ата-аналарыбызга карата кадер-хөрмәтсез булу – зур хурлык! Алар бездән тик яхшылык көтәләр, безнең ярдәмгә мохтаҗ булып, игътибарыбызга өметләнеп яшиләр. Без үстек, без көчле, безнең хәзер гыйлемебез бар, кешеләр алдында дәрәҗәләребез дә зур. Ә кем аркасында шундый абруйга лаек булдык икән без? Әллә бик тиз хәтеребездән чыгардыкмы икән, кечкенә чагыбызда әти-әниебезнең ярдәменә мохтаҗ булган вакытларыбызны? Арабызда ата-аналарын рәнҗетүчеләр, хәтта кулларын да күтәрүчеләр, алардан туеп, үлемнәрен теләүчеләр дә юк түгел, кызганыч! Әйе, исән-сау булсак, килер бер көн, без дә әти-әниләребез урынына калачакбыз, авырып китсәк, балаларыбызның ярдәме безгә дә кирәк булачагын истә тотыйк, кардәшләребез! Шуны онытмыйк, әти-әнисен хөрмәт иткән кешенең балалары үзен хөрмәт итәчәк, картлык көнендә терәк булачак!

Мәлик әс-Сәгыйди радыяллаһу ганһедән риваять кылына: «Бервакыт мин пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында идем, шулвакыт ансарлар арасыннан бер кеше килде һәм болай дип сорады: «Йә Расүлуллаһ, әйт әле, ата-анам вафат булганнан соң, аларга карата берәр хөрмәт күрсәтә аламмы?» Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип җавап бирде: «Әйе, әгәр дә ошбу дүрт әйберне үтәсәң: алар өчен догада булып, Аллаһыдан аларны гафу итүен, кичерүен сорасаң;

алар әйтеп калдырган вәгъдәләрен үтәсәң; әти-әниеңнең туганнары белән туганлык җепләрен сакласаң; аларның дөньялыкта калган дусларына хөрмәт күрсәтсәң».[1]

Раббыбыз Коръәни Кәримдә мондый дога өйрәтә:

رَبَّنَا اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ وَلِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ يَقُومُ الْحِسَابُ ﴿٤١﴾

> **«Ий Раббыбыз!** [Колларга] **Хисап булачак көнне мине дә, ата-анамны да, барча мөэминнәрне дә ярлыка».**

«Ибраһим», 14:41

Бер хәдисендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дәхшәтле Кыямәт көнендә Аллаһы өч кешегә борылып та карамас: үзенең әти-әнисен ихтирам итмәүчегә; хәмер эчүчегә; бер яхшылык эшләсә, шуның белән битәрләүчегә.

Өч кеше җәннәткә кермәс: әти-әнисен хөрмәт итмәүче; фәхеш эшләр эшләнгәндә, битараф булып карап торучы; ир-атларга охшарга тырышучы хатын-кыз».[2]

Дөреслектә, ата-анага карата ихтирамлы булу иманның ныклыгыннан тора, тәкъва булуны күрсәтә. Бу пәйгамбәрләрнең, расүлләрнең сыйфаты.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُل رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا ﴿٢٤﴾

> **«Мәрхәмәтлектән алар алдында тыйнаклык канатын җәй һәм** [кяфер булсалар да, һидаятькә ирешүләрен Аллаһыдан сорап]**: «Ий Раббым!** [Минем фани мәрхәмәтем нәрсә генә ул?] **Алар кечкенә**

1 Әхмәд, Әбү Давыд, Ибне Мәҗә.

2 Ән-Нәсаи.

**чагымда мине** [зур бер шәфкать белән] **үстергәннәре кебек, Син дә аларга** [бакый рәхмәтең белән] **мәрхәмәт ит», – дип әйт».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:24

Әти-әнигә һәм өлкән буынга карата мәрхәмәтле, ихтирамлы булу, әдәп-әхлакка өйрәтү өчен, балаларны кечкенәдән үк тәрбияләү – безнең өстебездә булган вазифаларыбыз. Аллаһы Тәгалә балаларны безгә әманәт итеп бирде, шуңа күрә аларны тәрбияләүдә бик игътибарлы булырга кирәк.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять ителә: «Һәр бинаның нигезе бар, Исламның нигезе – күркәм холыклы булу», ягъни кешеләргә карата ачык йөзле булу, аларга изгелек эшләү һәм яманлык кылудан баш тарту. Йорт төзегәндә дә, иң элек планлаштырып, яхшы сыйфатлы нигез, фундамент салып куела. Нигезе яхшы булса гына, йортның дивары да ныклы була, җимерелми. Балаларыбыз да яшьли иманлы булсын дисәк, без кичектермичә тәрбия эшләрен алып барырга бурычлыбыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Кечкенәләргә мәрхәмәтле булмаучылар һәм өлкәннәрне ихтирам итмәүчеләр – алар бездән булмадылар». Динебез әти-әниләребезне, өлкәннәребезне, кечкенәләребезне хөрмәт итәргә боера. Әти-әниләргә мәрхәмәтле булу гөнаһларның юуылуына бер сәбәп тә булып тора.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдис-шәрифендә: «Кайда гына булсаң да, Аллаһыдан курык. Яманлык кылсаң, артыннан шунда ук яхшылык кыл, гөнаһыңны сөртеп ташласын. Кешеләр белән яхшы холыклы бул», – дип әйтеп калдырган.[1]

Йә Аллаһым! Үзең кушканнарыңны үтәп, тыйганнарыңнан тыелып яшәргә насыйп ит! Ата-аналарыбызны һәм өлкәннәребезне хөрмәт итеп, үзебездән соң килүче буыннарыбызны әдәп-әхлакка өйрәтеп калдырырга ярдәм ит!

[1] Әт-Тирмизи.

Йә Аллаһым! Тәүбәләребезне кабул итеп, гөнаһ-хаталарыбызны, кимчелекләребезне гафу ит. Дөньякүләм барча мөселман кардәшләребезгә ярдәм ит. Адашып-саташып йөрүчеләреңне туры юлга күндер. Дөреслектә, барча мактау Сиңа гына! Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фәнис хәзрәт Хәлфетдин,*

*Баулы районы Кызылъяр авылының җәмигъ мәчете имам-хатыйбы*

*4 нче октябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Гыйлемне остазлардан алуның әһәмияте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Раббыбызга хәмде-сәна, мактау-догаларыбыз булса иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез ирешсә иде. Җомга көннәребез мөбарәк булсын!

Ислам дине укып, гыйлем иясе булуга бик зур әһәмият бирә. Динебезнең гыйлем алуга игътибар бирүен тагын да яхшырак аңлар өчен, Пәйгамбәребезгә беренче иңгән аятьтәге «укы» сүзенә күз салу да җитә.

Аллаһы Раббыз болай дип әйтте:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾

«[Расүлем! Һәрнәрсәне юктан бар итеп] **Яратучы Раббың исеме белән** [башлап, Коръәнне] **укы!»**

«Әл-Галәк / Оешкан кан», 96:1

Кешелекне караңгылыктан яктылыкка чыгара торган Коръән китабы безгә зур йогынты ясый торган китап булгач, аятьләр эчендә «гыйлем» сүзенә басым ясаган очракларны күрергә мөмкин. Мәсәлән, Аллаһы Раббыз болай дип әйтте:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ۗ

**«Әйт: «**[Исламны] **Белгән** [һәм белгәне белән яшәгән] **кешеләр белән** [хакны] **белмәгән** [шул сәбәпле, наданнарча эш йөрткән һәм адашу эчендә югалып калган] **кешеләр тиң була аламы?»**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:9

Гыйлем – Аллаһы Тәгаләнең бер сыйфатыдыр. Ихласлыгыбызны түбәннән югары мәртәбәгә күтәрү бары тик белем алу аркылы гына була. Бар милләтнең иң олы дошманы – җәһиллек, наданлыктыр. Наданлык белән көрәшмичә, дошманнарны җиңеп булмый.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә исебезгә төшерә:

وَاللَّهُ أَخْرَجَكُم مِّن بُطُونِ أُمَّهَاتِكُمْ لَا تَعْلَمُونَ شَيْئًا وَجَعَلَ لَكُمُ السَّمْعَ وَالْأَبْصَارَ وَالْأَفْئِدَةَ ۙ لَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ ﴿٧٨﴾

**«Аллаһы сезне берни белмәгән хәлегездә аналарыгызның карыннарыннан чыгарды, сезгә колаклар, күзләр һәм** [аң-зиһен үзәге булган] **күңелләр бирде. Бәлки, сез** [үзегезгә насыйп булган нигъмәтләрнең зурлыгын аңлап, аларның бәясен белерсез һәм] **шөкер итәрсез».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:78

Бу аятьтән беркемнең дә бу дөньяга белеп, ягъни гыйлемле булып тумаганы аңлашыла. Шуңа да адәм баласына белем туплау вәҗиб хөкемендә. Моның иң хәерле юлы: «Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варисларыдыр», – дигән хәдискә муафыйк кылып, гыйлемне галимнәрнең (остазларның) авызыннан ишетеп җыюыбыз.

Бүген без белемне дистанцион рәвештә алу шәкеленә өстенлек бирүче яшьләрне очрата алабыз. Кайбер балалар җәмгыятьтән аерылып, «домашнее обучение, образование»га, ягъни өйдән чыкмыйча гына, җансыз «экран» аркылы белем ала. Педагог һәм методистлар әйтүенчә: «Ул методика тиз темп белән үсеш ала башласа да, бу – безнең өчен бер яңалык һәм аның кая илтәсен беркем дә әлегә әйтеп һәм фаразлап бирә алмый». Алар бу өлкәдәге

яңалыкны ныклап өйрәнергә чакыралар. Хәзер инде бу хәл дөньяви уку йортларында гына түгел, ә дини уку йортларында да кулланыла.

Шушы дини белем алуга килгәндә, кешенең «электрон» дәрес алган вакытында экранның теге ягында «дөрес» мөгаллим утырганын каян беләбез һәм моңа кем нинди гарантия бирә ала?

Кеше ялгыз башына хакыйкатьне (дөреслекне) яманнан аеру халәтендә яратылмаган, ул бер сәбәпчегә, ягъни мөгаллимгә мохтаҗ. Юкка гына Аллаһы Тәгалә җир йөзенә пәйгамбәрләр һәм китаплар җибәрмәгән.

Чын гыйлемне остазсыз-галимсез үзләштереп булмый. Ә без укытучыларыбыз, остазларыбызга ничек хөрмәт күрсәтергә тиеш соң?

Игътикадыбызда тәкъдир ике төрле була:

1) без үзгәртә алмаган һәм көчебез җитмәгән тәкъдир;

2) без үзгәртә алган тәкъдир.

Беренчесенә кешенең тышкы кыяфәте (гәүдәсе, акылы), ата-ана, туган җире (туган туфрак), милләте һәм укытучы-мөгаллимнәр керә. Һәм, әйе, без укытучыларны да сайлый алмыйбыз икән. Алар безгә ата-ана кебек, Аллаһы тарафыннан билгеләнгән затлар. Без аларны хөрмәт итәргә тиеш.

Әгәр дә бер шәкерт кеше (укучы) даны таралган укытучыда гына укырга теләп, бер остаздан икенче остазга сикереп, күчеп йөрсә, бу наданлык билгесе була, чөнки гыйлем өстәргә теләгән кеше кайда һәм кемдә генә булуга карамастан, шул җирендә хикмәт һәм зирәклек табарга тиеш.

Танылган галимебез Ризаэтдин бине Фахретдин хәзрәтләре үзенең әдәп китабында мөгаллимнәргә карата хөрмәт итүне болайрак яза:

1. Остаз вә мәктәп җитәкчеләре сезнең эшегезне юлына куючылар вә сезнең өчен хәсрәт чигүчеләр булып, аларның сезнең өстегездә олы хаклары бардыр. Шуның өчен аларның кушканнарын җиренә җиткерүдә кимчелек эшләмәгез вә тыйган эшләрендә әвәләнмәгез!

2. Сөйләшкән вакытыгызда алар белән әдәпле сөйләшегез, артык кычкырмагыз, аларны алдап вә бер кешене гайбәт итеп бер дә сөйләмәгез!

3. Аталарыгыз тәннәрегезне тәрбияләп үстергән хәлдә, остазларыгыз җаннарыгызны тәрбия итеп үстерәләр. Бу сәбәпле, остазларыгыз – бөек аталарыгыздыр. Сез дә боларны чын күңел белән сөегез, нәсыйхәтләрен тыңлагыз, авыруларның табибларга тапшырылуы кебек, барлык ихтыярыгызны аларга тапшырыгыз, аларның теләкләренә каршы килмәгез!

4. Мөгаллимнәрегезгә түбәнчелекле булыгыз, каршыларында әдәпле утырыгыз, нәсыйхәтләре белән гамәл кылыгыз, саваплы булыр өчен хезмәтләрен җиренә җиткерегез, аларга ялыныгыз, башка урында ялыну – мөэмин-мөселманга хас булмаган хәлдә, гыйлем өйрәнү тугрысында ялыну – мөэмин-мөселман сыйфатыдыр.

5. Мөгаллимнәргә каршы килмәгез, алар белән кычкырышмагыз, һәрбер гүзәл эшләрдә аларның сүзләренә җан вә тән белән иярегез. Ләкин аңламаган урыныгыз булса, шул хәленчә калдырып китмичә, бәлки әдәп вә сабырлык белән: «Әфәндем, бу җирне аңламадым вә бу сүзне белмәдем», – дип кайтарып сорагыз!

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Өлкәннәрне хөрмәт итмәгән, кечеләрне кече итмәгән һәм гыйлем ияләренә тиешле хөрмәтне күрсәтмәгән кеше – минем өммәтемнән түгелдер», – дип әйтте. Шулай ук Расүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Фәннәрне өйрәнегез, гыйлемнәр алыгыз. Һәм шул фән белән гыйлемнәрне үзләштерүдә булышкан галимнәргә (остазларга) сабырлык күрсәтүне исегездән чыгармагыз», – дип әйтте.

Гыйлем алу Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына һәм җәннәт юлына алып килә. Бер хәдистә болай дип әйтелә: «Кем гыйлем алу нияте белән юлга чыкса, Аллаһы Тәгалә аны җәннәткә илтә торган юлга чыгарыр. Фәрештәләр гыйлем алучының аяк асларына канатларын җәеп торырлар. Һичшиксез, гыйлем иясе өчен җирдә һәм күктә булган һәрнәрсә, хәтта су эчендәге балыклар да, аның өчен ярлыкау сорап торырлар. Гыйлем иясенең гыйбадәт кылучы кешедән фазыйләте (өстенлеге) – айның йолдызлардан өстенлеге кебектер. Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары. Пәйгамбәрләр исә үзләреннән соң мираска

беркемгә дә динар да, дирһәм дә калдырмаслар. Алар мирас итеп гыйлем калдырырлар. Аны алган кеше мираска мул итеп акча алган кебек булыр».

Ләкин гыйлем юлы – сабырлык һәм тырышлык сорый торган бер юлдыр. Ул төрле сынаулар һәм авырлыклар белән чорналган. Җәннәткә илтә торган юллар да авырлыклар белән бөтерелгән бит. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бер хәдисендә: «Тән рәхәтлеге белән генә гыйлем алырга көч җитми», – дип әйтелә.

Белемнең фазыйләтен дәвам итеп, башка хәдис тә китерелә: «Үзең өчен яки кемне дә булса өйрәтү ниятеннән гыйлемнән бер бүлек өйрәнгән кешегә Аллаһы Тәгалә чүлдәге һәр ком бөртеге кадәр әҗер-савап язар».

Бер әдәп дәресләрен өйрәтә торган китапта болай язылган: «Кеше гыйлем алуын дәвам иткәнчегә кадәр галим булып санала. Ләкин ялгыш укыган гыйлеме күп, дип уйлап, гыйлем алуын туктатса һәм янындагы булган кеше белән сүз көрәштерә башласа, ул кеше дөньяның иң надан кешесенә әверелер».

Бервакыт Габдулла бине Мөбарәк хәзрәтләреннән: «Әгәр Аллаһы Тәгалә сиңа кайчан үләчәгеңне белдерсә, нәрсә белән шөгыльләнер идең?» – дип сораганнар. Ул: «Гыйлем белән шөгыльләнер идем», – дип әйткән. «Гыйлемнән өстенрәк нәрсә юкмы?» – дип сорагач, ул: «Әйе, аннан да өстенрәк нәрсә юк», – дип җавап кайтарган. «Гыйлем белән шөгыльләнүнең башка гыйбадәтләрдән фазыйләтлерәк икәнен ни белән исбатлап бирәсең?» – дип сорагач, ул: «Гыйлем һәрнәрсәдән дә югары, чөнки Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәренә һәрнәрсәне дә бирде һәм артыгын сорау белән әмер ителмәде. Гыйлем хакында исә: «Раббым, минем гыйлememне арттыр», – дип әйтергә боерды. Әгәр Пәгамбәребез Аллаһыдан гыйлемнән тыш башка нәрсә сораган булса, мин гыйлемне өстен куймас идем», – дип җавап биргән.

Гыйлемнең өстенлеген исбатлый торган Пәйгамбәребезнең түбәндәге хәдисен китерәсем килә: «Сөләйман галәйһиссәлам мал, солтанлык һәм гыйлем сайлау арасында ирекле кылынды. Ул гыйлемне сайлап алды. Шуңа да, нәтиҗәдә, байлыкка һәм солтанлыкка да ирештерелде».

Әбү Әвсәд хәзрәтләре: «Гыйлемнән башка кыйммәтле бернәрсә дә юктыр. Солтаннар – кешеләр өстендә хакимдер. Ә галимнәр исә – солтаннар өстендә хакимдер», – дип әйтте. Галимнәр дөньяда кешеләргә юл күрсәтеп, хәерле гамәлләргә сәбәпче буган кебек, ахирәттә дә юл күрсәтүләрен дәвам итәчәкләр.

Вәгазьне йомгаклап, түбәндәге хәдисне карап китик: «Җәннәт әһелләренең җәннәттә дә галимнәргә ихтыяҗлары булыр. Җәннәт кешеләре һәр җомга көнне Аллаһы Тәгаләне зиярәт итәрләр. Аллаһы Тәгалә аларга Миннән теләгән нәрсәләрегезне сорагыз, дип әйтер. Алар исә галимнәргә борылып: «Нәрсә сорыйк?» – дип әйтерләр. Галимнәр: «Аллаһыдан шунышуны сорагыз», – дип җавап бирерләр. Кешеләр галимнәргә дөньяда мохтаҗ булган кебек, Ахирәттә дә мохтаҗ булырлар».

Аллаһы Тәгалә безнең калебләребезгә гыйлемгә карата ихласлылык һәм мәхәббәт салып, өстебездә билгеләп куелган остаз һәм имамнарыбызга олуг хөрмәт күрсәтеп, мөгаллим һәм хәзрәтләребезнең хәер-догаларын алырга насыйп итсен. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фатих хәзрәт Нуруллин,*
*Зәй районы имам-мөхтәсибе*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# МАРТ-ИЮНЬ

## «Кол Шәриф»тә Коръәнне хәтем кыла башлауга 3350 көн булды

5 мартта «Кол Шәриф» мәчетендә Коръән укыла башлауга 3350 көн тулды. Биредә 12 хафиз, бер-берсен алыштырып, Коръәнне башыннан ахырына кадәр бер тәүлек эчендә укып чыга һәм аны кабаттан укырга керешә. Билгеле булганча, 2015 елның 2 гыйнварында Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан башкаласы үзәгендә урнашкан «Кол Шәриф» мәчетендә Коръән хәтем кылуны башлап җибәрде. Биредә хәтем кылу башланганнан алып бүгенге көнгә кадәр Кәлам Шәрифне уку, биш вакыт намаздан кала, бер минутка да тукталмады. Ә Болгар шәһәрендә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы белән Коръәнне өзлексез хәтем кылу 2015 елның 14 июнендә башланды. Бүгенге көнгә кадәр, биш вакыт намазларны укудан кала, биредә хәтем кылу бер көнгә дә тукталмады. Нәтиҗәдә 5 мартта татар хафизлары тарафыннан Шәһре Болгарда Коръән укыла башлауга 3187 көн тулды. Бу эштә көн саен иртәнге 9.00дан 17.00гә кадәр 6 хафиз катнаша һәм алар Коръәнне тулысынча 3,5–4 тәүлек эчендә укып чыга. «Кол Шәриф»тә һәм «Ак мәчет»тә Коръән хәтем кылуда барлыгы 40 хафиз катнашты.

## КИУның Коръән хафизлар әзерләү үзәге шәкертләренә иҗазәтләр тапшырылды

Казан ислам университетының Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәгендә тәҗвид кагыйдәләре җыентыклары буенча иҗазәтләр тапшыру тантанасы узды. Иҗазәтләр 20дән артык шәкерткә бирелде: алар шәех Хәмдалла әс-Сафти белән бергә ике көн дәвамында шигъри формада язылган «Төхфәтүл-әтфәл» һәм «Мөкаддимә әл-Җәзәрия» уку кагыйдәләрен укыды һәм үзләштерде. Казан ислам университетының Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәгендә мондый иҗазәтләрне 2010 елдан бирле бирәләр.

## Татарстан Рәисе һәм Мөфти катнашында Яшел Үзән районы Яңа Тура авылында яңа мәчет ачылды

Рамазан-шәриф аеның 4 нче көнендә (14 нче мартта) Яшел Үзән районы Яңа Тура авылында яңа мәчет үз ишекләрен ачты. Яңа мәчетне беренче булып

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Яшел Үзән районы башлыгы, Яшел Үзән шәһәре мэры Михаил Афанасьев килеп күрде.

Гомуми мәйданы 330 квадрат метрны тәшкил иткән яңа гыйбадәт йорты берьюлы 250 кешене сыйдыра. Анда ир-атлар өчен ике гыйбадәт залы, хатын-кызлар өчен антресоль кат һәм балаларга дәрес бирү өчен бүлмә бар. Бинаның фасады геометрик элементлар һәм витражлы, традицион мөселман рәсемнәр төшкән һәм алтын сиптерелгән тәрәзәләр белән бизәлгән. Интерьер композициясенең үзәге булып гипслы декор белән бизәлгән һәм яктыртылып торган михраб хезмәт итә. Заманча люстра белән яктыртылган гөмбәз һәм бизәкле келәм шулай ук игътибарны җәлеп итә. Мөнбәр, баскыч, антресоль катның киртәсе һәм уемнар агачтан эшләнгән. Гөмбәзнең түбәнге өлеше һәм диварларның бер өлеше кулдан эшләнгән мозаика белән бизәлгән. Мәчет янәшәсендә бердәм стильдә төзелгән бинада тәһарәтханә һәм котельная урын алган.

Яңа Тура авылында мәчет төзелешендә хәйриячеләр һәм проектның кураторы Татарстан Рәисе каршындагы Мәдәният үсешенә ярдәм фонды актив катнашты. Яңа Турада ачылган мәчеттән 3 гектар мәйданда Ислам Мәгърифәт үзәген төзү башланды. Киләчәктә биредә шулай ук мәдрәсә, никах үзәге һәм балалар бакчасы салу; спорт белән шөгыльләнү һәм ял итү өчен мөмкинлекләр булдыру ниятләнә.

## Изге Рамазан аенда Мөфти мөхтәсибәтләрдә мөселманнар белән очрашты

Изге Рамазан аенда Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанның Совет районы, Түбән Кама, Аксубай, Теләче, Лаеш һәм Буа районнары мөхтәсибәтләренә эшлекле сәфәр кылып, мөселманнар белән очрашты. Очрашулар вакытында Мөфти хәзрәтләре Рамазан аеның һәм ураза тотуның фазыйләтләре, нәфесне тәрбияләү, Коръән уку өчен бирелә торган саваплар, хәтем кылуның мөһимлеге турында вәгазьләр сөйләде. Төбәк җитәкчеләре белән очрашуларда исә урыннардагы дини вәзгыять турында фикер алыштылар. Урыннардагы сәфәр программалары кызыклы итеп төзелгән иде. Мәсәлән, Мөфти Түбән Кама мөхтәсибәтендә Н. В. Лемаев исемендәге «Бигеш» халыкара аэропортында һәм Түбән Каманың үзәк хастаханәсендә намаз уку бүлмәләрен ачуда катнашты. Түбән Кама мөхтәсибәте оештырачак пансионат проекты белән танышты. Теләчедә татар халкының авыл көнкүреше тасвирланган туган якны өйрәнү музеенда булды. Камил хәзрәт Сәмигуллин Буада

мөхтәсибәт һәм мәдрәсәнең 2023–2024 еллардагы эшчәнлеге нәтиҗәләре белән танышып, мәдрәсә янында урнашкан «Илһам» балалар үзәгенең яңа бинасын карады. Имам-мөхтәсиб үзәкне алга таба үстерү буенча планнарын тәкъдим итте, ә кечкенә шәкертләр «Сәхәр һәм авыз ачу йоласы» сәхнә күренеше белән сөендерде. Очрашу барышында мөхтәсиб Илмир хәзрәт Хәсәнов шулай ук Буа мәдрәсәсенең яңа комплексын тәкъдим итте.

## «Бигеш» аэропортында һәм Түбән Кама үзәк район хастаханәсендә намаз бүлмәләре ачылды

Рамазан аеның 5 нче көнендә (15 мартта) Н. В. Лемаев исемендәге «Бигеш» халыкара аэропортының яңа терминалында намаз уку бүлмәсен ачу тантанасы узды. Анда Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Түбән Кама районы башлыгы, Түбән Кама шәһәре мэры Рамил Муллин, Түбән Кама төбәге казые һәм имам-мөхтәсиб Салих хәзрәт Ибраһимов, Н. В. Лемаев исемендәге «Бигеш» аэропорты» АҖ генераль директорының беренче урынбасары – җитештерү буенча директор Дмитрий Захаров, епископ Пахомий һ. б. катнашты. Җитәкчеләр, иң беренче чиратта, намаз уку бүлмәсен карады, аңа булган ихтыяҗ һәм аннан файдалану турында фикер алышты, аннан соң җирле хәзрәтләр белән беренче намаз укыды. Мөфти яңа бүлмәгә мосхафлар бүләк итте.

Намаз бүлмәсе, Түбән Кама районы гына түгел, Яр Чаллы һәм якын-тирә район мөселманнарының аэропорт җитәкчелегенә үтенече белән ачылды. Әлеге тәкъдим яңа терминал төзелешендә исәпкә алынып, Түбән Кама мөхтәсибәте белән килештерелде. Ул пассажирлар өчен уңайлы, тыныч, җылы, имин урында урнашкан. Кыйбла юнәлеше билгеләнгән, келәмнәр җәелгән, дини әдәбият урын алган. Хатын-кызлар өчен намаз уку урыны пәрдә белән бүлеп алынган. Утыз квадрат метрлы намаз уку бүлмәсенә берьюлы 20 кеше кереп намаз укый ала.

Н. В. Лемаев исемендәге «Бигеш» аэропорты Түбән Камадан – 29,5 км һәм Чаллыдан 25 км ераклыкта урнашкан. Аэропорт мөмкинлекләреннән Чаллы, Түбән Кама, Зәй, Алабуга, Менделеевск, Әгерҗе, Минзәлә шәһәрләрендә, шулай ук Удмурт Республикасы, Башкортстан Республикасы шәһәрләрендә яшәүчеләр һәм Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерының эре предприятиеләре вәкилләре файдалана.

Аэропорттан җитәкчеләр Түбән Кама күппрофильле үзәк район хастаханәсенә юнәлде. Биредә, дәвалану учреждениесе төзекләндерелгәннән

соң, тагын бер намаз уку бүлмәсе ачылды. Хастаханә, Түбән Кама районыннан тыш, Чистай, Зәй халкы өчен дә хезмәт итә. 42 квадрат метрлы намаз бүлмәсе хастаханәнең 2 нче дәвалау корпусында урнашкан. Ул тәһарәт алу һәм бәдрәф бүлмәсе белән, шул исәптән, колясkaлы инвалидлар өчен мөмкинлекләр тудырылып җиһазландырылган. Намаз уку бүлмәләрен карап торучы итеп мөхтәсибәт тарафыннан Җәлил хәзрәт Латыйпов билгеләнде.

## «Зәкят» фонды «кояшлы» балалар тәрбияләүче гаиләләр өчен хәйрия ифтары үткәрде

Рамазан аеның 11 нче көнендә (21 мартта) Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды Бөтендөнья Даун синдромлы кешеләр көненә багышланган хәйрия ифтары үткәрде. Бу уңайдан 50 кеше – Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды карамагындагылар һәм аларның әти-әниләре – «Ханума» кафесына җыелды. Ифтар программасы кысаларында Коръән аятьләре укылды, Рамазан турында вәгазь сөйләнде, иҗади мастер-класслар оештырылды. Аннан соң «Зәкят» хәйрия фондыннан истәлеккә бүләкләр бирелде.

«Зәкят» хәйрия фонды әлеге чараны үткәрүдә үз өлешен керткән һәр кешегә ихлас рәхмәтләрен җиткерә. Игелекле эшләрегезне Аллаһы Тәгалә кабул итсен!

## Казанда 12 нче Республикакүләм ифтар узды

29 мартта Казанда 12 нче Республикакүләм ифтар узды. Җәмәгать белән авыз ачу мәҗлесе Татарстанда изге айның икенче ункөнлегенә йомгак ясады. Иң зур авыз ачу мәҗлесләренең берсе быелдан «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме химаясенә күчте һәм Россиянең ислам дөньясы илләре белән халыкара эшлекле элемтәләрне ныгыту бурычларын исәпкә алып уздырылды.

Республикакүләм ифтар 2013 елдан бирле, ел саен Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, «Ак Барс Арена» стадионы дирекциясе һәм «Туган авылым» милли-туристлык комплексы көче белән оештырыла. 2021 елдан бирле ул «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә уза. 12 нче Республикакүләм ифтарда 12 мең кеше катнашты. Авыз ачу мәҗлесенә чакырылган Татарстанның төрле почмакларыннан килгән дин кардәшләребез, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның якыннары, мохтаҗлар һәм физик мөмкинлекләре чикле кешеләр, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, эшмәкәрләр, төрле төбәкләрдән килгән кунаклар һәм рәсми затлар бар иде.

Ифтарның бай мәдәни программасы Россиядә игълан ителгән Гаилә елы, шулай ук Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елын исәпкә алып төзелгән иде. Анда аерым игътибар җәмәгать белән Фәләстыйн халкы, «Крокус сити холл»да зыян күрүчеләр һәм Ватаныбыз иминлеге өчен дога кылуга бирелде. 12 нче Республикакүләм ифтарда катнашучыларның барысына да истәлеккә яңартылган «Казан басма»сы бүләк итеп бирелде. Мосхафлар Катарның вакф һәм Ислам эшләре буенча министрлык каршындагы вакфлар эшләре буенча баш идарәнең финанс ярдәме белән бастырылды.

## «Нурлы Рамазан» бәйгесендә җиңүче бүләкләнде

29 мартта 12 нче Республикакүләм ифтар барышында, Татарстан мөфтиятенең Рамазан ае уңаеннан җәмәгать урыннары арасында иң матур бизәлештә ярышу буенча «Нурлы Рамазан» бәйгесендә җиңүчене һәм финалга чыгучыларны бүләкләү тантанасы узды. Бәйге шартлары буенча, абсолют җиңүче булып Кукмара районының Туембаш авылыннан Мөэминә Хәбибуллина йорты танылды. Әлеге өйнең тарихы кызыклы: аны йорт хуҗабикәсе түгел, ә монда үз йортлары янганнан соң яши торган гаилә бизәгән. Нигъмәтҗановлар гаиләсе, Мөэминә ханымга рәхмәт йөзеннән, үзләренең төп бүләген – хаҗга юлламаны бизәлгән йорт хуҗабикәсенә бүләк итте. Шулай итеп, Мөэминә Хәбибуллинага «ДУМ РТ Хаҗ» рәсми операторыннан хаҗга юллама тапшырылды. Финалга чыгучыларга мактау кәгазьләре тапшырылды. Туембаш авылындагы җиңү яулаган объект барлык сайлап алу критерийларына җавап бирә: ул бизәлештә Ислам һәм Рамазан ае символларын кулланган; гадәти булмаган бизәлеш; эстетик күркәмлеккә һәм мәгънәви төсмерләргә ия; хәзерге заман технологияләрен файдаланган.

Бәйге финалына Яшел Үзән районының Норлат авылыннан Сафиннар гаиләсе, Кукмара районының Зур Сәрдек авылыннан Ишмөхәммәтов гаиләсе һәм Саба районының Байлар Сабасы бистәсеннән Тимергалиевлар гаиләсе – шәхси йортлары; җәмәгать урыннарыннан Казаннан «Казпринт» компаниясе һәм Сабадан «Империя цветов» кибете; дини оешмалардан Балтач районынның Борбаш Сәрдегәне авылы мәчете, Биектау районының «Бердәмлек» мәчете, Алабуга шәһәренең Җәмигъ мәчете, Мөслим районының «Корбангали» мәчете, Яр Чаллы шәһәрендә төзелеп килүче Җәмигъ мәчете чыкты. Конкурс кысаларында Татарстанның төрле почмакларында 52 урын бизәлде: болар – шәхси йортлар, мәчетләр, кибетләр, кафелар. Быел бәйгедә шәхси йортларда яшәүчеләр аеруча

актив катнашты. 17 гаризаның күпчелеге – Кукмара районыннан (7 гариза). Шулай ук Яшел Үзән һәм Саба районнарыннан катнашучылар булды (3әр гариза). Шунысын билгеләп узарга кирәк: Кукмара мөхтәсибәтендә шәхси секторда тулы бер урамны бизәделәр. Бу юлы шулай ук мәчетләр һәм мөселман белем бирү учреждениеләре дә узган елга караганда күбрәк: бәйгедә Казаннан, Яр Чаллыдан, Әгерҗе, Әлмәт, Арча, Әтнә, Балтач, Бөгелмә, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Яшел Үзән, Кукмара, Мамадыш, Мөслим, Яңа Чишмә, Тукай, Чирмешән, Нурлат мөхтәсибәтләреннән барлыгы 28 объект катнашты. Шунысы сөенечле: гариза җибәрүчеләр арасында кабат катнашырга теләүчеләр дә бар. Шулай итеп, алар республикада яңа традиция – урамнарда Рамазан мохитен тудырырга мөмкинлек бирә.

Бәйгедә шулай ук 7 җәмәгать урыны катнашты. Болар – Актаныш районындагы «Таңсылу» банкет залы, Казан шәһәренең «Әхмәдзәки» мәчете каршындагы «Halal food» кафесы, шулай ук Кукмара районындагы «Хәләл» кибете, Питрәч мөхтәсибәтенең Габдрахман бине Гауф исемендәге мәчете һәм Саба районындагы «Империя Цветов» һәм Казанның «Казпринт» компаниясе, Түбән Кама районындагы «Давай Меняться» своп-маркеты. Алар дин кардәшләребезне каршы алып, аларга бәйрәм кәефе бүләк итү өчен, үзләренең керү юлларын бизәде.

## Казанда Рамазан ае хөрмәтенә 30 нчы автобуста йөрү бушлай булды

5 апрельдә, Рамазан аеның соңгы җомгасында, Казанда 30 нчы автобус Рамазан ае уңаеннан барлык кешеләргә түләүсез хезмәт күрсәтте. Беренче тапкыр ул рейска Рамазан ае хөрмәтенә мөфтиятнең «Зәкят» хәйрия фонды башлангычы белән узган ел чыкты һәм казанлылар аны хуплап каршы алды. Акция кысаларында әлеге маршрутка караган бер автобуста иртәнге сәгать алтыдан (6:00) кичке сәгать алтыга (18:00) кадәр һәркем бушлай йөри алды. Изге айда казанлылар һәм башкала кунакларына мондый үзенчәлекле бүләкне Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды ясады – ул пассажирларның чыгымнарын күтәрде. Бушлай автобусны танып алу өчен, аның алгы тәрәзәләрендә «Благотворительный маршрут от БФ «Закят» дип язылган табличка урнашкан, ә салоны шарлар белән бизәлгән иде.

## Нәзарәт татарлар күпләп яшәгән төбәкләргә яңартылган «Казан басмасы»н таратты

Март аенда Татарстан мөфтияте яңартылган «Казан басмасы»ның бер өлеше Кырым Республикасы һәм Севастополь шәһәре мөселманнары Диния нәзарәтенә; Ставрополь крае мөфтиятенә; Ерак Көнчыгыш һәм Приморье мөфтиятенә; Казахстан һәм Үзбәкстан Республикаларының Казандагы Генераль консуллыкларына; Татарстан мөфтиятенең Арча мөхтәсибәтенә, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте составына керүче «Самара өлкәсе мөселманнары төбәк Диния нәзарәте» Үзәкләштерелгән дини оешмасына җибәрелде. Моңа кадәр мосхафларның аерым тиражы Россиянең төрле төбәкләреннән татар дин әһелләренә тарату өчен – Бөтендөнья татар конгрессына, шулай ук Россиянең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәтенә, Казан ислам университеты каршындагы Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәгенә, «Казан Кремле» музей-тыюлыгына, мөхтәсибәтләргә, Белорусь Республикасындагы мөселман дини берләшмәсенә, Татарстанның төзәтү колонияләренә тапшырылган иде.

Яңартылган «Казан басмасы» заманча халыкара стандартларга туры килә һәм ул дөньякүләм танылган «Казан басмасы» уникаль шрифты белән бастырылды. Нәзарәт гомуми тиражы 30 мең булган мосхафны «Казан басмасы»ның 220 еллыгы уңаеннан «Хозур» нәшрият йортында бастырды.

## Бертуган Батталовлар урамындагы яңа ачылган «Наташа» хосписында намаз бүлмәсе эшли башлады

Рамазан аеның 26 нчы көнендә (5 апрельдә) Казанда Бертуган Батталовлар урамы, 16 адресы буенча урнашкан «Наташа» хосписы рәсми рәвештә ачылды. Хосписның намаз укый торган бүлмәсендә беренче җомга намазы укылды. Аны Габдрахман Утыз-Имәни исемендәге «Ал Таң» мәчете имамы Ирек хәзрәт Җиһаншин җитәкләде. Җомга намазында 20 мөселман катнашты һәм Рамазан аеның фазыйләтләре турында вәгазь тыңлады.

80 квадрат метр мәйданлы намаз бүлмәсе 50 кешене сыйдыра. «Хоспис мәчете»ндә пациентлар белән рухи әңгәмәләр уздыру, намазлар һәм Коръән уку, дога кылу мөмкинлеге бар. Хосписта имам авыруларны һәм аларның якыннарын аерым бүлмәдә кабул итә.

## «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 13 нче чыгарылышында 180 кеше намазга басты

Рамазан аеның 27 нче көнендә (6 апрельдә) Казанда Нәзарәтнең иң мөһим проектларыннан берсе – намаз укырга өйрәтү һәм Ислам нигезләре белән таныштыру буенча «Ислам. Беренче адымнар» дип исемләнгән кыска вакытлы курслар – тәмамланды. Шәкертләр «Сира», «Гакыйдә» фәннәре һәм тәһарәт, намаз, ураза, хаҗ гамәлләре буенча гыйлемнәрне колачлаган курсны үзләштерде. Башка еллардан аермалы буларак, бу чыгарылышта гаиләләре белән белем алучылар да күп булды. «Ислам. Беренче адымнар» проектының 13 нче курсын 180 кеше тәмамлады. Унөч сезон дәвамында әлеге курсларда 1400гә якын кеше белем алды һәм намазга басты.

## Мөселманнар Казанның «Галиев» мәчетендә Татарстан Рәисе катнашында Ураза гаетен билгеләп үтте

Шәүвәл аеның 1 нче көнендә (10 апрельдә) бөтен дөнья мөселманнары бөек бәйрәм – Ураза гаетен – билгеләп үтте. Бу уңайдан Татарстан Республикасының барлык мәчетләрендә иртәдән үк бәйрәм чаралары башланды. Башкалада төп бәйрәм тантанасы «Галиев» мәчетендә узды. Гаеткә килгән мөселманнар, бәйрәм вәгазен тыңлап, Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә намаз укыды. Мәртәбәле кунаклар арасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов бар иде. «Галиев» мәчетендәге бәйрәм чараларын «ТНВ Татарстан», «ТНВ Планета» телеканалы аша турыдан-туры карарга мөмкин булды. Туры эфир шулай ук «Хозур ТВ»ның YouTube каналында да оештырылды.

## Татарстан шәһәрләрендә һәм районнарда Ураза гаете уңаеннан бәйрәм чаралары узды

10 апрельдә Татарстан шәһәрләрендә һәм районнарда Ураза гаете уңаеннан гомумшәһәр балалар һәм гаилә бәйрәмнәре узды. Быел ул Россиядә игълан ителгән Гаилә елы, шулай ук Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында үткәрелде. Мөхтәсибәтләр гадәттәгечә паркларда һәм мәчетләр янында бәйрәмнәр оештырды. Алар сыйнигъмәт, төрле бәйгеләр, викториналар, эстафеталар, милли уеннар, спорт ярышлары һәм мәдәни программа, тәмле сыйлар, пылау тәкъдим итте.

## Татарстанда «Рамазан – изге гамәлләр ае» марафоны кысаларында 3000нән артык кешегә ярдәм күрсәтелде

Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны кысаларында 3043 кешегә ярдәм күрсәтте. Әлеге акция Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан Рамазан аеның беренче көненнән үк игълан ителде. Марафонның төп нәтиҗәләреннән берсе авыру сабыйларны һәм өлкәннәрне дәвалау өчен акча җыю белән бәйле булды. Акция 32 авыру балага һәм физик мөмкинлекләре чикле 17 өлкән кешегә тернәкләнү һәм дәвалау курслары узарга мөмкинлек бирде. Моннан тыш, авыр тормыш хәлендә калган 19 өлкән кеше бурычларын түләү һәм көнкүреш шартларын яхшырту өчен, финанс ярдәме алды.

Шулай ук Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан 1 700 000 сум фитр һәм 850 000 сум күләмендә фидия җыелып, 68 мохтаҗ кешегә бирелде һәм Фондның социаль проектларына җибәрелде.

Хәйрия марафонының тагын бер юнәлеше Татарстанның аз керемле гаиләләренә азык-төлекләтә ярдәм күрсәтү белән бәйле иде. Ай дәвамында «Зәкят» хәйрия фонды үз карамагындагы 600 кешене, мәдрәсә шәкертләрен һәм мөгаллимнәрне, инвалидларны һәм башка мохтаҗларны 3,6 тонна азык-төлек белән тәэмин итте. Моннан тыш, «Зәкят» хәйрия фонды катнашында Фонд карамагындагыларга 1000нән артык ифтар җыелмасы таратылды; 375 мохтаҗ казанлы өчен 13 хәйрия ифтары уздырылды.

## Казанда яшь мөслимә киленнәр өчен онлайн-курслар башланды

2024 елның 23 апрелендә Диния нәзарәтенең мөселман яшьләре арасында зур популярлык казанган проектларның берсе – «Яшь килен» курслары үз эшен башлап җибәрде. Әлеге проект 10 нчы тапкыр тормышка ашырылып, онлайн форматта узды. Бу курсларда катнашучыларның географиясен киңәйтергә: Мәскәү, Калуга һәм Чиләбе өлкәләреннән, Мәскәү, Оренбург, Уфа, Ижау, Ульяновск, Төмән, Красноярск һәм Әстерхан шәһәрләреннән, Беларусь Республикасыннан һәм башка төбәкләрдән 70 мөслимәне җәлеп итәргә мөмкинлек бирде.

Киленнәр мәктәбе Аллаһы Тәгалә кануннары буенча бәхетле гаилә корырга һәм гаилә учагын саклап калырга теләүчеләр – 17 яшьтән алып һәм

аннан өлкәнрәк, кияүдә булмаган, ярәшелгән мөслимәләр һәм кызларын кияүгә бирергә җыенган әниләр өчен оештырыла. Белем бирү курслары Коръән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте һәм ислам дин галимнәренең гыйлемнәренә нигезләнгән. Мөслимәләр өчен биредә академик белемнәргә ия, танылган остазлар һәм шәехләрдән никахта ир вә хатынның бурычлары һәм хокуклары, мәһер, никахлашу өчен хәерле ир сайлау, яшь гаиләдә проблемалар, балалар тәрбияләү, никахта җенси мөнәсәбәтләр һ.б. турында тәфсилле лекцияләр уздырыла. Кызлар никах, үзләренең хокуклары һәм бурычлары турында хакыйкый гыйлемнәр ала һәм үзләренә ир сайлаганда төптән уйланган карарлар кабул итәргә өйрәнә.

## Азнакайда «Әсләм» VIII Коръән укучылар бәйгесе узды

Шәүвәл аеның 11 нче көнендә (20 апрельдә) Татарстанның Азнакай шәһәрендә ир-атлар арасында сигезенче тапкыр Коръән укучыларның «Әсләм» республика бәйгесе узды. Аны Татарстан мөфтияте, Азнакай районы мөхтәсибәте һәм хакимияте, Шакировлар гаиләсе оештырды. Бәйгедә Татарстан районнарыннан тыш, Башкортстаннан, Ижаудан, Оренбургтан 7 яшьтән алып 35 яшькәчә 49 Коръән укучы катнашты.

## РИИда мәчет каршындагы курслар мөгаллимнәренә белем арттыру турында таныклыклар тапшырдылар

15–19 апрельдә Россия ислам институтында мәчет каршындагы курслар мөгаллимнәре өчен квалификация күтәрү курслары узды. «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту буенча теория һәм практика» дигән курсларда Казан, Арча, Чистай, Лаеш районнары мәчетләре каршындагы курсларда белем бирүче укытучылар катнашты.

Курсларда дини дисциплиналарны укыту методикасы; Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлына (сира) кагылышлы фәннәрне укыту ысуллары, Коръән уку кагыйдәләре (тәҗвид), гыйбадәт нигезләре, ислам дине тәгълиматы (гакыйдә), гарәп теле һ.б. предметлар буенча өстәмә белемнәр бирелде. Дәресләрне Россия ислам институты һәм Казан ислам университетының әйдәп баручы белгечләре алып барды.

## Шәүвәл аеның 13 нче көнендә Татарстанда Хәтер көне узды

Шәүвәл аеның 13 нче көнендә (22 апрельдә) Казанда Хәтер көне үткәрелде. Татар халкы тарихында әлеге истәлекле дата республиканың төрле мәчетләрендә билгеләп үтелә, әмма төп чаралар аеруча зурлап башкалада – «Кол Шәриф» мәчетендә узды. Нәзарәтнең Аксакаллар шурасы оештырган чарага Татарстанның төрле почмакларыннан аксакаллар, мөхтәсибләр, имамнар килде.

«Хәтер көне» җәмәгать белән өйлә намазы уку белән башланды, аны Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин алып барды. Намаздан соң мәчеткә җыелган халык, чараның төп өлешендә катнашыр өчен, Казан ханнары җәсәдләре җирләнгән мавзолей һәм Сөембикә манарасы янына юнәлде. Каберлек янында Коръәннән сүрәләр укылды һәм Казанны алганда шәһит киткәннәр һәм динебез, халкыбыз һәм Ватаныбыз хакына төрле вакытларда һәлак булган татар халкы батырлары рухына багышлап дога кылынды. Җыелган халык Аллаһы Тәгаләдән аларның рухлары шат, мәңгелек урыннары җәннәттә булуын сорады.

Хәтер көне ел саен Татарстан мәчетләрендә, Нәзарәтнең Аксакаллар шурасы тәкъдиме белән, Рамазан ае тәмамланып, 2 атна узгач, шәүвәл аеның 13 нче көнендә билгеләп үтелә.

## Нәзарәт РФ Ислам мәгарифе буенча советы белән берлектә Татарстан мәдрәсәләрен тикшерүне тәмамлады

Экспертлар – ТР мөселманнары Диния нәзарәте белгечләре, РФ Ислам мәгарифе буенча советы белән берлектә, Татарстанның урта һөнәри мөселман мәгариф оешмаларының белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тикшерүне тәмамлады. Мониторинг РФ Президенты Администрациясе һәм Ислам мәдәниятенә, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды йөкләмәсе буенча үткәрелде. Татарстан Республикасында дин әһелләре һәм мөселман дине белән бәйле дини оешмаларга хезмәткәрләр әзерләү юнәлеше буенча белем бирү программасын тормышка ашыру хокукын бирүче лицензиясе булган 8 мәдрәсә эшли. Бу һөнәри мөселман мәгариф учреждениеләрендә 2693 кеше белем ала, аларның күпчелеген читтән торып уку һәм кичке бүлек шәкертләре тәшкил итә. Мониторинг мөселман мәдрәсәләренең белем бирү, фәнни һәм финанс-

хуҗалык эшчәнлегенә кагылышлы кирәкле статистика мәгълүматларын җыюны үз эченә ала.

Уку йортларын тикшерү һәм өйрәнү барышында Татарстан мәдрәсәләре, Россиядәге башка мәдрәсәләргә караганда, югарырак нәтиҗәләр күрсәтте. Беренче чиратта, бу белем бирү сыйфатын, мәдрәсәнең мәгълүмати базасының тәэмин ителешен күрсәтә. Татарстан мәдрәсәләре бу нисбәттән калганнарга үрнәк булып тора, чөнки алар үз эшчәнлеген Ислам буенча мәгариф советы стандартларына тулысынча туры китереп гамәлгә ашыра.

## Татарстан Мөфтие Коръән хафизлар белән очрашты

Шәүвәл аеның 14 нче көнендә (23 апрельдә) Россия ислам институты бинасында КИУның Коръән хафизлар әзерләү үзәге студентлары өчен «Хәзерге заманда Идел-Урал төбәгендә «Казан басмасы»ның таралу мәсьәләләре» темасына түгәрәк өстәл узды. Утырышта төп чыгышны Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ясады. Ул хафизларга Коръән ятлауның фазыйләтләре, «Казан басмасы»ның тарихы һәм аның гомуммөселман мәдәнияте өчен әһәмияте, Нәзарәтнең бу басманы һәм татар халкында Коръән бастыру традицияләрен торгызу буенча эшчәнлеге турында сөйләде. Тәҗрибәле белгечләрне җәлеп итеп, Коръән ятлау буенча махсус программаны эшләтеп җибәрү планнары белән дә уртаклашты.

Очрашу ахырында шәкертләр Мөфтигә Коръәнне өйрәнү буенча мобиль кушымталар, мәчетләр каршында Коръән ятлау курсларында белем алу турында мөмкинлекләре, шулай ук бу өлкәдә балалар белән эшләү үзенчәлекләре турындагы сорауларын юллады.

## РИИда Ислам фәннәре буенча – төбәк һәм Татар теле буенча республикакүләм олимпиадалар узды

Шәүвәл аеның 16 нчы көнендә (25 апрельдә) Россия ислам институтында мөселман уку йортлары шәкертләре арасында берьюлы ике интеллектуаль ярыш: Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча төбәк олимпиада һәм Татар теле, әдәбияты һәм тарихы буенча республикакүләм олимпиада узды. Аларны Россия ислам институты, ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм күрсәтү фонды оештырды. Олимпиадаларда Татарстан, Башкортстан, Оренбург, Пермь өлкәсе һәм Мәскәү уку йортларыннан 60тан артык шәкерт катнашты.

## Нәзарәт һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе коллективы Казанның Иске татар зиратында өмә ясады

Шәүвәл аеның 18 нче көнендә (27 апрельдә) Татарстан мөфтияте коллективы, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре Казан шәһәренең Яңа татар зиратында өмә оештырды. Нәзарәт хезмәткәрләре, имамнар, мөгаллимнәр һәм шәкертләр зират территориясенең шактый зур өлешен тәртипкә китерде. Алар каберлекләрне чүп-чардан, кипкән үләннәрдән һәм корыган агачлардан аралады, аллеяларны себереп җыештырды, кабер ташларын чистартты. Өмә уздыру өчен Яңа татар зираты юкка гына сайлап алынмады. Биредә 50дән артык дин әһеле, мәгърифәтчеләр һәм галимнәр җирләнгән. Алар арасында Шиһабетдин Мәрҗани, Галимҗан Баруди, Әхмәдһади Максуди, Сөнгатулла Бикбулатов, Зәкәрия Минвәлиев, Габделхак хәзрәт Саматов, Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин бар. Ахырдан биредә җирләнгән дин әһелләре, күренекле мәгърифәтчеләр һәм остазлар рухына күмәкләп дога кылынды.

## Казанның Яңа татар зиратында Остазларны искә алу көне узды

Шәүвәл аеның 23 нче көнендә (2 майда) Казан шәһәренең Иске татар зиратында Остазларны искә алу көне билгеләп үтелде. Әлеге чара Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мәдрәсәсе тарафыннан ел саен дин әһелләре, мөгаллимнәр, шәкертләр, татар зыялылары катнашында «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» дигән исем белән оештырыла.

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин 26 ел эчендә шәкертләр белән бергәләп биредә дәфен кылынган хәзрәтләр вә остазларның каберен эзләп тапкан. Зиратта татар халкының олуг галимнәре – Шиһабетдин Мәрҗани, Галимҗан Баруди, Әхмәтһади Максуди һ.б., шулай ук совет чорында ислам динен саклап, киләчәк буынга тапшыруга зур өлеш керткән остазлар – Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин, Габделхак хәзрәт Саматов, Зәкәрия хәзрәт Минвәлиев һ.б. дәфен кылынган.

Быелгы Остазлар көненең төп үзенчәлеге шунда булды: каберлекләргә остазның исеме, әтисенең исеме язылган куар-кодлы табличкалар урнаштырылды. Барлыгы шундый 50ләп табличка урнаштыру ниятләнә. Зиярәт кыла торган

кеше, табличка янына телефон камерасын якын китереп, шәхесләрнең тормыш юлы һәм эшчәнлеге белән таныша ала.

Соңыннан Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә Коръән ашы узды. Шәкертләр тарафыннан Коръән хәтем кылынды һәм аның савабы мәрхүмнәр рухына багышланды.

## Урыссуда «Халисә» V Россиякүләм Коръән укучылар бәйгесе үтте

Зөлкагъдә аеның 3 нче көнендә (11 майда) Ютазы районы Урыссу бистәсендә хатын-кызлар арасында бишенче тапкыр «Халисә» Россиякүләм Коръән укучылар бәйгесе узды. Әлеге конкурс елдагыча Татарстан мөфтияте, Ютазы мөхтәсибәте тарафыннан, Ютазы районы хакимияте һәм Мәрданшиннар гаиләсе ярдәме белән оештырылды. Быел хатын-кызлар, Татарстан һәм күрше Башкортстан район-шәһәрләреннән тыш, Ижаудан да килде. Бәйгедә катнашучыларның иң яшенә – 8 яшь, иң олысына 38 яшь иде. Конкурс ике этаптан торды: иң элек 60 катнашучы арасында «Фәнис» мәдрәсәсе бинасында сайлап алу туры үтте һәм 22 конкурсант финалга чыкты. Финал мәртәбәле жюри каршында Мәдәният йорты бинасында узды.

## Казанда Kazan Halal Market хәләл ярминкәсе узды

«Казан» Агросәнәгать паркында «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2024» XV Халыкара икътисади форумы кысаларында Kazan Halal Market Халыкара Хәләл продукция ярминкәсе узды. Хәләл маркетта сатыла торган барлык товарлар төрле оешмаларда сертификацияләнгән иде һәм Диния Нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча Комитеты тарафыннан өстәмә рәвештә тикшерелде. Аерым алганда, Комитет белгечләре ярминкәдә эшләүче сатучыларның һәм җитештерүчеләрнең чималын, продукциясен, шулай ук сату-алу шартларының «хәләл» стандартларына туры килү-килмәвен карады. Комитет сату нокталарында «хәләл» нормативларын кертү буенча да эшләр башкарды: дуңгыз ите сатудан алынды, бина һәм җиһазлар җентекләп чистартылды, ремонт ясалды, бәдрәф бүлмәләре таһарәт алырлык итеп җиһазландырылды, хатын-кызлар һәм ир-атлар өчен аерым намаз уку урыннары булдырылды.

Ярминкәдә Россиянең төрле төбәкләреннән, шулай ук Төркия, Иран, Әзербайҗан, Казахстан, Кыргызстан һәм башка чит илләрдән 70кә якын

компания катнашты. Аерым алганда, Россия Федерациясе төбәкләреннән 57 компания үз продукциясен аерым блок итеп оештырылган «Татар базары» бренды белән тәкъдим итте. Биредә Татарстан, Башкортстан, Мордовия, Киров, Омск, Түбән Новгород һәм Пенза өлкәләреннән, шулай ук Чувашия, Оренбург һәм Пермь краеннан җитештерүчеләр катнашты. Алар товарларын ат итеннән ризыклар, колбасалар, консервалар; умартачылык продукциясе; бакча культуралары (җиләк-җимеш, бакча җиләге, каклар); файдалы үләннәр, чәйләр, кайнатмалар; милли киемнәр (баш киемнәре, Оренбург мамык шәлләре һ. б.); халык һөнәрчелеге (мәчетләрнең 3D модельләре, намазлыклар, табигый таштан тәсбихләр, басма продукция һәм төрле сувенирлар) кебек берничә юнәлештә тәкъдим итте.

## Татарстан Мөфтие «RUSSIA HALAL EXPO» Халыкара хәләл индустриясе күргәзмәсен Коръән укып ачты

Зөлкагъдә аеның 7 нче көнендә (15 майда) «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2024» Халыкара икътисади форумы кысаларында «RUSSIA HALAL EXPO-2024» Халыкара хәләл индустриясе күргәзмәсе ачылды. Беренче булып тантанада Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясады – ул экспозицияне Коръән укып ачып җибәрде.

Russia Halal Expo Россиядә инвестиция һәм инфраструктура белән бәйле проектлар тәкъдим ителә торган зур күргәзмәләрдән санала. Ул бизнес-проектларны таныту һәм үстерү, Форумда катнашучылар аралашуы өчен уникаль мәйданчык булып тора. Күргәзмәдә ислам икътисады башлангычлары, файдалы технологик альянслар, B2B-проектлары, зур бизнес, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары продуктлары тәкъдим ителә.

## Татарстан Диния нәзарәте KazanForum-да тематик мәйданчыклар оештырды

14–19 майда Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XV Халыкара икътисад форумы узды. Халыкара форум Россия Федерациясе һәм Ислам дөньясы илләренең икътисади өлкәсендәге хезмәттәшлегенең төп федераль мәйданчыгы булып тора. Төп максаты – Россия төбәкләре һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләре арасындагы сәүдә-икътисади, фәнни-техник,

социаль һәм мәдәни элемтәләрне ныгыту, шулай ук Россия Федерациясендә ислам финанс системасы институтларын үстерүгә ярдәм итү. KazanForum кысаларында ТР мөселманнары Диния нәзарәте берьюлы берничә тематик мәйданчык оештырды. Казанның Агросәнәгать паркында эшләгән Халыкара Kazan Halal Market хәләл продукция ярминкәсен оештыруда Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты буенча комитеты зур өлеш кертте. Әлеге комитет шулай ук Форум кысаларында Россия һәм чит илләр экспертлары катнашында хәләл өлкәсендә белгечләр әзерләү мәсьәләләренә һәм хәләл стандартлары буенча сервис темасына сессияләр уздырды. Ә Россия ислам институты каршындагы Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге «Ислам финансларында финанс технологияләре: заманча алымнар һәм перспективалар» сессиясен оештырды.

## KazanForum-ның пленар утырышында беренче тапкыр Казан кулъязма мосхафыннан аятьләр күрсәтелде

Зөлкагъдә аеның 9 нчы көнендә (17 май) Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» Халыкара икътисади форумының пленар утырышы узды. Югары җыелышны Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ачып җибәрде. Ул «Фәтх» («Җиңү») сүрәсенең аятьләрен ун кыйраәт буенча укыды. Шунысы игътибарга лаек: хәзрәт аятьләрне укыган вакытта, утырышта катнашучыларга тәүге тапкыр бу аятьләрне Казан кулъязма мосхафының (Коръәннең) битләреннән күрсәттеләр. Кулъязма Коръән Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан 2022 языла башлаган иде. Сәхнәдән билгеләп үтелгәнчә, «бу башлангыч Россиянең ислам дөньясының зур өлеше булуын күрсәтә: моны бай дини мирас һәм уникаль фәнни мәктәпләр, шул исәптән каллиграфик мәктәпләр раслый».

## Казанда «Милли тормыш һәм дин» XIV Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы пленар утырышы үтте

Зөлкагъдә аеның 7 нче көнендә (18 майда) Казанда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында «Милли тормыш һәм дин» XIV Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының пленар утырышы үтте. Форумга Россия Федерациясенең 77 төбәгеннән 1000 дин әһеле һәм кунак килде.

Һәр елдагыча, форум делегатлары дин өлкәсенә кагылышлы мөһим мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен җыелды.

Форумның пленар утырышында Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты. Ул курра-хафизлар, ислам финанслары буенча белгечләр, хаттатлар әзерләргә – Казанда белем алырга һәм татар авторларын «Хозур» нәшрият йорты белән хезмәттәшлек итәргә чакырды. Камил хәзрәт Татар дин әһелләре форумының истәлеге итеп һәр делегатка яңартылган, ТР мөселманнары Диния нәзарәте әзерләп бастырган «Казан басмасы» таратылуын әйтте. «Хәзер инде татарларның Коръәнне әзерләп бастыру традицияләре торгызылып бетте, дияргә мөмкин. Кайчандыр милләтебез бу өлкәдә беренче иде, хәзер дә ислам фәнендә беренчелеккә ирешик, хәзрәтләр! Россиядә исламны татарлар үстерә, диярлек булсын!» – диде Мөфти.

## Болгарда Изге Болгар җыены узды

Зөлкагъдә аеның 11 нче көнендә (19 майда) Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителү уңаеннан, һәр елдагыча, Шәһре Болгарда зурлап, Татарстан мөселманнары тормышындагы төп вакыйгаларның берсе – Изге Болгар җыены үткәрелде. Җыен «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» 2024 XV Халыкара икътисади форумы мәдәни программасына нокта куйды. Анда Татарстан Республикасы җитәкчелеге, Россия Федерациясе төбәкләреннән делегатлар, Россия мөфтиятләре, дини оешмалары, якын һәм ерак чит илләрдән мөселман җәмгыятьләре вәкилләре катнашты.

Быел Татарстан Диния Нәзарәте җыенның дини өлешен көчәйтеп җибәрде. Җәмәгать белән тәүбә кылу тәүге мәртәбә Изге Болгар җыенының төп, кульминацион өлеше булды һәм киләчәктә әлеге мөселман форумын уздыруның төп максатына әйләнер, дип ниятләнә. Бу чарага мөселманнарны күбрәк җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк, дип көтелә. «Тәүбә» чарасын Кече манара янында күп еллар дәвамында оештыручы, Россиянең Үзәк өлеше мөфтияте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин алып барды. Баш мөфти үгет-нәсыйхәтләрдән соң мөселманнарга ихластан тәүбә кылырга һәм Аллаһыдан гөнаһларын гафу итүне сорап дога кылырга чакырып, мөрәҗәгать итте. Хәзрәт тәүбә кылу һәм истигъфарның зарурлыгын изге Коръән аятьләренә һәм сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә таянып бәян итте.

## Изге Болгар җыенында гаиләле парлар арасында хаҗга 6 юллама уйнатылды

Быел Изге Болгар җыенында тәүге тапкыр гаиләле парлар арасында хаҗга 6 юллама уйнатылды. Хаҗга юлламалар уйнату тантанасы Истәлек билгесе янында узды. Бүләк уйнатуда 1500дән артык пар катнашты. Алар иртәдән рәсми никахны раслаучы ЗАГС штампы (мөһере) сугылган РФ гражданнары паспортларын күрсәтеп теркәлү узды. Бүләк уйнату чарасын Казанның «Ирек» мәчете имам-хатыйбы Тимур хәзрәт Камаев һәм аның хәләл җефете алып барды. Хәзрәт Ислам динендә гаиләнең әһәмияте, рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклау буенча нәсыйхәтләрен җиткерде.

Хаҗга юлламалар уйнату 2 этапта узды: беренче этапта алып баручы, җиңүчеләрне билгеләү өчен, сәхнәдә барабанны әйләндереп, аннан бер-бер артлы уникаль номерлар язылган очраклы 15 билетны алды. Әлеге билет ияләренә бүләккә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йортыннан китаплар җыелмасы тапшырылды. Аннан соң беренче этапта җиңгән 15 гаилә бәйгенең икенче этабында катнашты. Җиңүче парларга – Гөлназ һәм Илнур Шәйдуллиннарга (Казаннан), Мөнирә һәм Габделхәй Борһановларга (Тәтештән), Алия һәм Юрий Бабийларга (Казаннан) – 2025 елда «Комфорт» программасы буенча хаҗга юллама алу өчен 2шәр кешелек 3 сертификат тапшырылды.

Әлеге акция Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында уздырылды, мөселман җәмәгатьчелеге игътибарын гаилә кыйммәтләренә һәм аларны популярлаштыруга юнәлтергә мөмкинлек бирде. Хаҗга юллама уйнатуның максаты мөселманнарны киләчәктә гаилә коруга этәрү, ир белән хатын арасындагы җылы мөнәсәбәтләрне ныгытуга булышлык итү иде.

## Болгарда Нәзарәтнең чираттагы пленумы узды

Зөлкагъдә аеның 11 нче көнендә (19 майда) Болгарда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Пленумы үтте. Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге утырышта аның урынбасарлары, казыйлар, шулай ук бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр катнашты.

Камил хәзрәт нәзарәтнең имамнары алдында бурычлар куйды. Ул халыктан килгән барлык сорауларны һәм шикаятьләрне өйрәнеп барырга һәм аларга җавап бирергә, гомумән, халык белән тыгыз элемтәдә торырга кушты. Шулай ук Мөфти дәгъвәт эшен көчәйтергә һәм вәгазьләрнең сыйфатын яхшыртырга чакырды.

Пленумда Мөфтинең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасарлары Равил хәзрәт Зөфәров һәм Ришат Хәмидуллин, мөфтиятнең «Хәләл» комитеты җитәксесе Әббяс хәзрәт Шляпошников чыгыш ясады. Мөфти урынбасары Ришат хәзрәт Хәмидуллин «Хозур» нәшрият йортында алып барылган дәгъват эшчәнлеге турында сөйләде. Татар һәм рус телләрендә китаплар бастыру, «Хозур ТВ» телеканалы, онлайн-китапханә, онлайн-мәдрәсә, социаль челтәрләрдә аккаунтлар, төрле сайтлар, газеталар һәм журналлар – болар барысы шактый киң аудиторияне колачлый. 2023 ел нәтиҗәләре буенча Нәзарәтнең медиапроектлары барлыгы 35 млн кешене җәлеп иткән.

## РИИда Республикакүләм студентлар конференциясе узды

Зөлкагъдә аеның 15 нче көнендә (23 майда) Россия ислам институтында «Хәзерге Россия мөселман яшьләренең бердәмлекне саклауда һәм ватанпәрвәрлекне ныгытудагы роле» дип исемләнгән II Республикакүләм студентлар фәнни-гамәли конференциясе узды. Форумны Ислам мәдәниятенә, фән һәм мәгарифенә теләктәшлек фонды ярдәме белән Татарстан мөфтияте, Россия ислам институты һәм Казан ислам университеты оештырды.

Чарада Россия ислам институты, Казан ислам университеты, Казан (Идел буе) федераль университеты, Болгар ислам академиясе, Казан дәүләт мәдәният институты, Уфа фәннәр һәм технологияләр университетының Бөре филиалы, шулай ук Татарстан мәдрәсәләре, Алабуга политехник көллияте вәкилләре һәм республика мәктәпләре укучылары – барлыгы 100дән артык кеше катнашты. Яшь галим-тикшеренүчеләр Россиядә ислам дин гыйлеме һәм теология; туган тел һәм әдәбият; мультиконфессиональ җирлектә чит телләр һәм мәдәниятләр; хәзерге җәмгыятьтә медиа һәм реклама белән бәйле процесслар: аларны өйрәнү алымнары, эволюция, перспективалар һ.б. хакында фикер алышты.

## Солдатларга Татарстан мөселманнарыннан гуманитар ярдәм тапшырылды

ТР мөселманнары Диния нәзарәте делегациясе Луганск Халык Республикасына алтынчы тапкыр гуманитар миссия белән барып кайтты. Делегацияне кабаттан Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкләде, шулай ук аның составында казый һәм Ютазы районы имам-мөхтәсибе Марат хәзрәт

Мәрданшин, Казан шәһәренең «Ирек» мәчете имам-хатыйбы Тимур хәзрәт Камаев, Татарстан Мөфтиенең иминлек буенча киңәшчесе Фаик Абдурагимов һәм мөфтиятнең башка хезмәткәрләре керде.

Хәзрәтләрне Луганскида ТР Премьер-министры урынбасары Евгений Варакин каршы алды. Алар, Мөфти Камил хәзрәт, шулай ук ТР Сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин белән бергә Лисичанск госпиталенда булып, җирле хастаханәдә Татарстан ярдәме белән үткәрелгән ремонт эшләре белән танышты. Татарстан хәзрәтләренең Луганск Халык Республикасына ике көнлек сәфәренең төп өлеше Луганскида узды: монда алар ике госпитальдә яралы сугышчылар белән очрашу үткәрде. Алар солдатларга намазлыклар, догалыклар, мисвәкләр, тәсбихләр һәм башка кучтәнәчләрне тапшырды. Солдатлар хәзрәтләргә сораулар бирә алды, тәкъдимнәрен җиткерде, вәгазьләр һәм нәсыйхәтләр тыңлады, аралашып рухи көч алды. Аннары ТР Мөселманнары Диния нәзарәте делегациясе Луганскиның Җәмигъ мәчетендә җирле имамнар белән очрашу уздырды, аларга шулай ук «Хозур» нәшрият йортының дини басмалары тапшырылды. Мөфтиятнең хезмәт командировкасының иң мөһим бурычы сугыш хәрәкәтләре зонасындагы солдатларга гуманитар йөк илтеп тапшыру иде. ТР Мөселманнары Диния нәзарәте делегациясе аны уңышлы үтәде: азык-төлек һәм кирәкле җиһазлар Луганскидагы Татарстан мөфтияте шефлыкка алган хәрби бүлекчә, «Алга» батальоны һәм Дебальцеводагы госпитальдә дәваланучы солдатларга барып иреште. Аларга генераторлар, ноутбуклар, МФУ (принтер, сканер, күчермә ясаучы аппарат функцияләрен үз эченә алган җайланма), бензин белән эшли торган пычкы, дрон детекторлары һәм дроннарны юлдан яздыручылар, автозапчастьлар, автомобильләр өчен инструментлар, медикаментлар, азык-төлек, эчке киемнәр, маскировка челтәрләре һ.б. тапшырылды. Бу йөк солдатларның теләкләрен исәпкә алып оештырылды һәм ТР Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан битараф булмаган мөселманнардан җыелган, «Мәрҗани» мәчете биргән акчага тупланды. Барлык товарлар турыдан-туры солдатларның кулына тапшырылды.

## Баулы мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Зөлкагъдә аеның 16 нчы көнендә (24 майда) Баулы районы Салих авылында «Нәҗметдин» мәчете ачылды. 30–40 кешегә исәпләнгән гыйбадәт йорты ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен таһарәтханәләр, уку кирәк-яраклары белән җиһазландырылган, электр энергиясе һәм җылыту системасына тоташтырыл-

ган. Мәчетнең әйләнә-тирәсе төзекләндерелгән. Бу көнне шулай ук районның Татар Кандызы авылында 1997 нче елда салынган мәчет яңадан төзекләндерелеп ачылды. Баулы мөхтәсибәтендә барлыгы 16 мәчет эшли.

## Лениногорскида XI «Гыйлем нуры» бәйгесе узды

Зөлкагъдә аеның 17 нче көнендә (25 май) Лениногорск шәһәренең «Ихлас» мәчетендә Лениногорск мөхтәсибәте оештырган XI «Гыйлем нуры» конкурсы узды. Чараның төп максаты – хәнәфи мәзһәбе һәм Матуриди гакыйдәсе традицияләрен ныгыту, шулай ук халык арасында дини белем таратуга кызыксынуны арттыру. Бәйгедә Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Әлмәт, Тукай, Буа, Мөслим, Сарман, Кукмара, Ютазы һәм Лениногорск мөселманнары көч сынашты. Сораулар катлаулы булуга карамастан, уенда катнашучылар үзләренең югары дәрәҗәдә эрудицияле булуын күрсәтте. Өстәмә уеннан соң, Кукмара мөхтәсибәте командасы җиңү яулады.

## Татарстан Мөфтие халыкны кабул итте

Зөлкагъдә аеның 20 нче көнендә (28 майда) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Нәзарәттә халыкны кабул итте һәм аның нәтиҗәләре буенча җаваплы затлар алдында бурычлар куйды. Көннең беренче яртысында мөселман активистлары, җәмәгать эшлеклеләре, битараф булмаган гражданнар Мөфтигә дини мәсьәләләр буенча консультация сорап мөрәҗәгать итте, үз проектлары белән таныштырды. Аерым алганда, очрашулар вакытында дин кардәшләр Татарстан Республикасында һәм Казанда Коръәнне һәм гарәп телен өйрәнү үзәкләрен ачуга, мөселман инфраструктурасы объектларын яхшыртуга кагылышлы мәсьәләләрне күтәрделәр; «Татар хафизы» проектын тәкъдим итеп, шул ук исемдәге бәйге үткәрергә теләк белдерделәр.

## Нәзарәттә Гаилә елы уңаеннан «Бәхетле гаилә» чарасы узды

Зөлкагъдә аеның 21 нче көнендә (29 майда) Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә «Бәхетле гаилә» чарасы узды. Аны Россиядә игълан ителгән Гаилә елы һәм Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү елы уңаеннан Нәзарәтнең Хатын-кызлар белән эшләү бүлеге һәм Татарстан Мөслимәләр берлеге оештырды. «Бәхетле гаилә» чарасында Татарстанда 40, 50 ел

дәвамында бергә тату, матур гомер иткән парлар, аларның балалары һәм оныклары, күпбалалы мөселман гаиләләре – барлыгы 100гә якын кеше катнашты.

Кунакларга үгет-нәсыйхәтләрне Татарстан Мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов юллады. Ул, Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламнәрен җиткереп, гаиләнең Исламдагы мөһим урынын билгеләп үтте. Озак еллар тату, матур гомер иткән парлар да үзләренең бәхетле гаилә булып яшәү серләре белән уртаклашты. Алар Татарстан Диния нәзарәтеннән махсус дипломнар белән бүләкләнде.

## Актаныш мөхтәсибәтендә балалар арасында «Мин намаз укырга яратам» бәйгесе узды

Зөлкагъдә аеның 22 нче көнендә (30 майда) Актаныш мөхтәсибәтендә балалар арасында «Мин намаз укырга яратам» бәйгесе узды. Районның Җәмигъ мәчетендә узган чарада 80 ир һәм кыз бала катнашты. «Мин намаз укырга яратам» бәйгесе – Актаныш мәчетләрендә балалар һәм яшьүсмерләр өчен ел дәвамында үткәрелгән дини-мәгърифәт дәресләренә йомгак ясау, мөгаллимнәрнең һәм шәкертләрнең уңышларын барлый торган чара булып тора. Анда мәктәпкәчә яшьтән алып 16 яшькә кадәрге балалар катнаша.

## Татарстан мәчетләрендә гаилә кыйммәтләренә багышлап җомга вәгазьләре укылды

Зөлкагъдә аеның 23 нче көнендә (31 майда), Балаларны яклау көне алдыннан, Татарстанның барлык мәчетләрендә гаилә, ата-ана хакы һәм бала тәрбиясенә багышланган җомга вәгазьләре укылды. Мисал өчен, Казанның «Галиев» мәчетендә Әлмәт районы имам-мөхтәсибе Исмәгыйль хәзрәт Сингатуллин гаилә кыйммәтләре турында бәян итте.

## Түбән Камада балалар арасында Коръән бәйгесе узды

Зөлкагъдә аеның 25 нче көнендә (2 июньдә) Түбән Кама мөхтәсибәтендә балалар арасында Коръән бәйгесе үтте. Җиде номинациядә барган бәйгедә 100дән артык бала катнашты. 3–7 яшьлек балалар Коръәннән үзләре теләгән сүрәне укыды, 7–11 һәм 12–18 яшьлекләр – ярты, бер, ике, дүрт җүзне яттан белү буенча көч сынашты. Җиңүчеләр һәм катнашучылар истәлекле бүләкләр алды.

## Җәйге каникул чорында Татарстан мәчетләрендә балалар өчен рухи-сәламәтләндерү курслары уза

Җәйге каникул чорында Татарстан мәчетләрендә балалар өчен рухи-сәламәтләндерү курслары уза. Күркәм гадәт буенча сабыйлар өчен белем бирү, танып белү һәм күңел ачу чаралары кысаларында кызыклы программалар әзерләнде. Ул әхлак һәм тәрбия, Ислам нигезләре, Коръән дәресләрен, шулай ук күңелле чаралар: шаян уеннар, бәйгеләр, сабантуйларны һ.б. үз эченә ала.

## 2024 елда «ДУМ РТ Хаҗ» белән 1800 кеше хаҗ кылды

Быел «ДУМ РТ Хаҗ» Татарстанның рәсми хаҗ операторы аша республикадан 1800 кеше хаҗ кылды. Алар өчен «Эконом комби», «Очкычлы», «Комфорт» һәм «Люкс» программалары эшләнде. Хаҗиларның беренче төркеме изге җирләргә 1 июньдә кузгалды. Соңгы төркем юлга 10 июньдә чыкты.

Хаҗиларны төрле белгечлектәге 20 табиб – кардиолог, травмотолог, гинеколог, йогышлы авырулар табибы һ.б. озата барды. Барлык хаҗилар да ковид, менингит һәм дифтериядән прививка ясатты.

## Нәзарәт 7 яңа ислам финанс продуктын хуплады

Май-июнь айларында Нәзарәт 7 яңа ислам финанс продуктын хуплады. Тәкъдим ителгән документларны өйрәнеп, әлеге продуктларны ислам хокукы кануннары нигезендә рөхсәт ителгән, дип тапты. Шулай итеп, хәләл финанс хезмәтләре базарында «ТР Эшкуарлыкка ярдәм фонды»ннан – «Иджара–Развитие производства» һәм «Мурабаха–Содействие»; «Татарстан Республикасы Төбәк лизинг компаниясе»ннән – «Исламский лизинг», «Металлинвестбанк»тан – «Исламский счет»; Татарстан Рәисе каршындагы Дәүләт торак фондыннан – социаль ипотека программасы; Ак Барс Банкыннан – «Проектлы финанслау», Дәүләти булмаган пенсия фондыннан пенсияне туплау буенча яңа продуктлар барлыкка килде. ТР мөселманнары Диния нәзарәте мөселманнар һәм финанс оешмалары арасында, шулай ук Россия финанс регуляторында ислам финанс продуктларын гамәлгә кертү өлкәсендә ышаныч казанды. Нәзарәттә 11 финанс оешмасы өчен 14 ислам финанс продукты, шул исәптән физик һәм юридик затлар өчен: коммерция ипотекасы, банк картасы, рассрочка, инвестицияләр, лизинг, факторинг һ.б. эшләнеп расланды.